ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

№12 (407)
ДЕКАБРЬ 2025

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ТӨКЛЕ АЯГЫҢ БЕЛӘН, АТ ЕЛЫ!

Безнең миссия – Татарстан Республикасында яңа логистика ысулларын гамәлгә кертү аша сәнәгать үсеше өчен иң яхшы шартлар тудыру

РЕКЛАМА

«БЕР ПОЯС ҺӘМ БЕР ЮЛ» КОНТЕЙНЕР ТЕРМИНАЛЫ

Гомуми линия: 8 (85557) 59447
Импорт бүлеге: +7 (987) 29-11-993
Экспорт бүлеге: +7 (987) 17-46-029

dxlc.ru
t.me/dxlcru
vk.com/dxlcru

№12 (407)
ДЕКАБРЬ 2025

16+

Редакция:
Адрес: 420066, Россия,
Татарстан Республикасы,
Казан, Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасары: Фәридә Әхмәтҗанова
Әдәби мөхәррир: Луиза Янсуар
Бүлек мөхәррирләре: Руфия Фазылова, Николай Коновалов, Евгения Чеснокова, Дмитрий Сивков
Авторлар: Олеся Бондаревская, Фәнзилә Җәүһәрова, Николай Крушинин, Әлфия Шаһиева, Оксана Бирюкова, Елена Добровольская
Фотографлар: Анна Арахамия, Лилиана Вәлитова, Александр Ефремов, Зөлфия Ибраһимова, Айдар Мөшәрәпов, Ната Смирнова, Рамил Гали, Салават Камалетдинов, Екатерина Ежова
Дизайн-макет: Олег Бурилов
Вёрстка: Анастасия Хатыйпова
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Тышлыкта: Елена Вальцефер-Миронова.
Екатерина Ежова фотосы

Журнал 1920 елдан нәшер ителә
1977 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

ММЧ исеме: ТАТАРСТАН TATARSTAN

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 400 данә
Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми.

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4750 данә.
Реклама 16+

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә басылды. Адрес: 420066, Россия, Татарстан Республикасы, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ №: М-2619
Басарга кул куелды: 16.12.2025
Чыгу көне: 22.12.2025

Коммерция директоры:
Рәшит Хәйретдинов,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9600-487-900
Коммерция директоры урынбасары:
Алина Майорова,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9033-132-741
Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Ирина Захарова, irinamoroz10@mail.ru
Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел.: (843) 222-09-80

РЕДАКЦИЯДӘН

105 ЯШЬ – БАРЫСЫ ДА АЛДА ӘЛЕ!

Һәр декабрь «Татарстан» журналына бер ел өсти. Быел безгә 105 яшь тулды! Басмабызның декабрь санында бу цифра шактый күзгә чалыныр, чөнки «Татарстан» редакциясе төрле жанрларда үткәннәрен искә төшерә, халыклар арасында 105 еллык дуслык тарихы, Яңа ел чыршыларын тыйган чаклар һәм бүген дә дәвам иткән, тамырлары белән еракларга тоташкан төрледән-төрле сәяхәтләр турында сөйли.

105 ел эчендә «Татарстан» журналы, үзе белән бер исемдәге туган республикабыз тормышын яктыртып, үз битләрендә бик күп вакыйгаларны сурәтли һәм мәңгеләштерә. Әлбәттә, бу эш редакциянең төрле составлары тарафыннан башкарыла, ләкин аларның барысы да үз миссияләрен – журналда Татарстан тарихын язу, теркәү һәм саклауны намус белән үти. Бу җаваплы миссия бүген дә дәвам итә, чөнки республика һәм журналны алда әле озын-озак еллар көтә!

Туган көн белән безне!

Сезнең 105 яшьлек редакциягез

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛАХОВ Мәгъзум Хәлимуллович
ФАЗЛЫЕВА Ләйлә Ринатовна
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы: «ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче: «ТАТМЕДИА» АҖ
Адрес: 420097, Россия,
Татарстан Республикасы, Казан,
Академическая ур., 2

«Татарстан» журналына ТРның барлык элемтә бүлекләрендә язылырга мөмкин:
Индекс **П2381** – татар телендә ярты елга
Индекс **ПА468** – татар телендә бер елга

Индекс **П2378** – рус телендә ярты елга
Индекс **ПА471** – рус телендә бер елга

2026 елның ярты еллыгына ТР буенча язылу бәясе:
1998 сум 00 тиен китереп бирешелә,
1939 сум 20 тиен соратып алганда.
2026 елга ТР буенча язылу бәясе:
3995 сум 90 тиен китереп бирешлә,
3878 сум 29 тиен соратып алганда.

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

ТАТАРСТАННЫҢ 105 җәүһәре
барысы тик Татарстанда

ТАБЫЛДЫҢМЫ, ВЛАДИМИР ИЛЬИЧ?

Яшь Владимир Ульяновның бюсты гаҗәпләндерергә сәләтле-ме? Бигрәк тә Казандагы Ленин музееның запаснигында озак еллар ятканы? Гаҗәпләндерә икән бит! Шактый таушалган хәлдә булуы сәбәпле, реставраторлар кулына тапшырылган гипс юлбашчы чыннан да зур шау-шу уятты. Белгеч, бюстны «төзәтергә» тотынгач, гипс гәүдәдә күренер-күренмәс хә-рефләр һәм саннарга игътибар итә: БУ 1970. Җентекләп өйрәнү шуны ачыклый: автор имзасы һәм дата икән болар. БУ – БА-КЫЙ УРМАНЧЕ инициаллары, ә 1970 – бюстның эшләнү елы. Күрәсең, скульптураны Бакый Урманче 1970 елда В.И. Ленин-ның 100 еллыгына багышлап эшләгән. Шунысын да билгеләп үтик: Казандагы Урманче музеенда Ленинның оста тарафын-нан 1964 елда иҗат ителгән мәрмәр сыны саклана. Ә инде яшь Владимир Ульяновның Урманче эшләгән бюсты хәзергә кадәр югалган дип санала иде.

© «Татарстан» журналы

WWW.PROTATARSTAN.RU

ЭЧТӘЛЕК

акыллы гамәлләр

6. Дуслыкка чикләр юк
«Татарстан» сорауларына дустанә илләрнең консуллары җавап бирә

22. Бер-береңне ишетү – гади фән
Чит ил кайчан туган илгә әверелә

26. Фәнни юнәлешле мәхәббәт тарихы
Әфган егете Казанны ничек сайлаган

28. Бер сменага – 350 километр
Мәхмүтҗанга эш ни өчен ял булып тоела

30. Күрәгә һәм мәрхәмәт дипломатиясе
Ул илләрне һәм кешеләрне ничек якынайта

32. Туган якка юл
Уй-ниятләр һәм хыяллар кайчан юкка чыга

36. Барыбыз да бер гаилә булып
Республикада чит ил вәкилләре ничек яши һәм эшли

38. Татарстан 2025. Мөһим казанышлар
Узып баручы ел нәрсәләр белән истә кала

40. Көнчыгышка таба
Зур логистика проекты икътисад файдасына ни рәвешле эшли

42. Ясалма фәһем намуссыз кулланучыларга каршы
Нейрочелтәр электр энергиясен урлаучыларны ничек ачыклый

игелекле эшләр

54. Балалар киносы серләре
Бу турыда «Шкодники» балалары ни сөйли

62. Киләчәкне төзүчеләр
Балаларны лидерлыкка, ясалма фәһемгә һәм Арктика проектларына кайда әзерлиләр

72. Яраткан Яңа ел сые
Адвокат Надежда Моратова аны искиткеч тәмле итеп ясый

мәңгелек кыйммәтләр

82. Гамьле әңгәмә
Бездә кунакта – тарихчы Гамирҗан Дәүләтшин

86. Китап киштәсе
Бүгенгенең «зур» китаплары арасынданиләр бар

88. Татар авыллары
Чал тарихлы Түбән Бәрәскә

94. Казанның агач архитектура һәйкәлләре
Эммануил Пёльцам йорты ничек сакланган

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта: protatarstan.ru

Фото: lenin.tatmuseum.ru

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

01.12

Сергей Иванов, Россия Фәннәр академиясе В. А. Стеклов исем. Математика институтының Санкт-Петербург бүлеге геометрия һәм топология лабораториясенең төп фәнни хезмәткәре, – Казанда Н. И. Лобачевский исемендәге Халыкара премияне алганнан соң:

«

– Фән яхшы эшләгәндә, болай була: кеше үзе теләгән әйбер белән шөгыльләнә, ә моның өчен аңа әле хезмәт хакы да түлиләр. Ул тегесе белән дә, бусы белән дә элемтәне кабул итеп бетерә алмый. Минем иң баштан ук шулай килеп чыкты. Бу яктан карьера үсешен планлаштыру мөмкин түгел: сине үзе эзләп тапкан бурычларны хәл итәсең. Әгәр килеп чыга икән – яхшы, әгәр юк икән, мөгаен, башка берәр өлкәне сайларга кирәктер.

02.12

Илнур Рәхимов, «Казан Кремле» музей-тыюлыгы» ДБУ директоры, – Савицкий исемендәге музей (Нукус) һәм «Яңа Иерусалим» музее тупланмаларындагы ядкәрләрне берләштергән «Җиһаннар балкышы» күргәзмәсе ачылышында:

«

– Милли төрлелекне берләштергән Россия һәм Үзбәкстан Республикасы – гаять бай тарихка, мәдәнияткә һәм рухи тормышка ия ике үзенчәлекле төбәк. Алар арасында мәдәни диалог – үткәннәргә хөрмәт кенә түгел, киләчәк өчен стратегик мөмкинлекләр эзләү дә. Мәдәни алмашулар ике якны да баета, үзара аңлашуны яхшыртырга этәргеч бирә һәм барлык өлкәләрдә дә уңышлы эшчәнлек мохите тудыра.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

28.11

Ринат Садыйков, Лисичанск һәм Рубежное шәһәрләрен торгызу эшләренә җитәкчелек итүче ТР Премьер-министры урынбасары, – әлеге шәһәрләрдәге яшьләр активы белән очрашуда:

«

– Үзгәрешләр әлеге идеяләрне тормышка ашырырга әзер кешеләрдән башлана. Әгәр яшьләр үз шәһәрләрендәге социаль һәм икътисадый үсеш процессларының төп авторлары булырга тели икән, бу тизлекле үсешкә зур өмет уята! Яшьләр китми, алар укыйлар, эшлиләр, гаилә төзиләр, иҗат итәләр. Без мондый системалы якын килүне хуплыйбыз.

Фото: prav.tatarstan.ru, tatar-inform.ru

игелекле эшләр

акыллы гамәлләр

мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

«Татарстан» **кем** белән 105 ел буена дус

Татарстанда **ничә** кытайлы яши

Ни өчен Казан – мультимәдәни башкала

Кемнәр Татарстанда үзен өйдәгечә хис итә

Ни өчен читтән килүче мигрантлар Татарстанны сайлый

ДРУЖБА НАРОДОВ
СССР

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНДА ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫНЫҢ 105 ЕЛЛЫГЫ

Декабрь аенда «Татарстан» журналына 105 яшь тула. СССРда иң беренчеләрдән булып оешкан массакүләм мәгълүмат чарасы була ул. 1977 елда, «Татарстан коммунисты» (русчасы – «Коммунист Татарии») дип аталган чакта, басмабызга 1977 елда Халыклар Дуслыгы ордены тапшырыла. Басма социалистик илләр арасындагы бердәмлекне һәм хезмәттәшлекне үстерүгә, тынычлыкны, халыклар арасында дуслык мөнәсәбәтләрен ныгытуга керткән өлеше, шулай ук хезмәт ияләрен коммунистик тәрбияләү буенча нәтиҗәле эшләгән һәм Советлар Союзында, аерым алганда, ТАССРда яшәүче халыкларның тормышын даими яктыртканы өчен шундый абруйлы бүләккә лаек дип табыла. Журнал бүген дә Татарстанда, күрше төбәкләрдә, хәтта чит мәмләкәтләрдә яшәүче төрле милләт халыклары турында язуын дәвам итә. Бүген безне 105 еллык дустанә мөнәсәбәтләр бәйли. Әлеге матур дата уңаеннан күршеләребез дуслык серләре белән уртаклаша, чөнки чын дуслыкка бернинди дә чикләр юк. Казанда эшләүче төрле ил консуллары* «Татарстан» журналының түбәндәге сорауларына җавап бирә:

1. **ТАТАРСТАНДА СЕЗНЕҢ ИЛНЕҢ КҮПМЕ ВӘКИЛЕ ЯШИ ҺӘМ СЕЗДӘ НИКАДӘР ТАТАРСТАНЛЫ ГОМЕР ИТӘ?**
2. **СЕЗНЕҢ ИЛДӘ ТУЫП-ҮСКӘН, ӘММА КАЗАНГА КҮЧЕНГӘН ЯКИ БИРЕГӘ КУНАККА, ЭШ БЕЛӘН КИЛГӘН КЕШЕЛӘРНЕҢ РЕСПУБЛИКАБЫЗ ТУРЫНДА ФИКЕРЛӘРЕ НИНДИ?**
3. **СЕЗНЕҢЧӘ, ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫНЫҢ СЕРЕ НӘРСӘДӘ?**
4. **ТАТАРСТАНДА ЯРАТКАН УРЫННАРЫГЫЗ БАРМЫ? БИРЕГӘ БЕРЕНЧЕ МӘРТӘБӘ КИЛГӘН КУНАКЛАРНЫ ИҢ ӘҮВӘЛ КАЯ АЛЫП БАРЫР ИДЕГЕЗ?**

** Алга таба илләрнең консуллыклары алфавит тәртибендә бирелде.*

ВИКТОР ЩЕТЬКО,

Беларусь Республикасының Россия Федерациясендәге Илчелегенең Казан бүлеге җитәкчесе

РОССИЯЛЕЛӘР БЕЛӘН БЕЗНЕҢ КАН ТӨРКЕМЕ БЕР

1. БҮГЕН ТАТАРСТАНДА БЕЛАРУСЬ РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ КҮПМЕ ВӘКИЛЕ ЯШИ ҺӘМ СЕЗДӘ НИКАДӘР ТАТАРСТАНЛЫ ГОМЕР ИТӘ?

– Төгәл генә мәгълүмат юк. Союздаш дәүләт шартлары буенча, гражданнарның ирекле күчеше бар, ә 90 көнгә кадәр икенче илдә булу бөтенләй контрольдә тотылмый. Әмма Татарстанда 4–4,5 меңгә кадәр белорус кешесе һәм Беларусь Республикасы территориясендә 8–8,5 меңгә кадәр татар кешесе булуы турында әйтә алабыз.

Сүз уңаеннан, бездә татарларның иң күпсанлы диаспорасы Ивье (Гродно өлкәсе) һәм Узда (Өзәңге; Минск өлкәсе) шәһәрләрендә дип исәпләнә. Бер фараз буенча, Узда шәһәре атамасы белән Урда ханына бурычлы. Бу якларга һөҗүмнәрнең берсендә ул атының бик кыйммәтле,

Фото: Александр Ефремов

үзе өчен үтә кадерле йөгәнен югалткан. Шуннан: «Узда, узда...» – дип, арлы-бирле йөренеп, йөгәнне эзләгәннәр, имеш. Бу сүз атама булып ябышып калган. Белмим, ни дәрәҗәдә дөрестер, әмма «узда»лылар үзләре шулай саный.

ТР Рәисенең Беларуська соңгы визиты вакытында Ивье диаспорасы вәкилләре аның белән очрашырга килде. Алар Рөстәм Нургалиевичка тарихи ватаныннан еракта ничек яшәүләре хакында бәян итте.

2. БЕЛАРУСЬТА ТУЫП-ҮСКӘН, ӘММА КАЗАНГА КҮЧЕНГӘН ЯКИ БИРЕГӘ КУНАККА, ЭШ БУЕНЧА КИЛГӘН КЕШЕЛӘРНЕҢ РЕСПУБЛИКАБЫЗ ТУРЫНДА ФИКЕРЛӘРЕ НИНДИ?

– Мисал китерәм. Ноябрь уртасында Казанга «Динамо-Минск» хоккей клубының якынча йөз ярым җанатары килде. Алар Татарстан башкаласына таң калып, биредә ничек каршылауларына шаккатып, үзара җылы дуслык мөнәсәбәтләренә куанып кайттылар.

Беларусь делегацияләре елына ике-өч тапкыр Татарстанга килә, димәк, сезнең республикадан да шулкадәр үк делегация безгә бара, дигән сүз. Кайчандыр безнең Президент Александр Григорьевич Лукашенко билгеләп үткәнчә, белорус кешесе, Татарстанга килеп, әдәп, пөхтәлек, тәртип, матурлык, кече күңеллелек белән очраша, ул монда үзен уңайлы хис итә.

3. СЕЗНЕҢЧӘ, ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫНЫҢ СЕРЕ НӘРСӘДӘ?

– Сезнең белән безнең очракта – иң әһәмиятлесе, билгеле, ышаныч. Теләсә нинди катлаулы вазгыятьтә бер-береңә таянырга мөмкин булу – бу зур нәрсә. «Дуслар бәладә танылa» дигән әйтемне бүген, заманына күрә бераз үзгәртеп, «дуслар санкцияләр вакытында таныла» дияргә мөмкин. Безнең ике ил дә, кискен ихтыяҗ тугач, бер-берсенә иңен куйды һәм терәк булды.

Татарстан Республикасына килгәндә, Россия Федерациясендә сәүдә әйләнеше буенча ул Мәскәү, Мәскәү өлкәсе, Санкт-Петербург һәм Ленинград өлкәсеннән соң бара. Беләсезме, безнең илләр үзара кан төркеме дә, резус факторы да туры килгән донорлар кебек. Алар теләсә кайсы вакытта бер-берсенә ярдәмгә килергә әзерләр. Шулай булгач, россиялеләр белән безнең кан төркеме бер, дип шикләнми әйтергә мөмкин.

4. ТАТАРСТАНДА ЯРАТКАН УРЫННАРЫГЫЗ БАРМЫ? БИРЕГӘ БЕРЕНЧЕ МӘРТӘБӘ КИЛГӘН КУНАКЛАРНЫ ИҢ ӘҮВӘЛ КАЯ АЛЫП БАРЫР ИДЕГЕЗ?

– Печищи авылына. Беренчедән, анда Белоруссиянең халык шагыйре Янка Купаланың искиткеч мемориаль музее урнашкан, андый тагын бер музей Минск шәһәрендә генә бар. Икенчедән, музейдан Иделнең текә ярына күтәрелсәң, күзәтү мәйданчыгына эләгәсең. Ә аннан Иделгә һәм Казанга гаҗәеп манзара ачыла. Елганың да, шәһәрнең дә олы куәтен тоясың.

Җәй көне кунакларны шулай ук Лаешка алып барыр идем. Без гаиләм белән анда еш барабыз, кызыма «Кама диңгезе»ндәге пляж бик ошый. Шундагы бер җирле фермер белән дә таныштык, ул җитештергән төрле авыл хуҗалыгы продукциясен сатып алабыз. Каклаган үрдәге – телне йотарлык! Бездә дә үрдәкне күп үстерәләр, әмма ул бөтенләй башка: белорусныкы – симез, ә татарныкы күбрәк тыгыз тәнле, итле. Белмим, бу нәрсә белән бәйледер, ләкин – факт. Ул үрдәкне без, чәкчәк, казылык белән бергә, туган якка отпуск вакытында кайтканда күчтәнәчкә алабыз.

Әлбәттә, кунакларны татар чәе белән дә сыйлар идем! Мин хәзер аның җанатары. Ничек соң татар чәенә шулай хирысланып киттем, дисезме? Бервакыт Алабугадан кайтып киләбез, ә юлда палаткалар тора: ни генә сатылмый, күз камашырлык... Шундагы бер хатын миңа шәмәхә чәчәкле кипкән үләннәр бәйләмен сонды бит. Бу мәтрүшкә икән, өйдә хатын аны чәй белән пешерде һәм ул безгә бик нык ошады. Бигрәк тә бал катып эчсәң, искиткеч тәмле булып чыкты. Җитмәсә, тынычландыра торган эффектка ия, ә дипломатларның эше нервларны какшата, үзегез аңлыйсыз. Беларусьта яшәгәндә мин кофеман идем, ә Татарстанда чәй өчен үлеп китә торган адәмгә әйләндем дә куйдым! Инде хәзер чәй җанлы булып калырмын да, мөгаен.

ЕРЛАН ИСКАКОВ,

Казахстанның Казандагы Генераль консулы

КАЗАН – МУЛЬТИМӘДӘНИ МӘРКӘЗ

Фото: Виктория Зубова

1. ТАТАРСТАНДА КАЗАХСТАННЫҢ КҮПМЕ ВӘКИЛЕ ЯШИ ҺӘМ СЕЗДӘ НИКАДӘР ТАТАРСТАНЛЫ ГОМЕР ИТӘ?

– Төгәл статистиканы болай гына әйтү шактый катлаулы, чөнки ул даими үзгәреп тора. Кайбер мәгълүматларга караганда, Татарстанда якынча ике мең ярым казах кешесе яши. Тарихи яктан караганда, аларның күбесе монда Советлар Союзы чорында ук килгән, шуннан бирле төпләнеп калган. Казанда Казахстаннан студентлар бик күп – ел саен меңнән артык кеше укырга килә.

Әмма хәзер башка тренд та барлыкка килде – россиялеләр Казахстанга белем алырга бара. Казах дәүләт университеты филиалын хәтта ерак Омск шәһәрендә дә ачты. Шулай булгач, гуманитар өлкәдә безнең хезмәттәшлек даими рәвештә киңәя бара, дия алабыз.

Казахстанда күпме Татарстан кешесе яшәгәнен әйтүе кыен. Якынча статистика бар: елына 350 мең тирәсе Россия кешесе Казахстанга килә, ди безгә саннар. Казахстанда күпме этник татар яши, дип сорасагыз, әйтә алам: 220 меңләп.

2. КАЗАХСТАНДА ТУЫП-ҮСКӘН, ӘММА ТАТАРСТАНГА КҮЧЕНГӘН ЯКИ БИРЕГӘ КУНАККА, ЭШ БУЕНЧА КИЛГӘН КЕШЕЛӘРНЕҢ РЕСПУБЛИКАБЫЗ ТУРЫНДА ФИКЕРЛӘРЕ НИНДИ?

– Үз исемемнән шуны әйтә алам: Татарстанда яшәү бик уңайлы. Социаль тормыш гаять яхшы оештырылган: мәктәпләр, балалар бакчалары, театрлар, кинотеатрлар, сәүдә үзәкләре бар… Болар барысы да тормыш сыйфатының югары дәрәҗәсен күрсәтеп тора.

Мин үземне Казанда Алматыдагы кебек хис итәм. Ватандашларым кайчак: «Казанда нәкъ Алматыдагы кебек, таулар гына җитми», – дип шаяртырга ярата. Ә менә архитектура бик охшаш.

Минемчә, татарларга хас төп сыйфатларның берсе – искиткеч кунакчыллык. Бу – Казанның, Татарстанның йөзе, асыл билгесе. Кешеләр бик хәерхаһлы, үзара дустанә мөнәсәбәттә. Татарстан һәрвакыт Европа белән Азия арасында күпер булырга омтылды, бу, чыннан да, шулай. Мин барысына да әйтәм: Казан ул – мультимәдәни мәркәз. Биредә бик күп этнослар яши. Республика хакимиятенең башка халыклар һәм илләр белән дуслыкка омтылуын һәм файдалы багланышларны киңәйтүгә йөз тотуын Казанда дипломатик вәкиллекләрнең хәйран булуы да раслый.

3. СЕЗНЕҢЧӘ, ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫНЫҢ СЕРЕ НӘРСӘДӘ?

– Миңа калса, монда да шул ук кунакчыллык төп нигез булып тора. Һәрвакыт кисешү нокталарын эзләргә кирәк. Татарлар белән казахлар – бер-берсен гасырлар буе белгән ике халык. Алар һәркайсы үз тәңгәллеген дә саклап кала алган, шул ук вакытта сәүдә, дин, мәгариф буенча яхшы эшлекле, дустанә мөнәсәбәтләр дә урнаштырган. Мәдәнияттә дә кисешүләр күп бездә. Мәсәлән, Габдулла Тукай кайчандыр безнең Уральскида яшәгән, сезнең симфоник оркестрыгызның дирижеры Фуат Мансуров – тумышы белән Казахстаннан… Казахстаннан – Татарстанга, ә Татарстаннан Казахстанга күпме мәдәният эшлеклесе күчеп урнашуын тагын бик күп мисаллар белән раслап була. Татар теле казах теленә шактый якын. Һәм болар барысы да – безнең үзара дуслыкның иге-чиге булмаган кадерле чыганагы.

4. ТАТАРСТАНДА ЯРАТКАН УРЫННАРЫГЫЗ БАРМЫ? БИРЕГӘ БЕРЕНЧЕ МӘРТӘБӘ КИЛГӘН КУНАКЛАРНЫ ИҢ ӘҮВӘЛ КАЯ АЛЫП БАРЫР ИДЕГЕЗ?

– Иске Татар бистәсенә, «Казан Арбаты» – Бауман урамына. Кунакларны шулай ук Казансу яр буена һәм «Урам» паркына да алып барабыз – сокланып туя алмыйлар. Аннары үзләренә Зөя утрау-шәһәренә барырга киңәш итәбез.

Татарстанда матур урыннар бик күп, һәммәсен барып күрергә вакытлары гына җитсен. Хәзер менә Камал театрының яңа бинасы – туристларны җәлеп итеп торган урыннарның берсе. Безнең кунакларга да ул кызык булыр, дип уйлыйм. Гомумән, минем карашка, Казан Россиянең туристлык башкаласы исеменә тулаем лаек. Казахстанлылар, отпуск вакытында Россиягә килгәндә, Казанны һичшиксез күреп калырга омтыла.



СЯН БО,

Кытай Халык Республикасының Казандагы Генераль консулы

КЫТАЙ ҺӘМ РОССИЯ – ЯХШЫ КҮРШЕ, ЧЫН ДУС ҺӘМ ЫШАНЫЧЛЫ ПАРТНЁРЛАР

1. БҮГЕН ТАТАРСТАНДА КЫТАЙНЫҢ КҮПМЕ ВӘКИЛЕ ЯШИ ҺӘМ СЕЗДӘ НИКАДӘР ТАТАРСТАНЛЫ ГОМЕР ИТӘ?

– Татарстан Республикасы – күпмилләтле төбәк, халыкларның үзара гармониядә яшәү үрнәге ул. Мәгълүм булганча, Татарстан Республикасында хәзерге вакытта 2 меңнән артык Кытай гражданы эшли һәм укый. Аларның күбесе – Казан федераль университетында, Казан дәүләт консерваториясендә һәм башка югары уку йортларында белем алучы студентлар. Быел ноябрь аенда Казан дәүләт консерваториясе инде өченче тапкыр рәттән Кытай студентларының махсус концертын уздырды, бу аларның укудагы тырышлыгына һәм музыкаль талантларына югары бәя, шулай ук Кытай белән Россия арасындагы буыннан буынга тапшырылган дуслыкның чагылышы булып та тора. Биредә шулай ук Казан, Чаллы, Түбән Кама һәм бүтән шәһәрләрдә сәүдә, җитештерү һәм башка эшчәнлек белән шөгыльләнә торган Кытай компанияләре һәм эшкуарлары бар.

Соңгы елларда Кытай – Россия мөнәсәбәтләренең тиз үсүе нәтиҗәсендә, бигрәк тә узган елның октябрендә Казанда узган БРИКС саммитында КХР Рәисе Си Цзиньпин катнашканнан соң, Татарстан Республикасының Кытай белән бәйләнешләре

Фото: Александр Ефремов

һәм хезмәттәшлегә тагын да киңәя төште. Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов Кытай белән хезмәттәшлекне көчәйтүгә зур игътибар бирә һәм соңгы өч елда җиде тапкыр Кытайда булды. Әлегә миндә Кытайдагы татарстанлылар саны турында төгәл мәгълүмат юк, әмма мин ышанам, Кытай – Россия мөнәсәбәтләренең динамик үсеше фонында, Шанхай – Казан кебек туры рейслар ачылу һәм Россия гражданнары өчен визасыз режимы кертелүгә бәйле рәвештә Кытайга туризм, эш һәм уку өчен барачак татарстанлылар саны һичшиксез артачак.

2. КЫТАЙДА ТУЫП-ҮСКӘН, ӘММА КАЗАНГА КҮЧЕНГӘН ЯКИ БИРЕГӘ КУНАККА, ЭШ БУЕНЧА КИЛГӘН КЕШЕЛӘРНЕҢ РЕСПУБЛИКАБЫЗ ТУРЫНДА ФИКЕРЛӘРЕ НИНДИ?

– Казанда өч елдан артык эшләү дәверендә мин Татарстанның Яр Чаллы, Алабуга, Әлмәт кебек шәһәр һәм районнарында булдым, Татарстан Республикасы җирле хакимиятләренең Кытай белән хезмәттәшлекне ныгыту теләген, шулай ук җирле халыкның кытайларга карата яхшы мөнәсәбәтен һәм ихласлыгын тойдым. Миңа Казанда эшләү һәм яшәү бик ошый.

Белүемчә, Кытай компанияләре, бизнесменнары һәм студентлары Татарстан Республикасындагы һәм Казандагы эшләреннән һәм тормышларыннан канәгать. Алар биредә социаль-икътисадый вазгыять тотрыклы, үсеш куәтле, дип саный, үзләрен бигрәк тә кешеләрнең кунакчыл, ихлас һәм мәрхәмәтле булуы сокландыра. Татарстан Республикасы Хөкүмәте Кытай гражданнарына эш һәм уку өчен яхшы шартлар тудырды. Кытай гражданнары шулай ук төбәкнең социаль-икътисадый үсешенә һәм ике ил халкы арасында дуслыкны ныгытуга актив өлеш кертә.

3. СЕЗНЕҢЧӘ, ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫНЫҢ СЕРЕ НИДӘ?

– Кытай һәм Россия – яхшы күрше, чын дус һәм ышанычлы партнёрлар. Быел Кытай белән Россия арасында дипломатия мөнәсәбәтләре урнаштыруның 76 еллыгы һәм фашистларга каршы Икенче бөтендөнья сугышында Җиңүнең 80 еллыгы билгеләп үтелә. Гасырның өч чирегe дәвамында Кытай – Россия мөнәсәбәтләре өзлексез үсә, ә ике халык арасындагы дуслык ныгый гына бара, бигрәк тә Икенче бөтендөнья сугышы вакытында чыныга.

Ни өченме? Без үзара ихтирам һәм тигез хокуклылык саклыйбыз, төп мәнфәгатьләргә кагылышлы мәсьәләләрдә һәрвакыт бер-беребезгә булышабыз һәм һәр ил сайлаган үсеш юлына хөрмәт белән карыйбыз. Үзара нәтиҗәле хезмәттәшлек итәбез, уңышларга ирешәбез һәм илләребез белән халыкларыбызга файда китерәбез. Без һәр буында дуслыкка омтылабыз, Кытай Россия белән Дәүләт еллары, Тел еллары, Туризм еллары, Физик культура һәм спорт өлкәсендә Россия – Кытай хезмәттәшлеге еллары кебек һәм башка милли чараларны даими рәвештә уңышлы уздыра, бу халыклар арасында үзара аңлашуга, якынаюга тагын да ныграк ярдәм итә.

Кытай һәм Россия арасындагы мөнәсәбәтләр, шулай ук ике халык арасындагы элек-электән килгән дуслык бөтен дөнья өчен үрнәк булып тора. Минемчә, бер-береңә хөрмәт, тигез хокуклылык һәм үзара файдалы хезмәттәшлек, күп гасырларга сузылган җылы мөнәсәбәтләр – халыклар арасындагы дуслык сере менә шундадыр.

2026–2027 еллар Кытай һәм Россиядә Мәгариф еллары булачак. Ике як та үзара визасыз режим кертте, элемтәләр дә, ике ил халкы арасында гуманитар мөнәсәбәтләр дә тагын ныгыячак. Кытай һәм Россия халыклары арасындагы татулык буыннан буынга күчсен һәм мәңге дәвам итсен!

4. ТАТАРСТАНДА ЯРАТКАН УРЫННАРЫГЫЗ БАРМЫ? БИРЕГӘ БЕРЕНЧЕ МӘРТӘБӘ КИЛГӘН КУНАКЛАРНЫ ИҢ ӘҮВӘЛ КАЯ АЛЫП БАРЫР ИДЕГЕЗ?

– Кытай кунаклары арасында В.И. Ленинның Казандагы музей-йорты аеруча популяр, чөнки нәкъ менә монда яшь Ленин революцион юлга баскан – ә бу тарихи чор кытайларда зур кызыксыну уята. Кытай – Россия туристлык хезмәттәшлеге үсә барган саен, киләчәктә безнең туристлар Татарстан Республикасына Казанның уникаль шәһәр цивилизациясен тою һәм аның Мәскәү белән Санкт-Петербургтан аерылып торган күпмилләтле асылының гүзәллеге белән хозурлану өчен килерләр, дип уйлыйм. Т

Фото: Александр Ефремов

ЭРИК БЕЙШЕМБИЕВ,

Кыргызстан Республикасының Казандагы Генераль консулы

ТАТАРСТАН – ТРАДИЦИЯЛӘР ҺӘМ ҮСЕШ ГАРМОНИЯСЕ ҮРНӘГЕ

1. БҮГЕН ТАТАРСТАНДА КЫРГЫЗСТАННЫҢ КҮПМЕ ВӘКИЛЕ ЯШИ ҺӘМ СЕЗДӘ НИКАДӘР ТАТАРСТАНЛЫ ГОМЕР ИТӘ?

– Федераль миграция хезмәтенең соңгы мәгълүматларына караганда, Татарстан территориясендә Кыргызстан Республикасының 6159 гражданы яши. Күпчелеге Казанда – 3450 кеше, Чаллыда – 750, Әлмәт һәм Алабуга шәһәрләренең һәрберсендә якынча 300 кыргыз кешесе яши. Ватандашларыбыз, кагыйдә буларак, эш буенча килә, студентлар аз.

Татарстанның Кыргызстан Республикасындагы вәкилләренә килгәндә, 2023 ел мәгълүматлары буенча, бездә 26 мең Татарстан кешесе яшәве мәгълүм.

2. КЫРГЫЗСТАНДА ТУЫП-ҮСКӘН, ӘММА ТАТАРСТАНГА КҮЧЕНГӘН ЯКИ БИРЕГӘ КУНАККА, ЭШ БУЕНЧА КИЛГӘН КЕШЕЛӘРНЕҢ РЕСПУБЛИКАБЫЗ ТУРЫНДА ФИКЕРЛӘРЕ НИНДИ?

– Гомумән алганда, фикерләр әйбәт, аларга монда яшәү ошый. Татарстан үзен кунакчыллык, тотрыклылык һәм толерантлык дәрәҗәсе ягыннан югары күрсәткечләргә ия төбәк буларак танытты. Монда ватандашларыбызга уңайлы тормыш алып бару, укыту һәм эшчәнлеген җәелдереп җибәрү өчен барлык шартлар да тудырылган.

Җирле халыкның ачык, яхшы мөнәсәбәтен билгеләп үтәсе килә, алар Кыргызстан халыкларының мәдәни традицияләренә ихтирам белән карый. Күп кенә кыргызлар монда үзләрен өендәге шикелле хис итә: мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә үзләрен таба, иҗтимагый проектларда катнаша. Шулай ук һөнәри үсеш өчен мөмкинлекләрдән дә рәхәтләнеп файдалана.

Татарстан хакимияте белән кыргыз диаспорасы арасындагы хезмәттәшлекнең югары дәрәҗәдә булуын да әйтеп китәсе килә. Бу безнең илләр арасында үзара аңлашуны тагын да ныгытуга, милли үзенчәлекләрне саклауга һәм ике яклы элемтәләрне үстерүгә ярдәм итә. Моның өчен Татарстан хөкүмәтенә һәм шәхсән республика Рәисе Рөстәм Нургали улы Миңнехановка зур рәхмәт.

Диаспоралар белән әйбәт хезмәттәшлекнең ачык мисалы – Халыклар дуслыгы йорты эшчәнлеге. Анда ватандашларымның балалары кыргыз телен өйрәнә, комузда – милли уен коралында уйный, түгәрәкләргә йөри. Шулай итеп, алар, Кыргызстаннан читтә булсалар да, милли мәдәният һәм тел, гореф-гадәтләрдән читләшми.

3. СЕЗНЕҢЧӘ, ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫНЫҢ СЕРЕ НӘРСӘДӘ?

– Минемчә, ул бер-беребезгә хөрмәт белән карау, мәдәниятләребез һәм традицияләребез белән чын күңелдән кызыксыну. Шулай ук безне аермый, ә берләштерә торган нәрсәләрнең кадерен белү. Халыклар арасында үзара ышаныч хөкем сөргәндә, ачык аралашу һәм аңлашуга омтылыш булганда, хезмәттәшлек һәм үсеш өчен ныклы нигез бар, дигән сүз.

Кыргызстан белән Татарстан, мәдәни яктан төрлелек булуга карамастан, аның бердәмлек чыганагы булып хезмәт итә алуына ачык мисал. Без бер төрки тамырларга барып тоташабыз, тел ягыннан да бик якынбыз, шулай ук дин һәм мәдәниятләрнең уртаклыгын да билгеләп үтәр идем. Безнең халыкларны охшаш кыйммәтләр бәйли: өлкән буынны олылау, гаиләнә хөрмәт итү, белемгә һәм хезмәткә омтылу.

Мине Татарстанда мөселман гыйбадәтханәләренең христиан гыйбадәтханәләре белән янәшә торуы, һәр дингә тигез ихтирам булуы сокландыра. Бу Татарстанны башка төбәкләрдән аерып тора. Монда күпмилләтлелек, күпконфессиональлек, мультимәдәнилек хөкем сөрә.

Болар барысы да кардәшлек һәм үзара ярдәмләшү атмосферасын тудыра, ул елдан-ел ныгый бара. Шуңа күрә, мөгаен, халыкара чаралар үткәрү үзеге дә бирегә кучә: Казанда эре спорт чаралары, мәдәни, икътисадый һәм сәяси форумнар күпләп уза.

4. ТАТАРСТАНДА ЯРАТКАН УРЫННАРЫГЫЗ БАРМЫ? БИРЕГӘ БЕРЕНЧЕ МӘРТӘБӘ КИЛГӘН КУНАКЛАРНЫ ИҢ ӘҮВӘЛ КАЯ АЛЫП БАРЫР ИДЕГЕЗ?

– Казан – тарих, мәдәният һәм заманчалык үзара гармонияле рәвештә ярашкан, бербөтенне тәшкил иткән гаҗәеп шәһәр ул. Яраткан урыннарым арасында, һичшиксез, Татарстанның рухи һәм мәдәни мирасы символы булган Казан Кремле бар. Бу төбәкнең күпгасырлык тарихын чагылдырган һәм бергә яшәүче халыкларның дуслыгын аеруча күрсәтеп торган кадерле урын.

Кунакларга Кол Шәриф мәчетен һәм Благовещение соборын да күрсәтергә кирәк. Алар янәшә урнашкан һәм төрле дин вәкилләре арасында тату яшәү, үзара хөрмәт мөмкин булуын раслап тора. Сөембикә манарасын күрсәтеп, Казансу яр буена алып төшәр идем. Нәкъ менә шунда шәһәрнең заманча ритмын ишетергә һәм никадәр динамик үсеш алуын тоярга мөмкин.

Казанның элеккеге рухын саклап калган үзеген дә әйләнеп узарга ярамый. Әйтик, кабатланмас атмосферасы, милли ашлары һәм кунакчыллыгы белән танылган Бауман урамын. Татарстан башкаласыннан читтәрәк урнашкан Зөя утрау-шәһәрен һәм Болгар тарихи-археологик комплексын, һичшиксез, барып күрергә кирәк. Анда төбәкнең рухи тамырлары аеруча тирән сизелә.

Бу урыннарның һәркайсы Татарстанның бай мәдәниятен, традицияләрен һәм тарихын чагылдыра. Ә Татарстан белән кыргыз халкын, үз чиратында, күпгасырлык ихлас дуслык җепләре, тирән ихтирам бәйли.

Миңа татарстанлыларның аралашуда ачыклыгы, ярдәмчеллеге, башка мәдәният белән дин вәкилләренә ихтирамлы мөнәсәбәте бик ошый. Татарстанлылар хезмәт сөючәнлеге, кунакчыллыгы һәм югары аралашу культурасы белән аерылып тора. Бу сыйфатлар кыргыз халкының характерына да охшаш.

Татарстанлыларның үз традицияләрен саклап кала алуы һәм, бер үк вакытта, заман рухына йөз тотып үсү сәләте аеруча зур соклану уята. Бирегә халыкның үз тарихына, туган теленә, тамырларына сакчыл карашы сизелә. Әмма кешеләрдә инновацияләргә, мәгарифкә һәм прогресска омтылыш та бик зур. Рухи кыйммәтләрнең нәкъ менә шушылай заманча фикерләү белән ярашуы Татарстанны традицияләр һәм үсеш гармониясе ягыннан дөнья күләмендә үрнәк итә.

УГУР ЙЫЛМАЗ,

Төркия Республикасының Казандагы Генераль консулы

МӘДӘНИЯТ ҺӘМ ТЕЛЛӘРЕБЕЗ БИК ЯКЫН

1. БҮГЕН ТАТАРСТАНДА ТӨРКИЯНЕҢ КҮПМЕ ВӘКИЛЕ ҺӘМ СЕЗДӘ НИКАДӘР ТАТАРСТАНЛЫ ГОМЕР ИТӘ?

– Мәгълүм булганча, узган гасырларда, XX гасыр башында, бигрәк тә 1923 елда Төркия Республикасы игълан ителгәч, шактый күп Казан татары Төркиягә күчеп киткән. Хәзерге вакытта күп кенә Казан татары һәм Россиянең башка төбәкләре гражданнары безгә туристлар сыйфатында, гуманитар һәм мәдәни багланышлар, белем алу, бизнес булдыру һәм яшәү максаты белән килә. Төркия һәм Россия Федерациясе гражданнары арасында теркәлгән никахлар да күп. Элек Казан татарлары, нигездә, Искешәһәр һәм Конья провинцияләрендә төпләнгән. Бу шәһәрләр тирәсендә әле дә татар авыл-

Фото: Александр Ефремов

лары бар. Хәзерге вакытта, төгәл саны билгеле булмаса да, Искешәһәр, Конья, Анталья, Адана, Истанбул һәм Әнкарада шактый күп Казан татары яши дип исәпләнә. Искешәһәр һәм Антальяда Сабан туе үткәрелә, бу ике шәһәрдә Казан татарларының ассоциацияләре бар. Искешәһәрдәге ассоциациядә мин әле күптән түгел генә булдым.

2. ТӨРКИЯДӘ ТУЫП-ҮСКӘН, ӘММА КАЗАНГА КҮЧЕНГӘН ЯКИ БИРЕГӘ КУНАККА, ЭШ БУЕНЧА КИЛГӘН КЕШЕЛӘРНЕҢ РЕСПУБЛИКАБЫЗ ТУРЫНДА ФИКЕРЛӘРЕ НИНДИ?

– Ел саен 10 меңгә якын Төркия гражданы Казанга кыска вакытлы сәфәргә яки турист булып килә. Хәзерге вакытта 200 дән артык студентыбыз Татарстанда югары белем ала. Аларның күбесе КФУда укый. Төркия гражданнарының Казан һәм Татарстан белән кызыксынуы көннән-көн арта бара. Кызыксыну даирәсе – туризм, белем алу һәм бизнес. Монда инде без, генконсуллык буларак, хезмәттәшлегебез төрле өлкәләрдә уңышлы үссен өчен тырышабыз. Төркия гражданнары, кагыйдә буларак, Казанда һәм Татарстанда үзләрен чит кеше итеп тоймый, безнең мәдәниятләр һәм телләребезнең якынлыгы үзара багланышларны һәм сәфәрләрне шактый җиңеләйтә.

3. СЕЗНЕҢЧӘ, ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫНЫҢ СЕРЕ НӘРСӘДӘ?

– Төркия һәм Татарстан халыкларының, иң әүвәл, мәдәният, тел, гореф-гадәтләр һәм рухи кыйммәтләр җәһәтеннән уртак яклары күп. Безнең халыклар гасырлар дәвамында сәүдә, мәдәният, мәгариф һәм дини кыйммәтләр аша һәрвакыт элемтәдә торган, аралашкан. Без сөйләшә торган тел, җырлый торган җырлар, хәтта мәкальләр дә бер-берсенә бик якын, чөнки безнең тамырлар уртак. Табигый ки, Төркия белән Татарстан арасында багланышлар бик нык һәм ышанычлы. Безнең дуслык һәм кардәшлек, үзара хөрмәт һәм ярату хисләребез рухи мирас, хезмәттәшлек һәм үсешебезгә карата охшаш күзаллауларга таяна. 2024 елда Төркия белән Татарстан арасында сәүдә күләме 5,3 миллиард АКШ долларына җитте. Безнең Татарстанга турыдан-туры инвестицияләребез якынча 3 миллиард АКШ долларын тәшкил итә. Үзара мөнәсәбәтләребез мәдәни якынлык белән генә чикләнми, алар сәүдә, сәнәгать, мәгариф, технологияләр, туризм һәм энергетика тармакларындагы динамик хезмәттәшлек нәтиҗәсендә тагын да тирәнәйде һәм баеды.

4. ТАТАРСТАНДА ЯРАТКАН УРЫННАРЫГЫЗ БАРМЫ? БИРЕГӘ БЕРЕНЧЕ МӘРТӘБӘ КИЛГӘН КУНАКЛАРНЫ ИҢ ӘҮВӘЛ КАЯ АЛЫП БАРЫР ИДЕГЕЗ?

– Татарстан – бик матур республика. Табигать һәм җир асты ресурсларының байлыгы, уңайлы географик урыны бай тарихи мирасны һәм мәдәни төрлелекне тагын да кызыклырак итә. Казаннан тыш, мин Әлмәт, Яр Чаллы Алабугада, шулай ук Мамадыш, Болгар, Биектау, Байлар Сабасы, Теләче һәм Иннополиста булдым. «Әлдермешкә кайтам әле» җырын искиткеч матур итеп башкарып, Хәния Фәрхи данын бөтен дөньяга тараткан Әлдермеш авылын да күрдем... Бу урыннарның барысы да бик матур, уңайлы, төзек. Казан, һичшиксез, татар мәдәнияте һәм тулаем Россия Федерациясе өчен генә түгел, ә барлык төрки халыклар өчен дә тарихи һәм рухи әһәмияткә ия үзенчәлекле шәһәр. Төньяк һәм көньяк, көнчыгыш һәм көнбатыш кисешкән урында урнашкан бу шәһәр гасырлар дәвамында бик мөһим фән, сәнгать, сәнәгать һәм мәдәният үзәге булган. Казанда миңа барыннан да бигрәк Иске Татар бистәсе, Казан Кремле, «Туган авылым» комплексы һәм Казансу елгасы ярындагы җәяүлеләр зонасы ошый. Казанга килүче кунакларны без беренче чиратта нәкъ менә шушы урыннарга алып барабыз.

Татарстан халкы киң күңелле, кулач йөзле, ихлас, тыныч, бердәм, тырыш, тиктормас һәм зирәк. Мин татар халкын бик ихтирам итәм. Ул кунакчыл һәм булдыклы, үз традицияләрен һәм рухи кыйммәтләрен кадерли, мәдәни мирасын саклый. Болар барысы да төрек халкына да бик якын.

НОДИРЖОН КАСЫЙМОВ,
Үзбәкстан Республикасының Казандагы Генераль консулы

БЕЗНЕ БИК КҮП НӘРСӘ БЕРЛӘШТЕРӘ

1. БҮГЕН ТАТАРСТАНДА ҮЗБӘКСТАННЫҢ КҮПМЕ ВӘКИЛЕ ЯШИ ҺӘМ СЕЗДӘ НИКАДӘР ТАТАРСТАНЛЫ ГОМЕР ИТӘ?

– Беренчедән, «Татарстан» журналы редакциясенә нәтиҗәле хезмәттәшлек өчен рәхмәт белдерәсем һәм, мөмкинлектән файдаланып, Генераль консуллык исеменнән дә, шәхсән үз исемемнән дә якынлашып килүче истәлекле дата – «Татарстан» журналының 105 еллыгы белән котлыйсым килә. Басма коллективына чын күңелдән һөнәри уңышлар, иҗади илһам, яңа идеяләр, бәхет һәм иминлек телим.

Мәгълүм булганча, безне күпгасырлык тарихи, сәяси, икътисадый, фәнни һәм мәдәни мөнәсәбәтләр бәйли.

Татарлар тормышы Үзбәкстан белән моннан берничә гасыр элек үк тыгыз бәйләнгән. Безне охшаш милли гореф-гадәт һәм традицияләр, уртак төрки телләр гаиләсе, мәдәният һәм дин якынайта.

Фото: Виктория Зубова

Күп кенә күренекле татар дин белгечләре һәм галимнәре, мәсәлән, фәлсәфәче һәм мәгърифәтче Шиһабетдин Мәрҗани, рухани һәм дөньяви элита әзерли торган Бохарада белем алган.

Татарстанда 15 меңгә якын ватандашыбыз бар. Ә Үзбәкстанда яшәүче татарлар саны инде 400 меңнән артып китә, дип уйлыйм. Алар барысы да, Үзбәкстандагы 130 дан артык башка милләт вәкилләре кебек үк, дус һәм тату яши. Чөнки Үзбәкстан – тиз үсә торган икътисад, искиткеч демографик тенденция, дуслык һәм бердәмлек атмосферасы ул.

Күптән түгел мин «Үзбәкстан татарлары» энциклопедик басмасын тәкъдир итүгә багышланган бик әһәмиятле чарага чакырылган идем. Китапта Үзбәкстан белән Татарстан арасындагы күпгасырлык мәдәни-икътисадый багланышлар һәм тарихи традицияләр турында язылган.

Басма Татарстан Фәннәр академиясенең М. Хәсәнов исемендәге Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты тарафыннан Үзбәкстандагы коллегалары белән берлектә әзерләнгән.

Ни өчен бу чара турында сөйлимме? Чөнки бик күп татар кешесе кояшлы Үзбәкстанда яшәгән елларын бүгенге көнгә кадәр зур җылылык һәм сагыну белән искә ала, дуслыкта-татулыкта узган көннәрне хәтерендә яңарта – шуңа бик кадерле хатирәләр бу.

Әлеге чарада Татарстанның күренекле эшлеклеләре ике кардәш халыкның тарихы һәм мәдәниятендәге мөһим вакыйгалар турында сөйләде. Моңа бик күңелем булды, чөнки безне традиция, мәдәният, гаилә тормышына кагылышлы бик күп уртак кыйммәтләр берләштерә.

2. ҮЗБӘКСТАНДА ТУЫП-ҮСКӘН, ӘММА КАЗАНГА КҮЧЕНГӘН ЯКИ БИРЕГӘ КУНАККА, ЭШ БУЕНЧА КИЛГӘН КЕШЕЛӘРНЕҢ РЕСПУБЛИКАБЫЗ ТУРЫНДА ФИКЕРЛӘРЕ НИНДИ?

– Бу сорауга икенче яктан карап җавап бирәсем килә: Татарстанга килгән чит ил кунакларын иң беренче нәрсә гаҗәпләндерә? Иманым камил: аларны биредә яшәүче кешеләрнең җылылыгы, ихтирамлы мөнәсәбәте һәм хезмәт сөючәнлеге таң калдырадыр.

Чит илләр, бигрәк тә Үзбәкстан төбәкләре белән хезмәттәшлектә Татарстанның икътисадта да, фәнни-гуманитар юнәлештә дә потенциалы һәм үсешкә омтылышы мактауга лаек.

1993 елдан Татарстанның Үзбәкстандагы вәкиллеге уңышлы эшләп килә. 2019 елдан Казанда Үзбәкстанның Генераль консуллыгы эшли, ул Россия Федерациясенең бөтен Идел буе федераль округын колачлый.

Безнең төп бурычыбыз – бер яктан гражданнарыбызга консуллык-хокукый юнәлештә ярдәм күрсәтү, икенче яктан – инвестицион, сәүдә-икътисадый һәм фәнни-гуманитар хезмәттәшлекне көчәйтү. Хәер, ул хәзер гел үсештә: товар әйләнеше дә, мәдәният алмашу да, туризм да, студентлар алмашу да елдан-ел арта гына бара.

Тагын шуны да аерып әйтү мөһим: Казан университетының беренче филиалы нәкъ менә Үзбәкстанда, Җиззах шәһәрендә ачылды, һәм быел беренче белгечләр дә чыгарылды инде.

3. СЕЗНЕҢЧӘ, ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫНЫҢ СЕРЕ НӘРСӘДӘ?

– Беләсезме, халыклар дуслыгының сере шунда дип уйлыйм: безнең буынның да, варисларыбызның да тарихи кыйммәтләрне, телләрне, гореф-гадәтләрне белеп һәм бер-берсен хөрмәт итеп, үзара ихтирам белдереп яшәвендә.

4. ТАТАРСТАНДА ЯРАТКАН УРЫННАРЫГЫЗ БАРМЫ? БИРЕГӘ БЕРЕНЧЕ МӘРТӘБӘ КИЛГӘН КУНАКЛАРНЫ ИҢ ӘУВӘЛ КАЯ АЛЫП БАРЫР ИДЕГЕЗ?

– Татарстан – кунакчыл төбәк, Үзбәкстан кунакларын гел югары дәрәҗәдә каршы ала. Беренче чиратта Казанны, ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы объектларын бар матурлыгында күрсәтергә телиләр. Татарстанда кешеләргә уңайлы булсын өчен бик күп эш башкарыла. Моны барысы да билгеләп үтә.

Без гаиләм, балалар белән «Урам» паркында, Кремль яр буенда йөрергә яратабыз. Болар барысы да җәяү йөрү өчен бик матур урыннар – һәммәсе Татарстанда яшәүчеләрнең дә, якындагы төбәкләрдән килеп, һәр ял көнен Казанда уздырырга омтылучы туристларның да рәхәт ялы өчен җайланган.

Фото: tatar-inform.ru

«Татарстан» журналының махсус проекты

КИЛЕП ТУЛДЫЛАРМЫ? РӘХИМ ИТЕГЕЗ!

Алар күп яктан безнең кебек үк, гәрчә һәрвакытта да татар һәм рус телләрен белмәсәләр дә. Араларында безнең кебек үк законнарны бозмаучылар да, кайчак аны үтәп бетермәүчеләр дә бар. Алар безнең якларга бәхетләрен сынарга, эшләргә һәм укырга килгән. Кемдер – вакытлыча, кемдер – бөтенләйгә. Аларның тормышка карашлары, гореф-гадәтләре төрле, кайвакыт безнекеннән үзгә. Ә бездә, кызганычка, аларга мөнәсәбәт төрле. Бәлки, бу һәрвакытта да ап-ачык булганнарны тулысынча аңлап бетермәгәнгә шулайдыр.

Мигрантларны җәлеп итмичә, без бүген икътисадыбыз алдында торган бурычларны хәл итә алмаячакбыз, дип искәртте Татарстан Рәисе дә. Язмыш җилләре бирегә китергән мигрантларның үзләрен безнең республикада, илдә ничек тотачаклары алардан гына түгел, кабул иткән якның мөнәсәбәтеннән дә тора. «Татарстан» журналының махсус чыгарылышы шул хакта.

БЕР-БЕРЕҢНЕ ИШЕТЕП ЯШӘҮ

Евгения Чеснокова

Абдулбосит русча акцент белән, әмма шактый йөгерек сөйләшә. Ә дүрт ел ярым элек Таҗикстаннан әти-әнисе белән Татарстанның Буа районына күченгәндә, малай русча бер авыз сүз белми, чөнки туган авылындагы мәктәптә рус теле бөтенләй укытылмый. Бүген ул рус теленнән дүртлегә укый, уку елы ахырында төп дәүләт имтиханы тапшырачак, бу сынауны яхшы үтәчәген белә.

РУСЧА КЫЧКЫРЫП УКУ…

Абдулбосит әти-әнисе белән Татарстанга күченгәндә, телне белмәгәннәрне укырга алмаска дигән канун булмаганга, русча бөтенләй белмәгән малай авыл мәктәбенең дүртенче сыйныфында укуын дәвам итә. Сыйныфташларым белән аралашу аркасында, көнкүрештә кулланыла торган сүзләрне шактый тиз өйрәндем, ди малай. Балалар да чит яклардан килеп урнашкан малайны ят итмиләр. Башта күбрәк ым, ишарәләр ярдәмендә аңлашалар. Тора-бара, әлбәттә, нормаль сөйләшкә күчәләр. Әмма мәктәптәге биремнәрне үтәү Абдулбоситка барыбер кыенрак бирелә.
Ә менә инде бер елдан Казанга күченгәч һәм 51 нче мәктәптә укый башлагач, җиңелрәк була, чөнки, беренчедән, ул инде русча яхшы аңлый, икенчедән, бу сыйныфта берничә якташы, хәтта үз авылындагы бер малай да була. Өстәвенә, бу мәктәптә Абдулбосит кебек балалар өчен рус теленнән өстәмә дәресләр дә каралган.
Һәм тагын бер нәрсә бар. 51 нче мәктәп башкаланың үзәк базарыннан ерак түгел – Кәрим Тинчурин урамында урнашкан. Янәшәдә – елга порты, автовокзал һәм тимер юл вокзалы. Казанга килүче күп мигрантлар базарда сәүдә итәләр, торакны да эш урыннарына якынрак табарга тырышалар. Шуңа аларның балалары күп еллар нәкъ менә әлеге мәктәпкә укырга йөри. Вакытлар үтү белән бу үзенә күрә җирле «фишкага» әверелә. Бүген мигрантлар бөтен шәһәрдән үз балаларын бирегә укырга йөртә. Мәсәлән, шул ук Абдулбосит Пулотов хәзер шәһәрнең Мәскәү районында яши. Ләкин көн саен еракка йөреп укуына зарланмый – 51 нче мәктәп аңа ошый. Руслар, татарлар, таҗиклар, тагын башка милләт вәкилләре укыган сыйныфта аның дуслары күп. Укытучыларның аларны аңлый белүе дә, яхшы мөнәсәбәте дә ошый. Рус теле дә инде алай авыр тоелмый.
«Ну, русча мин белмәгән сүзләр дә очрый, әмма мин дусларымнан сорыйм, алар аңлата, – ди ул. – Ә болай минем рус теленнән дүртле, 60–70 процент кагыйдәне беләм, өтерләр белән генә кыенрак әлегә…».
Ул әле русча кычкырып укырга ярата – бөтен сыйныф аны тыңласын. Рус әдәбиятыннан «Слово о полке Игореве» әсәреннән өзекне яттан сөйләвен искә төшерә. «Мөгаен, авыр булгандыр?» – дим. «Авыр!» – дип елмая Абдулбосит. Ә менә Пушкин һәм Чуковский әкиятләре – алары җиңелрәк, аларны бик кызыксынып укыган. Тагын, татар телен өйрәнү сәбәпле, аңа Тукай белән Җәлил дә ошый. Абдулбосит 9 нчы сыйныфтан соң имтиханнарны биргәч, мәктәптән китәм, ди.

Фото: авторныкы, 51 нче мәктәп архивыннан, mon.tatarstan.ru

Әлегә алга таба кайда укыячагын төгәл белми. Вариантлар төрле: бәлки, автомеханиклыкка укырга барыр, бәлки – медицина көллиятенә... Аның зур хыялы бар – стоматолог булу. Һәм, бәлки, Казанда түгел, Мәскәүдә үк укыр. Бүген гаиләсе Россия гражданлыгы алгач, үзенең киләчәген Россия белән генә бәйли. Ул үҗәт һәм тырыш егет. Теләгенә һичшиксез ирешер, дип уйлыйк.

«БУ МИНЕМ ДӘ ИЛЕМ»

51 нче мәктәпнең тагын бер укучысы – беренче сыйныфта белем алучы Олим Хамрозоданың бик зур хыялы бар – президент булу. Дөрес, дип көлә әнисе Бахриниссо, әлегә нәрсәнең президенты булырга теләвен тәгаен белми.

Олим – мәктәпкә яңа кагыйдәләр буенча кабул ителгән балаларның берсе. Казанга ул әнисе һәм апасы белән Таҗикстан башкаласы Дүшәнбедән биш ел элек килгән. Әнисенең сүзләренә караганда, русча сөйләшмәгән дә, аңламаган да. Мәктәптә укый торган апасы кебек үк. Бахриниссо кызын бер ел мәктәпкә махсус бирми тора һәм, укып китәргә җиңелрәк булсын өчен, ел дәвамында аның белән ныклап шөгыльләнә, шөкер, үзе рус телен яхшы белә – Дүшәнбедә рус телендә югары медицина белеме алган.

Ә Олим берничә ел балалар бакчасына йөри, анда рус телен дә, татар телен дә өйрәнә. Тик барыбер тест тапшырырга вакыт җиткәч, әнисе аның өчен бик борчыла. Малайның гына исе китми. Имтиханнан чыккач, Олим дулкынланып көтеп торган әнисеннән шуны гына сорый: ничек инде бирмәс дип шикләнергә була? Бүген Олим Россия урта мәктәбенең беренче сыйныф курсын уңышлы үзләштерә. Сигезенче сыйныфта укучы апасы Сумая шулай ук дүртле-бишлегә генә укый. Хәзер инде әнисенең хатасын да төзәтергә мөмкин. Ике бала да мәктәпкә бик теләп йөри – монда аларның дуслары, монда аларны укытучылар ярата. Бахриниссо: «Казан – минем шәһәрем, Россия – минем илем», – ди. Ихтимал, балалары белән горурлану шулай дияргә бер сәбәптер. Ул бу илдә балаларының киләчәге өчен тыныч.

ПРОБЛЕМА ТҮГЕЛ, БУРЫЧ

– Безнең укучыларыбызның күбесе, аларның ата-аналары үз киләчәкләрен нәкъ менә Россия белән бәйли, – дип сөйли 51 нче мәктәп директоры Рөстәм Хаҗиев. – Монда безнең мәктәп тә үз ролен уйнамый калмый, дип уйлыйм. Без балалар белән Россия һәм Татарстан халыклары мәдәнияте турында күп сөйләшәбез, төрле бәйрәмнәр үткәрәбез. Бу безнең төбәкнең тарихы, традицияләре

һәм кыйммәтләре белән танышырга мөмкинлек бирә.
51 нче мәктәптә белем алучы 471 укучының, әйткәнебезчә, йөзгә якыны – чит ил гражданнары. Монда үзбәкләр, кыргызлар, азәрбайҗаннар, әрмәннәр, уйгурлар, венгрлар, хәтта Африка илләреннән килгән балалар белем ала.
– Без һәр бала – ул Россия гражданинымы яисә чит илдән килгәнме – безнең өчен кадерле һәм мөһим булуын сизсен өчен, кулдан килгәннең барысын да эшләргә тырышабыз. Балаларны үзара хөрмәт атмосферасында тәрбиялибез. Без төрле телләрдә сөйләшә алабыз, әмма бер-беребезне аңлыйбыз, – ди директор.
Мигрант балалары белән инде күптәннән эшләгәнгә, бөтенләй русча белмичә укырга килүчеләргә ярдәм итү буенча мәктәптә үз системаларын булдырганнар. Һәм бу система үзенең нәтиҗәле булуын раслаган. Без мәктәптә тел буенча өстәмә дәресләр үткәрелүе турында югарыда язып үткән идек инде. Бу түләүле хезмәт, әмма, директор сүзләренә карагандa, ата-аналар тарафыннан өстәмә дәресләргә ихтыяҗ зур. Һәркем баласының яңа шартларга тизрәк җайлашуын һәм тулы канлы белем алуын тели.
Башлангыч сыйныф укытучысы Ольга Ганзина – чит илдән килгән мәктәп укучылары өчен шундый курсларны алып баручыларның берсе. Анда күбрәк Урта Азия илләреннән килгән балалар укый. Ольга Анатольевна кайчандыр үзе дә Үзбәкстанда яшәгән, шуңа күрә укучылар белән уртак телне тиз таба. Кечкенәләрне укыту җайлы, бик тиз отып алалар, программалары да җиңелрәк, ди ул. Гадәттә беренче уку елы ахырына алар инде телне шактый яхшы үзләштерергә өлгерә. Грамматиканы аңлатырга кирәк булганга, өлкән сыйныф укучыларын укыту авыррак. Ләкин монда иң мөһиме – теләкнең булуында. Ә аның тәрбияләнүчеләренең андый теләге бар. Быел кайчандыр телне өр-яңадан өйрәнә башлаган укучылары арасында берничәсе 9 нчы сыйныфтан соң рус теленнән имтиханны шактый уңышлы тапшырган. Бишле, бәлки, булмагандыр, тик имтиханда андый билгене рус теле туган теле булганнар да сирәк ала. Ә менә дүртлегә бирүчеләр шактый.
– Беренче тапкыр рус мәктәбенә җиденче сыйныфта гына килүчеләр арасында тугызынчыда барысы да имтиханны тапшырдылар, беркем дә яңадан бирергә калмады, – дип дәвам итә Рөстәм Хаҗиев. – Күпләр техникум һәм көллиятләргә укырга керде. Бу хәлгә без бик шат.
Әлбәттә, мәктәптә алып барыла торган эш җиңелләрдән түгел. Шуңа күрә һәр укытучы өчен үзен аңламаган укучы бу мәктәптә проблема түгел, бурыч булып тора. Рөстәм Хаҗиев та шулай кабатлый: әйе, рус телен начар белүче мигрант балалары – ул бурыч. Бурыч – чишелергә тиешле нәрсә. Аны чишү юлын табарга теләк бар икән, ул, һичшиксез, табылачак.

Сентябрь аенда журналистлар каршында чыгыш ясаганда, ТР мәгариф министры урынбасары – Мәгариф өлкәсендә күзәтчелек һәм контроль департаменты җитәкчесе **Рәмис Мөҗипов**, бүген республика балалар бакчасына 800 дән артык чит ил баласы йөри, дип сөйләде. Татарстан мәктәпләрендә 3200 чит ил баласы белем ала. 500 гә якын чит ил студенты урта һөнәри белем бирү системасында укый.

2025 елның апреленнән чит ил гражданнары балаларын гомуми белем бирү учреждениеләренә кабул итү буенча яңа кагыйдәләр гамәлгә кергәннән соң, республикада ай саен мигрант балаларының рус телен белүен тикшерү буенча тестлар үткәрелә. Ул телдән һәм язмача өлешләрдән тора, ләкин беренче сыйныфлар өчен сынауны телдән генә үтү каралган. 1 апрельдән соңгы чорда тикшерү үтәргә гариза биргән балаларның 82 проценты тестны уңышлы үтте. Министр урынбасары сүзләренә караганда, мондый югары күрсәткеч балаларның күбесе республика балалар бакчасына йөрүе белән аңлатыла.

Беренче тапкырдан ук тестны үтә алмаган балага өч айдан соң тагын бер мәртәбә тапшырырга мөмкинлек бирелә. Теләк буенча алар экспертлар, педагоглар һәм психологлары тарафыннан эшләнгән һәм 72 академик сәгатькә исәпләнгән махсус курсларда шөгыльләнә ала. Тестны тапшыра алмаган балаларның күбесе әлеге курсларга бик теләп йөри. Әгәр инде тагын бер мәртәбә тапшыра алмасалар, әзерләнер өчен тагын өч ай бирелә.

Мәхәббәт... Хезмәт миграциясе сәбәпләре арасында бу фактор статистика тарафыннан ни өчендер исәпкә алынмый. Рәхим Улаххны исә нәкъ менә көчле хисләр Пакыстаннан Казанга күченергә мәҗбүр итә. КФУның Геология һәм нефть-газ технологияләре институты фәнни хезмәткәре, гаилә корып кына калмыйча, Татарстан башкаласында икътисад фәннәре кандидаты да була.

ПАКЫСТАННАН КАЗАНГА КИТЕРГӘН МӘХӘББӘТ ТАРИХЫ

Дмитрий Сивков

Рәхим, галимнән бигрәк, эстрада артистына охшаган: кыяфәте белән ул Careless Whisper чорындагы Джордж Майклны яки «Корни» төркемендәге Александр Бердниковны хәтерләтә. Әмма без кайдадыр сәхнә артында түгел, ә Кремль урамындагы А.М. Бутлеров исемендәге Химия институты бинасының алтынчы катында урнашкан эш урыны – каталитик акватермолиз өлкәсендә дөньякүләм танылган лабораториядә очрашабыз.

КАТАЛИТИК АКВАТЕРМОЛИЗ ЛАБОРАТОРИЯСЕ

Кабинеттагы ис аның җисеменә туры килә – күзеңне йомсаң, автосервиста яки автомобильгә ягулык салу станциясендә кебек тоелырга мөмкин. Нефть продуктлары пары бөтен нәрсәгә сеңгән. Киштәләрдәге савытларда – төрле ятмалардан алынган нефть үрнәкләре. Биредә аларның нефть бирүчәнлеген арттыру ысулларын өйрәнәләр.

НЕФТЬ ЧЫГАРУ БУЕНЧА ЛИКБЕЗ

– Чыганакларга төрле реагентлар кертеп карыйбыз, алар токымның чыланучанлыгын үзгәртә, капиллярларының көчен арттыра, һәм шул рәвешле өслекнең активлыгы да, димәк, нефть чыгару куәте дә арта, – дип, кыскача гына үз эшчәнлеге белән таныштыра әңгәмәдәшем.

Хәер, мин бүген нефть чыгаруны өйрәнергә түгел, ә чит ил кешесенең Россиягә, Татарстан башкаласына күченү сәбәпләрен, аның карьерасы һәм шәхси тормышы серләрен ачыкларга дип килдем.

ӘФГАНСТАН – ПАКЫСТАН – ТАТАРСТАН

Рәхим милләте буенча – әфганлы, белеме буенча – минералог. Ул COMSATS университеты бакалавриатын «Структуралы геология» белгечлеге буенча тәмамлаган. Атасы әзеннән киткән. Әфганстанда бу – бик кирәкле һөнәр. Сүз уңаеннан, әлеге ил минераль ресурсларның дөньяда иң бай ятмаларына ия, әмма бу запасларны эшкәртү катлаулы инфраструктура һәм сәяси тотрыксызлык нәтиҗәсендә кыенлаша. Хакимияткә талиблар килгәч, Рәхимнең әти-әнисе дә чит илгә китәргә мәҗбүр була.

– Ватаныбыз белемсез, надан кешеләр хакимлегендә калды. Мондый дәүләтнең киләчәге юк шул, – Рәхимнең сүзләрендә әрнү сизелә.

Россия турында сөйли башлагач, тоны үзгәрә. Пакыстанның Әфганстан белән чиктәш Пактика провинциясеннән егет Казанга 2017 елда килә. Тик, әтисеннән аер-

Автор фотолары

малы буларак, аның эмиграция өчен сәбәбе күңеллерәк була.

АТА-АНА ИХТЫЯРЫНА КАРШЫ – «ЯВЫЗЛЫК ИМПЕРИЯСЕ»НӘ

Гүзәл исемле кыз белән алар 2015 елда Интернет аша таныша. Елдан артык видеоэлемтә буенча аралашалар. Озак көтелгән очрашу Пакыстанда була.

– Ул КФУда икътисад фәнен укыта, һәм безнең илгә гыйльми конференциягә килде, – дип таныштыра башлады үзенең мәхәббәт тарихы белән Рәхим.

Шуннан соң инде аның үзенә ерак юлга җыенырга чират җитә. Россиядә нәрсә белән шөгыльләнәчәген ул яхшы белә – укыячак. КФУның әзерлек факультетыннан соң берьюлы ике магистратурага – КФУның Геология һәм нефть-газ технологияләре институтына һәм Казан дәүләт аграр университетының икътисад институтына укырга керә.

– Әти-әни башта минем Россиягә китү теләгемне авыр кабул итте. Биредәге тормыш турында Пакыстан матбугат чаралары ешрак тискәре яктан яза һәм күрсәтә, шуңа кешеләр монда явызлык империясе дип уйлый. Безнең никахны да тиз генә кабул итмәделәр. Гәрчә без мөселманча никахлашып кавышсак та, чит милләт кешесенә өйләнү хупланмый шул.

ФӘННИ ИНТЕРНАЦИОНАЛ

Әңгәмәдәшебезнең казанышларын киметеп күрсәтәсе килми, әмма шунысы яхшы аңлашыла: хәләл җефетенең ярдәменнән башка аңа ике югары уку йортында берьюлы белем алу кыенга туры килер иде.

Гаиләсе белән.

– Чыннан да, Гүзәл Казанда беренче адымнарымнан ук миңа бик булышты, – дип раслый фикеремне Рәхим.

Аларның уңышлары укуда гына түгел. Бүген ир белән хатын биш яшьлек кызлары Рәйхәне дә тәрбияли.

Рәхим үзенең Казанга җайлы гына ияләшүендә хезмәттәшләренең ролен дә билгеләп үтә. Лабораториядә, аның сүзләренчә, «хезмәт сөючән, яхшы кешеләр» эшли.

– Чит ил кешесе булуымның аралашуга ничек тә булса йогынты ясавын сизмәдем. Институтта чит илләрдән килүчеләр күп: Гыйрак, Мисыр, Йәмән, Ираннан... Киресенчә, мондагы коллегалар безгә игътибарлырак та әле. Һәрвакыт ярдәм итәргә теләк белдерәләр, миңа башлыча телне начар белүем аркасында нәрсәнеңдер кыенрак бирелүен күрәләр. Гәрчә мин төрле дәрәҗәдә әфган, һинди, инглиз, фарсы телләрен белсәм дә, рус теле белән – катлаулырак.

– Сез Россия турындагы фикерегезне үзгәрттегезме?

– Әлбәттә! Монда – КФУда белем дәрәҗәсе күпкә югарырак, Пакыстанда булмаган юнәлешләр буенча үсәргә мөмкин. Мин барлык чит ил кешеләренә әйтәм: әгәр укуда да, һөнәрдә дә уңышка ирешергә телисез икән, Россия – моның өчен иң яхшы урын. Һәм күп кенә якташларыма бирегә килергә ярдәм итәргә тырышам, алар арасында студентлар да шактый. Укырга һәм эшләргә теләүче кешеләр миңа ошый. Хәлемнән килгәнчә булышам.

Татарстан яңа мөмкинлекләр ачты – күп җирдә эшли алам. Магистратура тәмамланганнан соң, нефть-газ компанияләреннән чакырулар булды. Әмма мине күбрәк фәнни эш җәлеп итә.

P. S. буларак

Рәхим тыйнак кеше дә булып чыкты. Безнең сөйләшү вакытында ул икътисад фәннәре кандидаты гыйльми дәрәҗәсенә әзерләнүен әйтмәде. Диссертация темасы да төп эшеннән ерак икән: «Авыл хуҗалыгы оешмаларының мелиорация эшләре буенча идарә хисабын исәпкә алу-контроль белән тәэмин итүне үстерү». Яңалыкны диссертациясен уңышлы яклаганнан соң гына хәбәр итте. Рәхимнең Россиядә чит ил кешеләренә бирелгән мөмкинлекләрдән тулысынча файдалана белүе дә аңа булган ихтирамны бермә-бер арттыра.

БЕРЕНЧЕ МАРШРУТНЫ КЕМ ЙӨРТӘ?

Дмитрий Сивков

Дәрвишләр бистәсе пассажирлары тынычлап бара ала, чөнки автобусны үз эшен нык яраткан шофер йөртә.

Мәхмүтҗан Умурзаков – нурлы кеше. Аның йөзе кояшлы Өчкурган җилләрен үзенә мәңгегә сеңдергән бугай. Әлбәттә, моны тиз генә аңлый алмыйсың, чөнки сөйләшә башлаганда ул каушап китте, каршымда әйтерсең имтихан бирүче студент. Әмма берничә мизгелдән барысы да үзгәрде.

– Русларда шундый җыр бар: «Я большой человек, с этим ты не поспоришь. Несмотря на быстрый бег, ты меня не догонишь». Бу җыр автобус йөртүчеләр турында. Сез дә үзегезне шундый зур кеше дип хис итәсезме?

– Юк инде, сез нәрсә?! – ди әңгәмәдәшем, кулын селтәп, һәм шунда ук йомшак күңелле, мөлаем бабайга охшап кала.

«БЕНЗИНГА АКЧА ҖЫЯМ ДА КАЗАНГА КИТӘМ!»

Наманган өлкәсендә туган Мәхмүтҗан 60 ел гомеренең өчтән берен Казанда яши һәм 2 нче пассажирлар автотранспорты предприятиесендә эшли.

– Ә ни өчен нәкъ менә Казан? Россиядә шәһәрләр күп бит...

– Өчкурганда бергә эшләгән хезмәттәшем һаман: «Менә бензинга гына акча җыям

Автор фотолары

да Казанга китәм!» – дип тукыды, чөнки ул анда эшләп кайткан иде. Ахыр чиктә хыялын тормышка ашырды. Мин дә аның артыннан кузгалдым. Ә аннары ике улым да, энем дә бирегә килеп урнашты. Дүртебез дә автопредприятие тулай торагының бер бүлмәсендә яшибез.

– Алайса автобус йөртү гаилә эше булып чыга бит!

– Шулай килеп чыга...

– Ә үзегез ничек шофер булып киттегез?

– Әтием һөнәрен сайладым. Тик ул йөк машинасы йөртте, ә мин бала чактан ук автобус йөртүчеләрдән көнләшә идем. Аларны иң бәхетле кешеләр дип уйлый идем.

СМЕНАГА 350 КИЛОМЕТР

– Һәм бу чыннан да шулай булып чыктымы?

– Әйе, үземне бәхетле дип саныйм. Шул исәптән Казан кебек матур шәһәр урамнары буйлап автобус йөртүем белән дә. Казанлылар үзләренең нинди күркәм калада яшәүләренең кадерен белсен иде.

– Мөгаен, пассажирлар сезнең бәхетле булуыгызны тоялардыр?

– Тоялардыр (елмая). Әле Үзбәкстанда, халыкара маршрутта эшләгәндә үк, пассажирлар, гаражга язып, рейска мине куюны сорыйлар иде. Өлкән яшьтәге кешеләр үтенече буенча «санитар тукталышлар» ясый идем. Әгәр юл кырыенда егет һәм кыз кул күтәреп тора икән, кызы каршында егеткә уңайсыз булмасын өчен, һәрвакыт туктап утырта идем. Казанда бер әби белән бабай соңгы тукталышта һәрвакыт килеп рәхмәт әйтәләр.

– Ә кайсы маршрутта эшлисез?

– Беренчедә, Дәрвишләр бистәсенә йөрим. Ни өчендер җавап гаҗәпләндерми: беренче булмыйча, тагын нинди маршрут булсын?

– Сүз уңаеннан, сменага ничә километр юл үтәсез?

– Өч йөз илле.

ЯЛГА ТИҢ ЭШ

– Арымыйсызмы? Яшегез шактый бит инде...

– Сез нәрсә! Мин эштә ял итәм.

– Шуңа эшкә дә бәйрәмгә йөргән кебек йөрисез, ахры, – ак күлмәк белән галстуктан, моны һәр офиста да күрмәссең.

– Бу миннән тормый, бездә униформа шундый.

– Казан пассажирлары турында нәрсә әйтә аласыз? Без ниндирәк?

– Нигездә, тәртипле-әдәпле – картлар һәм хатын-кызга урын бирәләр. Йөкле хатыннарга урын бирүләре аеруча сөендерә. Мин эшләгән елларда аларның бер тапкыр да басып барганы булмады. Дөресен әйткәндә, мондый хәлне күргәч, кәефем күтәрелә.

– Маршрутта истә калырлык нәрсәләр еш буламы?

– Алай нииндидер шаккатарлык нәрсәләр булганы юк инде... Күптән түгел бер кыз салонда кыйммәтле смартфонын калдырган иде. Мин диспетчер аша кире кайтардым. Алырга килгәч, кыз телефонын әллә ничә югалтуын, тик менә беренче тапкыр кире кайтаруларын сөйләгән, рәхмәт әйткән. Күңелем булды, әлбәттә.

Мәхмүтҗан Умурзаков белән аралашкач, беренче маршрутка утырып Дәрвишләр бистәсенә барасым, аның күтәренке кәефен йоктырасым, аннары автобус йөртүчегә ихластан рәхмәт әйтәсем килеп китте...

КӨРӘГӘ ҺӘМ МӘРХӘМӘТ ДИПЛОМАТИЯСЕ

Дмитрий Сивков

Казан читендәге бу кибетнең элмә тактасы юк, әмма аны бөтен кеше белә. Сату ноктасы хуҗасының туган ягы – Ворух дип аталган таҗик авылында язулар элеп тормыйлар – кайдан нәрсә аласын халык болай да белә. Бу ысул бездә дә эшли: Фурузон Фәрзиев кибетенә кереп йөргән йөзләгән кешене исемләп әйтә ала, аның үзен исә тагын да күбрәк кеше беләдер.

Сез Таҗикстандагы таулы Исфара районы турында нәрсә беләсез? Белмим, диярсезме? Әмма чәйне җимешләп эчәргә яратучыларның күбесе әлеге төбәкнең тәмен белергә тиеш – безнең кибетләрдә нәкъ менә шул якларда үсә торган өрек-көрәгәләр сатыла бит. Киптерелгән җиләк-җимеш сатучыларның да күбесе шул төбәктән. Язма авторы үзе дә бу турында сатучыларның белән аралашканнан соң гына белде.

БАБАСЫ ЭЗЕННӘН

Фурузон – ачык йөзле, кунакчыл, сатып алучы ханымнарның әйберләрен һәрвакыт машинага кадәр илтеп куярга әзер, шул ук вакытта бу гамәлләрдә ниндидер ясалмалык, ялагайлык юк. Гадәттә яхшы таныш кешеләр генә бер-берсе белән шулай аралаша. Мондый мөнәсәбәтне берниди коуч та тәрбияли алмый, моның өчен шундый булып туарга кирәктер.

– Унбер классны бары тик бишлегә генә тәмамладым, медицина юлыннан китәргә иде исәп. Тик бюджет урыннары бик аз, гади гаиләдә үскән балага анда эләгү мөмкин түгел, ә эти-әниләрнең түләп укытырга хәле юк. 2008 елда Казанга килдем, монда минем өч абыем эшли иде инде – киптерелгән җиләк-җимеш саталар, – дип сөйли Фурузон.

Бертуган Фәрзиевләрнең Татарстан башкаласына килеп чыгулары да кызыклы. Әле 90 нчы еллар башында ук аларның бабалары Әхмәт бирегә кипкән җиләк-җимеш ташыган, аны колхоз базарына күмәртәләп тапшыра торган булган. Соңрак улларының

Автор фотолары

берсе монда сату белән шөгыльләнергә уйлый, аның артыннан туганнары да тартыла. Вакыт узу белән ассортимент та киңәя – җиләк-җимеш, яшелчә, сок, чәй, тәм-том һәм хәтта милли эчтәлекле сувенирлар да саталар.

– Бабагыз җиләк-җимешне каян ала иде?

– Үзебезнең бакчадан! Бик зур бакчабыз бар – абрикос, алмалар... Ә өрек белән күрәгә – үзебезнеке дә, күршеләрдән дә алабыз. Казанда гомумән җимешнең күпчелек өлеше Исфара районыннан, сатучылары да нигездә безнең якташлар. Алманың Хубон, Голден, Семеренко сортлары, өйдә үскәннәре...

Сатучы ишек төбендәге кәгазь әрҗәләргә язылган язуны күрсәтә: яшел-кызыл алма тутырылган берсенә: «Әти бакчасы алмалары, Таҗикстан...» дип язылган.

Гадәттә үз ягыбызны арттырыбрак мактарга, матурларга яратабыз, бу кешегә хас сыйфат. Ишеткәннәремнең дөреслеген раслау өчен, интернетны ачтым: «Исфара районы, Фирганә үзәнендә урнашкан, Урта Азиядә киптерелгән җиләк-җимеш җитештерә торган төп төбәкләрнең берсе булып тора», – диелгән иде анда.

«АКЧА ТӘМЕ» ҺӨНӘР САЙЛАРГА БУЛЫШТЫ

Фурузон гомер буе кибет киштәсе артында басып торырга хыялланмаган. Математика һәм физика укытучы булып эшләгән әтисе дә үрнәк. Казанга килгәч, егет документларын КФУның юридик факультетына тапшыра: абыйлары да аның бу теләген хуплый. Ләкин аларга сату эшендә булыша-булыша, Фурузон шуны аңлый: аның язмышы – бизнес. Берничә елдан соң ул, югары белем турындагы уйларыннан баш тартып, үз сәүдә ноктасын ача.

– Акчаның тәмен тоеп алдыгызмы?

Тынлык урнашты, тик берничә мизгелгә генә:

– Ул да бардыр... Ләкин иң мөһиме - миңа кешеләр белән аралашу, эшләү ошый икән.

Ярты сәгатьлек әңгәмә вакытында моның чыннан да шулай аңлыйсың: кибет бусагасын атлап кергән һәр кешедә сатучы акча янчыгы булган билгесез затны түгел, кешенең үзен күрә. Сатып алучы моны сизә, тоя һәм кибеттән әйберсез чыгып китми.

Фурузон бик өлгер кеше, бу аның канында. Дөрес, баштарак ул шул рәвешле җылына дип уйлыйсың, чөнки павильон эчендә урамнан бераз гына җылырак. «Акчаңны янга калдырасыңмы, кибетеңне җылытмыйча?» – дим. Соравыма ул елмаеп җавап бирә: «Юк, салкынчада товар озаграк саклана».

Яшь чырайлы сатучының үзенә карагач та, әллә бу да шуннан киләме, дип уйлап куясың.

ОЛЫГА – ПЫЛАУ, Ә БАЛАГА – БОРЩ

– Сез үзегезне кем итеп тоясыз: Казанда яшәүче исфаралымы, Исфарада туган казанлы итепме?

– Мөгаен, икенчеседер. Мин бит 38 еллык гомеремнең күп өлешен биредә үткәрдем. Иртәнге 9 дан кичке 9 га кадәр кешеләр белән аралашам, күршеләрем – руслар һәм татарлар, шуңа күрә мин яртылаш татарстанлы инде.

– Ә гаиләгез?

– Хатыным Мехронфарин турында әйтүе кыенрак. Без бер авылдан, 2013 елда өйләнештек, ул күбрәк өйдә – хуҗалык эшләре, балаларны карау аның өстендә. Ике ул һәм ике кыз үстерәбез. Ә менә алар бергә укый, бакчага йөри торган яшьтәшләреннән аерылмый, дип уйлыйм. Аш яраталар, бигрәк тә – борщны, боткадан да баш тартмыйлар... Үзара рус телендә сөйләшәләр, дөрес, минем белән – туган телдә, тамырларны онытырга ярамый.

– Балаларыгызның киләчәген ничек итеп күрәсез? Гаилә бизнесын дәвам итәрләрме?

– Олы кызым Әминәгә 10 яшь, бишкә генә укый, ресторанда шеф-повар буласым килә, ди. Карарбыз, нинди һөнәр сайларлар. Балаларга үз ихтыярыңны көчләп тагарга ярамый. Үзләре сайласын, дим. Һәрхәлдә, аларның киләчәге Россия белән бәйләнгән булачак.

– Балалар борщ белән ботка ярата, дидегез, ә ашау-эчү ягыннан үзегезнең зәвык үзгәрдеме?

– Юк, кич белән табында һичшиксез пылау – көне буе аяк өстендә, эшләр өчен көч җыярга кирәк.

– Ә нинди музыка тыңлыйсыз – таҗик, әллә Россия башкаручыларынмы?

– Әлбәттә, Россия җырчыларын! Яраткан җырчыларым – Сергей Лазарев, Алексей Воробьёв белән Аида Гарифуллина «Интервидение» ачылышында куандырдылар. Гомумән без музыкаль тапшырулар карарга яратабыз.

– Ә татар эстрадасын?

– Татарстанның атказанган артисты Раил Бикбаевны яхшы беләм, Салават Миңнехановны, тагын кайбер җырчыларны. Сатып алучыларым булрак беләм! (Елмая.) Раил белән дуслар, ул миңа абыем шикелле. Һәр кич диярлек керә – гел сатып алырга гына түгел, сөйләшергә, гәпләшергә.

Менә шулай – өрек һәм күрәгә аша казанлыларның Төньяк Таҗикстанның таулы районы белән халык дипломатиясе урнаштырылган. Ә Фурузон Фәрзиев анда, ким дигәндә, – консул.



ТУГАН ЯККА ЮЛ

Әскәр Сабиров

Туган ягында Өметҗанның зур матур йорты, шапталлар үскән бакчасы бар һәм ел әйләнәсе – кояш – җәннәт диярсең! Казанга беренче мәртәбә килгәндә үк, озакка түгеллегенә ышанычы нык була: «Акча эшлим дә – шунда ук өйгә!» Озакка түгел дигәне ун елга сузыла, балалары да биредә мәктәпкә керә... Ул инде Россиядә гражданлык алу турында уйлана башлый. Барысы да бер көндә юкка чыга – депортация!

– Үзем гаепле, – дип әйтеп куя сүз башында ук Өметҗан, теләсә кайсы аклануларга юл калдырмыйча, үзенең күңелсез тарихын башлар алдыннан. – Акыллы булсам, бүген үземнең көлчәләремне пешереп, рәхәтләнеп яшәр идем. Балалар да күңелсезләнмәс иде...

Өметҗан Искәндәровка утыз биш яшь. Улы Шәфкатькә – унбер, кызы Ясминәгә – сигезяшь. Өметҗанны самолетка утыртып, Россиягә кире кайту хокукы бирмичә, туган иленә кайтарып җибәрүгә, гаилә чемоданнарын тутыра башлый. Хатыны Комола да, яңа җирдә югалып калмыйча, бу ел-

Фото: pxhere.com

лар эчендә кечкенә генә кафе директоры дәрәҗәсенә кадәр үскән була – хәзер инде сау бул, карьера! Шәфкать белән Ясминә сыйныфташлары белән аерылуны авыр кичерә. Күз яшьләре – дәрья – искә аласы да килми...

Үзеннән рөхсәт алып, Өметҗанның тарихын* тулысынча журналыбызда бастырырга уйладык. Монда бернәрсә дә уйлап чыгарылмаган: барысы да тормышта булганча.

КАБАРТМА БИЗНЕСЫ ИЯСЕ

Өметҗан пешерә торган көлчәләр гадәти түгел – Хорезм көлчәләре! Ә бу, беләсегез килсә, сыйфат билгесе, үзенә күрә Мишлен йолдызы! Казан халкы мондый нечкәлекләрне белеп бетермәсә дә, көлчәнең тәмен тиз тоеп ала: челтәр супермаркетында һәрвакыт чират тезелә торган була. Җитәкчелек өчен Өметҗан чын табышка әйләнә, гәрчә ул тыйнак, карусыз мигрант-гастарбайтерга бөтенләй охшамаса да. Үзенеке булмаган эшкә кысыла, хәтта таләп итәргә дә мөмкин: мич – һичшиксез махсус, он – бары тик аерым бер җитештерүченеке генә...

Ләкин Өметҗан керем китерә, шуңа күрә аның көйсезлекләренә бармак аша карыйлар. Алай гына да түгел, күпмедер вакыттан соң хәтта эшендә күтәрәләр дә.

– Наилә апа, – мин хәзер остаз – укытучы, – дип горурланып хәбәр итә ул фатир иясенә. – Көлчә пешерергә өйрәтәм, өйрәнергә теләүчеләрне үзем сайлыйм!

Алга таба эшләр тагын да яхшыра. Тиздән аңа башка шәһәр һәм регионнарда көлчә пешерү бизнесын оештырырга тәкъдим итәләр. Командировкаларга йөри башлый, сыйфатны тикшереп тора, җентекләп, полицейскийлар кебек.

Һәрвакыт матур-пөхтә киенгән, кыяфәтеннән зыялылык бөркелеп торган Өметҗан, гади эшчедән бигрәк, берәр көллияттә укытучы мөгаллимне хәтерләтә. Бу чыннан да шулай булыр иде дә: югары белем турындагы дипломы – чын, аны Өметҗан, биредә таләп ителмәгәнгә, тирәнгәрәк һәм ераккарак яшереп куя.

Өметҗанны карьерасының иң югары мәлендә тоткарлыйлар. Эштә вакытта алып китәләр. Якыннары белән саубуллашырга да рөхсәт итмиләр – туп-туры мигрантларны вакытлыча тоту үзәгенә китерәләр...

КУНАКЧЫЛЛЫКНЫҢ БАШКА ЯКЛАРЫ

Казанга Өметҗан, башка йөзләгән якташлары кебек, туган ягында эш белән дә, акча юнәтү ягыннан да хәлләр авырайгач килә. Башта Казанга әнисе күченә, аннан соң – сеңлесе, соңрак аны да чакыралар. Иске Татар бистәсендәге бер кафеда бергә эшлиләр. Якташлары да күп, шуңа күрә яңа урында урнашканда эш табу белән дә, киңәшләр белән дә ярдәм итәләр, ул яктан проблемалар чыкмый. Уртак чат бар – ул да бик зур ярдәмче. Аны хезмәт биржасы да, мәгълүмат бюросы да, үзенчәлекле куркынычсызлык хезмәте дә дияргә була.

Чатта кайчак намуссыз эш бирүчеләр турында да хәбәр итәләр: алар, мигрантларга яхшы акча вәгъдә итеп, эшкә алалар да соңыннан бик аз түлиләр яисә бөтенләй түләмиләр. Торак өчен алдан акча алып юкка чыгучылар турында да бер-берсенә хәбәр итәләр бу чатта. Намуссыз эш бирүчеләр һәм риелторларның кара исемлеге яңартылып тора, һәм асылда бу алданулардан бердәнбер саклану чарасы була. Каядыр барып зарлануның, күрәсең, мәгънәсе юк, чөнки «намуссызлар» күбрәк «соры» хезмәт хакы түли. Хокук саклау органнарының килүчеләргә мөнәсәбәте дә, йомшак кына әйткәндә, үзенчәлекле.

Өметҗанга моны берничә мәртәбә үз җилкәсендә татырга туры килә. Бервакыт алар арендалап торган фатирга яшь кенә полиция лейтенанты бәреп диярлек килеп керә. Уята, документларын таләп итә. Теркәлү ягыннан барысы да тәртиптә булса да, лейтенант чыгып китәргә ашыкмый. Хуҗаларча фатирны әйләнеп чыга, рөхсәтсез бүлмәләрне карый, фотоаппаратын чыгара.

– Фотога төшерәсегез килсә, хуҗабикәдән рөхсәт сорасагыз иде, – дип төнге кунакны җай белән генә туктатырга тырышып карый Өметҗан.

– Синең эшең түгел, – дип җавап кайтара полицейский, төшерүен дәвам итеп.

Гаҗизлектән нишләргә белмәгән Өметҗан чакырылмаган кунактан соң төне буе йоклый алмый чыга. Иртән фатир хуҗабикәсенә зарын сөйли. Полицейскийның шулай рөхсәтсез инде икенче мәртәбә «кунакка» керүен белгәннән соң, фатир хуҗабикәсе аны эзләп таба һәм, тагын шундый очрак кабатланса, лейтенантның тәртибен югарыдагы җитәкчелек катнашында тикшертәчәген җиткерә. Кисәтү ярдәм итә.

«МИГРАНТЛАРНЫҢ БОРЧЫМАВЫН ҮТЕНӘМ»

Алар яшәгән йорт – тарихи үзәктә. Бөтен уңайлыклары да бар, хәтта үз ишегалды да.

– Фатирыбыз бик яхшы иде, – ди Өметҗан. – Лотореяда откан кебек булдык бу яктан!

Әйе, көчле яңгырларда түбәдән бераз тама. Әйе, обойлары да өр-яңа түгел, ә душ кабинасының ишеге инде күптән ябылып бетми. Ләкин иң мөһиме бу мыни? Йорт элек буш торган, хуҗабикә аны арендага бушка бирә дияргә була – коммуналь

*Язмадагы геройларның исемнәре үзгәртеп бирелә.

хезмәтләр өчен түләсеннәр дә кышын ишегалдындагы карны көрәсеннәр....

Бирегә эшләргә килүчеләр өчен бу чыннан да зур бәхет – язмыш бүләге дияргә мөмкин. Эш шунда ки, акча эшләргә килгән мигрантка, гади россияле белән чагыштырганда, фатир табу чыннан да кыен. Юк, Татарстанда, башка регионнардан аермалы буларак, толерантлык белән бар да тәртиптә. Проблема башкада. Мигрантка фатирыңны арендага бирәсең икән, рәхим итеп, аны тору урыны буенча теркә дә.

Ә хуҗалар өчен ОВИРда мигрантларны теркәү – чыдамлыкка тест үтү белән бер: ярты көн чират тору – әле эш бетте дигән сүз түгел. Барысы да беренче тапкырдан хәл ителмәскә бик мөмкин: кулда берәр төрле кәгазь җитеп бетмәве ачыклана икән, иртәгә барысын да яңадан башларга кирәк. Яңадан – чират, яңадан – һәрвакытта да әдәп кагыйдәләрен саклап тормаган «кунакчыл» хезмәткәрләр белән сөйләшү. Аның каравы, вакыт-вакыт бер өем чит ил паспортлары тоткан билгесез затлар килеп керә. Алар кабинетка узалар да чиратны тагын озакка тоткарлыйлар...

Шушы хәлләрне күреп, фатирларын арендага тапшыручылар нишли, дисезме? Игъланнарына алдан ук: «Мигрантларның борчымавын үтенәм» дип язып эләләр. Яисә мескен килүчеләрдән теркәү өчен аерым түләү алалар. Бәясе – берничә мең сум...

Нинди юллар кала? Теркәү үтмичә яшәү яисә яшәү урыны буенча түгел, берәр «начар» фатирда теркәлү. Мондый фатирларның хуҗалары законсыз бизнесны шул рәвешле җайга салган. Ике вариант та – бер якка алынган билетка тиң – депортацияләнүгә иң кыска юл.

ОТПУСК АКЧАЛАРЫ – ЯЗМЫШ БҮЛӘГЕ

Отпусксыз һәм бөтенләй диярлек ялларсыз тәүлегенә унике-унсигез сәгать эшләү. Мигрант өчен мондый эш графигы – гадәти. Эшли башлаган мәлләрендә Өметҗан да өенә кайтуга урын өстенә ава – иртәнгә кадәр. Хезмәт куркынычсызлыгы турындагы уйлар төшкә дә керми...

Озак вакытлардан соң, инде супермаркетта көлчә пешерү буенча төп белгечкә әверелгәч, эшләр бераз җиңелләшә, әлбәттә. Беренче тапкыр Кремльне күрә – матур! Хәтта үзенә электросамокат та сатып ала – җәмәгать транспортында этеш-төртешләрдән котылу өчен.

Ә монда әле закон буенча еллык ял да тиеш икән! Могҗиза! Бу шулкадәр тәэсир итә ки, ул фатир хуҗабикәсенә шалтыратып хәбәр итми кала алмый:

– Наилә апа, миңа отпуск бирделәр! Ике атна ял, әле акча да түләделәр – мондыйны беркайчан да күргәнем юк иде!

Безнең геройны шаккатырган факт, кызганычка, бер генә мәртәбә була. Гипермаркет тиздән ябыла, икенчесендә – анда тәмле көлчәләр пешерү белүче Өметҗанны биш куллап кабул итәләр – хезмәт хакын яхшы түлиләр, әмма конвертта. Һәм инде отпуск икән – бары тик үз хисабыңа гына.

Анысына да исе китми Өметҗанның. Иң мөһиме – ул гаиләсен Казанга күчерә. Туган иленә көн саен шалтыратулар һәм якыннарыннан башка үткән күңелсез кичләр артта кала. Хатыны Комола, улы Шәфкать, кызы Ясминә – алар хәзер барысы бергә. Ял көннәрендә бергәләшеп ишегалдына чыгалар һәм чын, үзләрендәгечә итеп пылау пешерәләр...

Депортацияне көтеп, махсус бүлмәдә утырганда, ул, ачынып, әлеге мизгелләрне, Иске Татар бистәсендәге тыныч ишегалдын искә төшерә.

ТАТАР ТЕЛЕ: ХАЛЫКЛАР АРАСЫНДАГЫ КҮПЕР

Өметҗанның гаҗәпләнүенә каршы, хатыны Комола чит илгә һәм ят тормыш рәвешенә тиз ияләшә. Шаккаткыч бит: Өметҗаннан аермалы буларак, монда килгәндә хатыны бер авыз сүз русча белми. Аңа туган теленең татарчага охшашлыгы нык булыша. Күченеп килгәненә бер айлап вакыт үтә, ә ул инде күршеләре белән татарча аралаша, эштә дә (башта савыт-саба юучы булып урнашкан кафеда) аралашу ягыннан кыенлыклар тумый.

Шулай да үзләре өчен яңа мохиткә җайлашып китү буенча чын могҗизаны Шәф-

кать белән Ясминә күрсәтә. Алар күршедәге балалар белән бик тиз уртак тел таба. Монда да татар теле аралашу күпере ролен үти. Килүгә үк диярлек алар татарча ипилек-тозлык сөйләшә башлый – ис китәрлек!

Рус теле белән авыргарак туры килә, һәрхәлдә, балалар бакчасына барганда алар русча бөтенләй белми. Бәхеткә, бернинди тестлар да тапшырырга туры килми, беренче мәлләрдә тәрбиячеләр, төркемдәге балалар (алар арасында шулай ук мигрант балалары да бар) белән аралашуда татар теле ярдәмгә килә. Беренче сыйныфка барганчы, балалар рус телен дә өйрәнеп өлгерәләр. Ә мәктәптә инде рус телен дә, башка фәннәрне дә тагын да яхшырак итеп үзләштерәләр. Бераздан инде әкренләп үз ватаннарына әйләнә башлаган илнең тарихы, мәдәнияте буенча этиәниләрен дә «агарта» башлыйлар.

Өметҗанның төрле илләргә акча эшләргә киткән туганнары һәм дуслары күп. Туганнарының берсе – медик, бәхет эзләп, Согуд Гарәбстанына киткән, бер сыйныфташы – Германиягә. Иң якын дусты Канадада яши. Өметҗанны да берничә мәртәбә үзе янына чакыра, эш белән проблемалар булмый, ди, андагы тормышны мактый. Казанга килгәннең беренче елларында Өметҗан әлеге вариантны сайлау турында да чын-чынлап уйлана. Әмма берничә елдан соң ныклы карарга килә: бары тик Татарстан, бары тик Казан гына.

– Казанда мин өемдә кебек, – дип аңлата ул фатир хуҗабикәсенә, монда бөтенләйгә калырга дигән теләген дәлилләгәндә. – Беркем дә, беркем дә диярлек миңа кырын карамый, килеп тулдылар, дими, минем нинди диндә булуым беркемне дә ярсытмый. Эшем әйбәт, яхшы түлиләр. Балаларым түләүсез мәктәпкә укырга йөри. Сездә ришвәт алмыйлар, Наилә апа! Ә табиблар? Андыйлар монда гынадыр!

Калырга дигән ныклы карарны ул ковид булган елны, могҗиза белән исән калганнан соң кабул итә.

ПАНДЕМИЯ ҺӘМ ИГЕЛЕК ВАКЦИНАСЫ

Бу хәл пандемиянең котырган чагына туры килә. Ул фатир хуҗабикәсенә хәле бөтенләй авырайгач шалтырата.

– Наилә апа, хәлем начар, сулыш җитми, – ди ул көч-хәл белән. – Ә ашыгыч ярдәм һаман килеп җитә алмый...

Ашыгыч ярдәмне ниһаять китертәләр. Табиблар, кислород мендәре, реанимация... Аннан соң озак атналар дәвамында тернәкләнү...

Хастаханәдән чыккач, Өметҗан шуны да әйтә: әгәр туган илендә мондый хәлгә дучар булса, исән калуы икеле булыр иде.

– Монда мине туганнарын тәрбияләгәндәй карадылар. Шәфкать туташы, миңа апа тиеш кеше, ботка ашатты, – дип, исенә төшереп сөйли Өметҗан, хастаханәдән өенә кайткач. – Улым, терел, дия иде. Һәм беркем дә бер тиен дә акча алмады!

Өметҗанның сөйләвенә караганда, ул нәкъ шулчакта Россия гражданлыгы алырга дигән карарга килә дә.

БЕР ЯККА ГЫНА АЛЫНГАН БИЛЕТ

Шайтан алгыры, пандемия дигәннәре соңрак барыбер китереп бәрә – бөтенләй көтмәгән җирдән, дип сөйли Өметҗан. Ковид котырынган чакта мигрантларга теркәлүне автомат рәвештә яңарталар. Ә инде барысы да тынычланып, үз урынына кайткач, элек мәҗбүри булган теркәлү Өметҗанга ни өчендер андый булып тоелмый башлый.

– Өметҗан, ут белән уйнама, – дип кисәтә фатир хуҗабикәсе. – Барысын да югалтасың бит...

Ә ул тыңламый: аңа, карап торган бер кадрга, теркәлүне эштә ясыйлар. Берәр хәл була калса, ярдәм вәгъдә итәләр.

Әлбәттә, беркем дә булышырга җыенмаган була. Документларны тикшерү вакытында Өметҗанны тоткарлагач, теркәлү таныклыгының ялган булуы бик тиз ачыклана...

Хөкем карары бик тиз чыгарыла: депортация!

P.S. Казанга, элекке фатир хуҗаларына, Өметҗан гел язып, шалтыратып тора. Күптән түгел генә хатыны Комола белән күрше илгә эшкә барып кайтулары турында да сөйли. Ошамаган. Татарстан белән чагыштырып булмый, ди. Тагын шунысын да яза: балалар күченүне бик авыр кичерә икән, яңа мәктәпләрендә аларга ошамый. Сөйләшкән саен Өметҗан шуны да искә төшерә: болай килеп чыгуда бары тик ул үзе гаепле. Һәм күпме калганын саный. Депортациядән соң ике ел вакыт узган. Димәк, тагын өч ел бар. Бары шулчакта гына илгә керүне тыю вакыты чыгачак, һәм без һичшиксез өебезгә кайтачакбыз, ди. Нәкъ шулай: «Өебезгә», – ди.

БӘЙШЕНБӘК МУКАНБӘТОВ: «КЫРГЫЗЛАРНЫҢ ТАТАРЛАР БЕЛӘН УРТАК КЫЙММӘТЛӘРЕ КҮП»

Евгения Чеснокова

Бүгенге көндә Татарстанда 12 меңгә якын Кыргызстан кешесе яши һәм эшли. «Татарстан Республикасы кыргызларының милли-мәдәни автономиясе» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе Бәйшенбәк Муканбәтов әйтүенчә, алар сәүдә белән шөгыльләнә (күбесе – Яңа Тура базарында), транспортта (шәһәр автобуслары йөртә), төзелештә һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә (нигездә урам себерүче булып) хезмәт куя.

Кыргызстан Евразия икътисадый берлеге (ЕАЭС) әгъзасы булганга, аның гражданнарына Россиядә эшләү өчен патент кирәкми – эш бирүче белән килешү һәм яшәү урыны буенча теркәлү генә таләп ителә. Бу аларга Россиядә яшәүне шактый җиңеләйтә. Әмма гомумән, ди Бәйшенбәк Муканбәтов, аның ватандашлары Татарстанда үзләрен өйдәге кебек хис итә – республикада мөселманнарның күп булуы сизелә, ә кыргызлар белән аларның традицияләре һәм рухи кыйммәтләре уртак.

– Ышаныгыз, мин Россиянең башка төбәкләренә күп йөрим, андагы диаспора вәкилләре белән очрашам, чагыштырырлык әйберләрем бар, – ди Бәйшенбәк Әскәрбай улы. – Татарстанда Азия илләреннән килгән кешеләргә мөнәсәбәт бик дустанә.

Муканбәтов үзе Казанда утыз елдан артык яши инде – 1986 елда ук биредә авыл хуҗалыгы институтына укырга килгән һәм бөтенләйгә калган. 1997 елдан кыргыз диаспорасы эшенә җитәкчелек итә. Милли-мәдәни автономиянең төп бурычы – якташлар арасында туган телне һәм гореф-гадәтләрне саклау. Халык бәйрәмнәре, концертлар оештыралар, милли аш көннәре үткәрәләр. Әмма, әлбәттә, нинди дә булса көнкүреш яки юридик проблемалар килеп чыккан очракта да үз ватандашларын ярдәмсез калдырмыйлар. Кайвакыт, ди Бәйшенбәк Муканбәтов, ярдәм кирәк булса, аңа төнлә дә шалтыраталар икән.

Кыргызстан мигрантлары еш очраша торган көнкүреш проблемалары арасында – теркәлү кыенлыклары. Фатирны арендага алырга мөмкин, тик менә хуҗаларны вакытлыча теркәү ясарга күндерүе кыен. Ә мигрантларның республика территориясендә теркәлмичә яшәргә хокукы юк. Муканбәтов аңлатуынча, кайвакыт торакны арендага бирүчеләр белән дә эшләргә – барысын да закон буенча рәсмиләштерергә күндерергә туры килә... Соңгы вакытта вазгыять яхшы якка үзгәрә башлаган: хәзер торак хуҗалары үзләре дә кагыйдәләрне бозмауның яхшырак икәнен аңлый икән.

Күп кенә мигрант мәктәп яшендәге балалары белән килә. Әгәр шәһәр балалары икән, алар, кагыйдә буларак, рус телен яхшы белә, чөнки ул Кыргызстанда икенче дәүләт теле, аны мәктәпләрдә укыталар. Авыл балаларына кыенрак, әмма, телне тизрәк үзләштерсеннәр өчен, аларга әти-әниләре репетиторлар яллый.

Диаспора дәүләт органнары белән үзара мөнәсәбәтләрдән дә канәгать. Татарстан халыклары ассамблеясендә даими рәвештә түгәрәк өстәлләр уза, аларда милли-мәдәни автономияләр җитәкчеләре белән беррәттән көч структуралары, миграция һәм салым органнары вәкилләре дә катнаша. Килеп туган барлык проблемалар турында белгечләр белән фикер алышырга була, кайвакыт катлаулы мәсьәләләр дә шунда ук хәл ителә. Болай да булгалады, дип искә алды Бәйшенбәк Муканбәтов: ул берничә тапкыр миграция хезмәте җитәкчеләре янына шәхсән үзе барып, гаепле булмаган кешеләрне депортацияләүдән коткарып калган.

«Әгәр кешеләр закон бозмаган икән, барлык мәсьәләләрне дә хәл итеп була, – ди Бәйшенбәк Әскәрбай улы. – Әгәр инде бозган икән, депортациягә эләкмәс өчен, без аларга үзебез үк китәргә кушабыз».

Ел ярым элек Казанда Кыргызстан Республикасының Генераль консуллыгы ачылган. Хәзер, ди Бәйшенбәк Муканбәтов, Татарстанда аның ватандашларына тиешле ярдәмне алу тагын да ансатлашкан.

Фото: Бәйшенбәк Муканбәтов архивыннан

САБРИДДИН ТОИРОВ: «ТАТАРСТАННЫҢ КҮП ЮНӘЛЕШЛЕ ИКЪТИСАДЫНА ХЕЗМӘТ МИГРАНТЛАРЫ КИРӘК»

Елена Добровольская

КамАЗ, Яшел Үзән фанера заводы, СИБУРның Түбән Камадагы филиалы – Татарстанда Таҗикстаннан килгән хезмәт мигрантлары эшли торган кайбер предприятиеләрнең берничәсе генә әле бу. «Татарстан Республикасы таҗикларының милли-мәдәни автономиясе» төбәк иҗтимагый оешмасы җитәкчесе Сабриддин Тоиров әйтүенчә, бүген республикада рәсми рәвештә 13 меңгә якын Таҗикстан гражданы хезмәт куя.

Татарстанда яшәүче тагын шул чама таҗикның бүген ике гражданлыгы бар, ягъни алар инде Россия гражданнары да булып тора.

– Татарстанның икътисады күп юнәлешле, монда хезмәт ресурслары бик кирәк, – ди Сабриддин Мирзоевич. Аның әйтүенчә, республиканың зур предприятиеләре оешкан төстә Таҗикстаннан эшчеләр алып кайта һәм аларны укыта. Күбесе тиз арада югары квалификацияле белгечкә әйләнә.

Таҗикстан хезмәт мигрантлары арасында Татарстандагы төзелеш, кибет һәм базарларда эшләүчеләр дә бар. Республикада яшәү аларга зур проблемалар тудырмый. Сабриддин Тоиров әйтүенчә, Татарстанда халык дустанә, һәм әгәр мигрантлар үзләре яшәгән төбәк нормалары һәм традицияләренә хөрмәт белән карый икән (ә күпчелек очракта бу нәкъ шулай), алар хезмәттәшләре һәм күршеләре белән уртак телне җиңел таба.

Диаспора җитәкчесенә якташлары еш мөрәҗәгать итә торган сораулар нигездә нindiдер җитешмәгән документларга кагыла. Милли-мәдәни автономия мәдәни традицияләрне һәм туган телне сакларга тиешле иҗтимагый оешма булганлыктан, мигрантларга юридик мәсьәләләр буенча Таҗикстанның Уфадагы Генераль консуллыгына мөрәҗәгать итәргә киңәш бирәләр. Әмма Татарстан халыклары ассамблеясендә көч ведомстволары, миграция һәм салым хезмәтләре, шулай ук милли диаспоралар җитәкчеләре катнашында түгәрәк өстәлләр даими уздырылганга күрә, нindiдер катлаулы мәсьәләләрне Казанда да хәл итәргә булыша алалар.

Дәүләт органнары белән диаспораның тыгыз эше нәтиҗәсендә күптән түгел Таҗикстанның Татарстанда законсыз яшәүче кайбер гражданнарының язмышы уңай хәл ителгән. Аңлатып китик: Россия Президенты Указы нигезендә, Россиядә яшәү өчен законлы нигезләре булмаган чит ил гражданнарына 2025 елның 10 сентябренә кадәр илдән чыкмыйча гына үз хокукый статусын җайга салу мөмкинлеге бирелгән иде. Милли-мәдәни автономия вәкилләре үз ватандашлары белән мессенджерлардагы чатлар аша тыгыз аралашкан, аларны чыннан да депортация куркынычы булмауда, штраф белән генә котылып булуда ышандыра һәм моны эшләргә күндерә алган. Нәтиҗәдә, 400 дән артык кеше легальләшкән, хәзер алар республикада законлы нигездә эшли.

Таҗикстан Конституциясендә рус теле милләтара аралашу теле буларак беркетелгән. Илнең башкаласы Дүшәнбедә хәтта бөтен укыту рус телендә алып барыла торган сигез мәктәп тә бар. Әмма, әлбәттә, әгәр мигрантлар гаиләләре белән Таҗикстанның ерак районнарыннан килә икән, аларның балаларында телгә кагылышлы проблемалар туарга мөмкин. Монда, диаспора җитәкчесе ассызыклаганча, республика Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан таҗик балаларын җирле мәктәпләрдә укуга җайлаштыру өчен күп нәрсә эшләнә. Мәсәлән, Көектә күптән түгел генә ачылган лицейдагы 164 таҗик укучысы өчен рус телен чит тел буларак аерым укыту оештырганнар. Гомумән, таҗик балалары рус телен тиз үзләштерә һәм яхшы нәтиҗәләр күрсәтә. Моңа ачык мисал – Сабриддин Тоировның үз улы. Аның дүрт яшьлекулы Казанга килгәндә рус телен начар белгән. Бүген ул инде «Таможня эше» белгечлеге буенча университет тәмамлаган, уңышлы эшли, бирегә үз бизнесын үстерә.

Хәзер республикадагы таҗик диаспорасы махсус хәрби операция зонасындагы сугышчыларга гуманитар ярдәм күрсәтүдә актив катнаша. Татарстан таҗиклары фронтка ике автомобиль җибәргән, Лисичанскида һәм Курск өлкәсендә яшәүчеләргә икешәр миллион сумлык гуманитар ярдәм җыйган.

«Без алга таба да МХО сугышчыларына ярдәм итәчәкбез», – ди Сабриддин Тоиров.

Фото: Евгения Чеснокова

ТАТАРСТАН:

15 гыйнвар

РФ Президенты Указы нигезендә **Яшел Үзәнгә «Хезмәт батырлыгы шәһәре» исеме бирелде.**

20 гыйнвар

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театрының яңа бинасын ачу тантанасы. «Бинаның театр гына түгел, гаять зур мөмкинлекләргә ия мәйдан булачагына шик юк, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Бу – башкалабызның энҗе бөртеге. Һәм без, әлбәттә, аны республика өчен генә түгел, илебез өчен дә үзәк булдырырлык итеп кулланырга тиеш».

12–13 февраль

Ислам хезмәттәшлеге оешмасы (ИХО) илләре мәдәният министрларының Согуд Гарәбстанында узган конференциясендә **2026 елда ислам дөньясының мәдәни башкаласы итеп Казанны сайлау** турында карар бертавыштан кабул ителде.

30 май

«Алабуга» махсус икътисадый зонасында яңа буын Sollers SF5 коммерцияле җиңел автомобильләр җитештерүен ачу тантанасы узды. Ел ахырына кадәр яңа модельне локальләштерү дәрәҗәсе 70 процентка җитәр, дип планлаштырыла.

16 июнь

Казаннан Лисичанск һәм Рубежное (ЛХР) шәһәрләренә чираттагы гуманитар ярдәм озатылды. 19 фурадан торган гуманитар йөк «Бердәм Россия» партиясенең төбәк бүлеге химаясендә тупланды.

26 июнь

Казанда заманча материаллар өчен катализаторлар җитештерү буенча СИБУР заводы төзелешенә старт бирелде.

11 июль

«ТАНЕКО» заводлары комплексында гидрокрекинг-2 җайланмасы сәнәгать кулланышына тапшырылды. Ул елына 1,2 млн тонна вакуумлы газойль эшкәртәчәк һәм югары сыйфатлы продукция: дизель ягулыгы, нефть химиясе өчен нафта җитештерүне тәэмин итәчәк.

28 август

Татарстанда махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаиләләре өчен яңа торак программасы эшли башлады. Ул гаиләләргә социаль ипотека буенча фатир алырга мөмкинлек бирәчәк.

Фото: png.klev.club, flaticon.com, ru.freepik.com

ЕЛ ВАКЫЙГАЛАРЫ

13-18 май

Казанда «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» XVI Халыкара икътисадый форумы узды.

22 май

Әлмәттә елына 1000 тонна продукция чыгарырга сәләтле азык аксымы (гаприн) җитештерүен ачтылар. Чимал – газ эшкәртү заводларыннан алына торган метан.
Азык аксымы буенча үз базабызны булдыруга караган алдынгы технология гамәлгә ашырылды.

23 май

Түбән Камада «СИБУРИНТЕХ-НК» инженер-техник экспертизаны үстерү буенча укыту үзәге ачылды. Бу заманча җиһазлар куелган 42 уку аудиториясе, урамда 5 полигон, 47 стенд һәм тренажер. Үзәк елына 17 мең кешене, шул исәптән 2000 студентны һәм 1500 мәктәп укучысын укыта һәм аларга яңадан әзерлек үткәрә алачак. Проектка СИБУР керткән инвестицияләр күләме 1,8 млрд сумга якын.

16 июнь

Казанда Н. И. Сентябрев исемендәге «Рубин» футбол манежы ачылды.
Бу – барлык халыкара таләпләргә җавап бирә торган Футболны үстерү үзәген төзү буенча бик зур проектның башы.

26 июнь

Казанда Г. Камал исемендәге театрның яңа бинасында **31 нче «Алтын битлек» Россия милли театр премиясен тапшыру тантанасы оештырылды.**

1 октябрь

Лаеш районында «Батареон» компаниясенең литийлы-ионлы аккумулятор батареялары заводы эшли башлады. Анда сәнәгатьнең 30 тармагы өчен универсаль аккумуляторлар чыгарачаклар.

19 ноябрь

Яшел Үзәндә яңа «Турбина» сәнәгать паркы мәйданчыгында **газ-турбина җиһазлары җитештерү һәм ремонтлау буенча югары технологияле завод эшли башлады.**

3 декабрь

Балтач районы Кариле авылында «Балтач Арена» боз сарае ачылды. Өсте ябылган, ясалма бозлы шугалакта бер сменага 80 кеше шуа ала.

КӨНЧЫГЫШКА ЮЛ АЛАБЫЗ

КАМА АРЪЯГЫНДА ТАТАРСТАННЫҢ ӘҺӘМИЯТЛЕ ЛОГИСТИКА ПРОЕКТЫ ТОРМЫШКА АШЫРЫЛА

2025 ел Татарстанның логистика инфраструкурасы үсешендә әһәмиятле алга китеш этабы булып тора: Тукай районында урнашкан «Бер пояс һәм бер юл» контейнер терминалы үзенең тәүге операция циклын уңышлы төгәлләде. Эшләп киткәннән соң, проект тиз арада кыю идеядән республика тышкы икътисадый эшчәнлегенең гаять мөһим элементына әверелде.

Терминалны 2024 елның азагында эшләтеп җибәрделәр, ә инде 2025 елда ул ныклап аякка басты. Бүген терминал берьюлы 8 мең контейнерны сыйдырырга сәләтле, аның аша ел әйләнәсендә 100 мең контейнер уза ала. Склад куәтләренең суммар мәйданы 170 мең кв. метрны тәшкил итә, шул исәптән таможня контролендә вакытлыча саклау складларының 20 мең кв. метрын да үз эченә ала.

Казанда узган XVI БРИКС саммитында «Бер пояс һәм бер юл» проектын РФ Президенты Владимир Путин хуплап телгә алды, шулай ук ул Кытай Халык Республикасы Рәисе Си Цзыньпинга тәкъдир ителде.

РЕКОРДЛЫ ЙӨК АГЫМЫ

2025 елның гыйнварыннан ноябренә кадәр «Бер пояс һәм бер юл» контейнер терминалы искиткеч нәтиҗәләр күрсәтте. Бу вакыт эчендә терминалдан 13,5 мең контейнер узды, шуларның 7,7 меңе – йөк төялгән килеш. Шул вакыт аралыгында барлыгы 122 тимер юл составы кабул ителде һәм озатып җибәрелде. Шуларның 94 е экспорт йөкләре булса, 28 е – импорт буенча йөкләр. Йөк агымын анализлап карасак, экспортның өстенлекле булуын күрербез: аның буенча операцияләрнең күләме 6,1 мең контейнерны тәшкил итә. Импорт агымы исә 1,6 мең контейнердан гыйбарәт, ул да төбәктә яңа, инде җайга салынган маршрутлар буенча кирә торган әзер продукциягә, компонентларга ихтыяҗ барлыгын раслап тора.

Терминалның операцияләр башкару эшчәнлегендә рекордлы ай булып 2025 елның ноябре исәпләнә. Бу ай эчендә 1,2 мең экспорт һәм 338 импорт контейнеры узган. Әлеге күрсәткеч, ел башы белән чагыштырганда, куәтләрнең үсешен генә түгел, ә ун мәртәбәгә артуын да раслап тора. Димәк, без, проект буларак, терминалның тотрыклы үсешкә йөз тотуы турында әйтә алабыз.

Мондый динамика терминал күрсәткән хезмәткә югары ихтыяҗ булуын да дәлилли. Моннан тыш, бизнесның үсеп-үзгәреп торучан таләпләрен үти алуыбызны, алга таба тагын да колачлырак эшләргә әзер булуыбызны раслап тора.

Фото: «Бер пояс һәм бер юл» проекты архивыннан.

РЕКЛАМА

КЛИЕНТЛАР – ТАТАРСТАННЫҢ ӘЙДӘП БАРУЧЫ КОМПАНИЯЛӘРЕ

2025 елда Татарстан Республикасының иң эре сәнәгать гигантлары «Бер пояс һәм бер юл» контейнер терминалы йөк базасының экспорт буенча төп донорлары булды. Бу да терминалның гаять әһәмиятле проект икәнлеген күрсәтә. Атап әйткәндә, экспорт юнәлешендәге лидерларның берсе – нефть химиясе тармагы кластеры. Ул чит илдәге партнёрларына агымдагы елда 4,5 мең контейнер юллады. Татарстанның агросәнәгать комплексы да югары активлык күрсәтте: агропродукция белән чит илгә 262 контейнер озатылды.

Экспортның активлашуы белән беррәттән, 2025 елда терминал аша импорт агымының үсеше дә күзгә күренерлек артты. Импорт юнәлешендә лидерлар дип көнкүреш техникасы һәм автомобиль компонентлары җитештерә торган кластерларны атый алабыз. Терминал аша узган йөкләрнең төп категориясе үз эченә нәкъ менә автомобиль компонентларын, көнкүреш техникасын һәм машина төзелеше өчен кирәк-яракларны алган булып чыкты.

ТАТАРСТАН ӨЧЕН ИКЪТИСАД ЭФФЕКТЫ

«Бер пояс һәм бер юл» терминалының йогынтысы транспорт операцияләрен генә күздә тотмый, әлбәттә. Татарстан өчен бу проектның комплекслы һәм киң колачлы икътисадый эффекты – бәхәссез. Нефть химиясе, агросәнәгать продукцияләре һәм башка товарларны читкә озату буенча да яңа уңайлы, үтемле каналлар формалаша, бу исә, үз чиратында, Татарстан җитештерүчеләренә товарларын тәкъдим итү базарында иркенрәк эш итәргә һәм халыкара аренада конкурентлыкка сәләтләрен сынарга, аны үстерергә мөмкинлек тудыра. Төбәктәге предприятиеләр шул рәвешле тиешле техниканы, комплектлау өчен кирәк-яракларны, сәнәгать товарларын тизрәк тә, арзанрак ысул белән дә кертә ала. Бу җитештерү чыгымнарын киметә, җирле предприятиеләрнең тотрыклырак эшли алуына уңай йогынты ясый. Моннан кала, үзебезнең җитештерүчеләр өчен логистика чыгымнары да кими төшә, йөкләрне илтеп җиткерү ягыннан да уңайлыклар арта.

Республиканың логистика хабы буларак җәлеп итүчәнлегенә яхшы хезмәт итә яңа проект. Терминалның үсеше Татарстанның транспорт һәм логистика үзәге буларак дәрәҗәсен, абруен күтәрә. Димәк, безгә яңа инвестицияләр киләчәк, яңа сәнәгать кластерлары формалашуга мөмкинлек артачак, дигән сүз.

Терминалның үсеше һәм эшчәнлеген киңрәк җәелдерүе логистикада гына түгел, аңа төрдәш тармакларда яңа эш урыннары ачарга ярдәм итә. Тиешле инфраструктураларны үстерергә этәргеч бирүе дә әһәмиятле, мәсәлән, юллар челтәрен, склад комплексларын, сервис оешмаларын. Тулаем алганда, яхшы итеп корылган логистика инфраструктурасы – инвесторларның төбәк белән кызыксынуына зур йогынты ясый торган фактор ул. Шулай булгач, республика территориясендә үз җитештерүләрен ачарга әзер булган чит ил инвесторлары белән үзебезнең җитештерүчеләр арта гына барачак, дип фаразлый алабыз.

2025 елда ирешкән уңышлар контейнер терминалының ныклы нигезе бар, дип ышанырга һәм аның үсеше буенча алга таба тагын да колачлырак планнар корырга мөмкинлек бирә. 2026 елга фаразлар операцияләрне колачлырак итүне, яңа офыкларга чыгуны күздә тота. Терминалда, вакытлыча саклау склады зонасын 20 мең квадрат метрга кадәр җәелдереп, таможня инфраструктурасын булдырырга ниятлиләр. Бу, үз чиратында, импортны тагын да ныграк җәлеп итәчәк. Шулай ук, 1,1 километрга сузылачак өстәмә 10 линия кертеп, тимер юл фронтын киңәйтү уе да бар.

2026 елда «Бер пояс һәм бер юл» терминалы аша 12 меңгә кадәр контейнер узачак, дип планлаштырыла.

ЭЛЕКТР ЧЕЛТӘРЛӘРЕ: АКЫЛЛЫ МОДЕЛЬ

Алар электр энергиясен куллануны тикшереп торалар, урлау очракларын ачыклыйлар. Челтәрдә өзеклекне табалар, аннары – бер минут эчендә! – кеше катнашыннан башка гына төзәтеп тә куялар. Ниһаять, клиент мөрәҗәгать иткәндә, иң дөрес юлны табып, тиз арада җавап та бирәләр. Бу – «Челтәр компаниясе» АҖ тарафыннан актив гамәлгә кертелә һәм кулланыла торган ясалма фәһем технологияләре нигезендәге эшләрнең кайберләре генә.

Ясалма фәһем технологияләре модага иярү түгел, ул финанс югалтуларын киметергә һәм клиентларга хезмәт күрсәтүне камилләштерергә булыша торган реаль көч булуын күрсәтте.

– Соңгы 10 ел эчендә безнең компаниядә электр энергиясен югалту – 19,3 процентка, авария вакытында энергияне өзеп торуның дәвамлылыгы – 80,3 процентка, кулланучыга ут бирми торуларның ешлыгы 86 процентка кимеде. Бу ясалма фәһем дә кергән комплекслы эшчәнлек нәтиҗәсе, – дип сөйләде цифрлы трансформацияләр һәм ЯФ буенча генераль директор урынбасары Тимур Корбангалиев.

Бүген компания үз хезмәткәрләрен эзлекле рәвештә яңа технологияләргә өйрәтә. Якындагы ике ел эчендә ЯФ бөтен юнәлешләргә дә үтеп керәчәк, диләр компаниядә. Биредә оештырылган аналитика үзәге бер ел эчендә генә дә, ясалма фәһемгә таянып, 8 проектны гамәлгә ашырды. Иң зур проектлар арасында – энергия югалтуларны фаразлау, клиентларның мөрәҗәгатьләрен эшкәртүне һәм диспетчерлар белән аралашканда сөйләмне аеруны автоматлаштыру. Барлык бу проектлар – күп яктан революцион.

НЕЙРОЧЕЛТӘР «ЭНЕРГИЯ КАРАКЛАРЫН» ТОТАЧАК

Иң мөһим яңалыкларның берсе – «Нейрон челтәр ярдәмендә электр энергиясен исәпкә алмыйча тотуны эзләү» проекты. Энергия саклау һәм энергетиканың нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә иң яхшы казаныш өчен, ул инде республика конкурсының Гран-приена да ия була. Шунысын да әйтик: әлегә кадәр электр энергиясен исәпкә алмыйча тотуга кагылышлы җитди проблемага каршы асылда кулдан гына көрәшәләр иде. Мәсәлән, бер белгеч көненә 15–20 абонентны тикшерергә өлгерә – бу диңгездәге бер тамчы кебек. Хәзер исә «энергия каракларын» ясалма фәһем ачыклаячак. Бу хисапка алу буенча акыллы счетчиклар урнаштыру нәтиҗәсендә мөмкин булачак. Алар секунд саен зур күләмдәге мәгълүматны эшкәртергә сәләтле, «күп мәгълүмат» массивларын туплый ала. Мәгълүмат исә «Челтәр компаниясе» АҖ серверларында саклана.

– Безгә 2000 нән артык намуслы кулланучы һәм элегрәк түләүсез кулланулары теркәлгән 150 клиент турында мәгълүмат кирәк. Ул чистартылган һәм эшкәртелгәннән соң, нейрон челтәрен өйрәтергә юлланды, – дип сөйләде проект авторы – «Челтәр компаниясе» АҖнең ясалма фәһем карарларын эшләү бүлеге башлыгы Шамил Яхин. – Модельләр белән эш итү өчен программа яздык. Аны йөкләнеш графигындагы гадәти булмаган тайпылышлар нигезендә электр энергиясен куллануның шикле очракларын ачыкларга өйрәттек. Хәзерге вакытта мәгълүмат эшкәртү тизлеге – сәгатенә 800гә якын абонент.

Аналитика үзәге белгечләре энергия югалтуларны фаразлау өчен машина өйрәтүен (Random Interval Classifier) куллана. Система зур күләмдәге мәгълүматны эшкәртә һәм сезон факторын, технологик кушылуның егәрен һәм акыллы исәпләү приборларыннан алынган күрсәткечләрне дә истә тота. Ясалма фәһем куллану графигына анализ ясый һәм электрны исәпләмичә тоту очракларын ачыклый, төгәллек – 92 процентка кадәр. Бу компания белгечләренә приборга рөхсәтсез кушылуларны ачыкларга да булыша.

ЭШТӘГЕ БЕРТӨРЛЕЛЕККӘ КАРШЫ ЧАРА

Икътисадый нәтиҗәлелектән тыш, тагын бер мөһим яңалык клиентларга хезмәт күрсәтүнең сыйфатын тагын да югарыракка күтәрергә вәгъдә итә. Ясалма фәһем нигезендәге проект нәкъ менә клиент мөрәҗәгатьләрен эшкәртү өчен каралган да. Бу очракта ЯФнең бурычы – мөрәҗәгатьләрне мөмкин кадәр тизрәк җавап бирерлек итеп эшкәртү, бертөрле операцияләрне автоматлаш-

Фото «Челтәр компаниясе» АҖнән алынды. РЕКЛАМА

тыру (мәсәлән, технологик тоташтыруга гаризалар, мөрәҗәгатьләр статусы буенча консультацияләр) һәм индивидуаль якын килүне таләп итә торган катлаулы сорауларны хәл итү өчен хезмәткәрләрнең вакытын бушату. Фаразлар буенча, компания өчен икътисадый файда шактый саллы булачак: стандарт мөрәҗәгатьләрне эшкәртүне тизләтү һәм персоналга йөкләнешне киметү хисабына операцион чыгымнар 25 процентка кимеячәк.

Эш сыйфатын яхшыртуга килгәндә исә, алдынгы технологияләрне куллану клиентларга хезмәт күрсәтүгә сизелерлек уңай йогынты ясаячак. 2024 ел мәгълүматларына караганда, читтән торып хезмәт күрсәтү үзәкләрендә «Челтәр компаниясе» экспертлары тарафыннан 30 мең мөрәҗәгать каралган, аларның 12 меңе ясалма фәһем тарафыннан да уңышлы эшкәртелергә мөмкин булган сораулар категориясенә керә. Шул рәвешле, нейрон челтәренең эше типик сорауларның 40 процентына җавап бирергә, кеше факторы аркасында хаталарны киметергә, белгечләргә клиентларның үзенчәлекле ихтыяҗларына тирәнрәк төшенергә һәм сыйфатлырак хезмәт күрсәтергә мөмкинлек бирәчәк.

Өстәп шуны әйтергә кирәк: бүген ЯФ диспетчерларга сөйләшүләрне максималь рәвештә файдалы һәм нәтиҗәле итеп алып барырга булыша. Ни рәвешлеме? Элек сөйләшүне бәяләү сөйләшү үзе күпме дәвам иткән булса, шулкадәр вакытны ала иде. Хәзер ЯФ сөйләшүне секунд эчендә анализлый, хаталарны ачыклый һәм диспетчерга кирәкле инструкцияне әйтеп җибәрә. Киләчәктә система тарихи мәгълүмат нигезендә аварияләрне фаразлый алачак.

SMART GRID БАРЫСЫН ДА ҮЗЕ ЭШЛИ

Прогресс юлында җитди адым – акыллы электр челтәрләре (Smart Grid), аларны «Челтәр компаниясе» АҖ үз эшенә кертә. Яңалыкларның асылы шунда: шәһәр һәм авыл бүлү челтәрләре өзеклекләрне ачыкларга һәм изоляцияләргә, кеше катнашыннан башка аларны ялгарга, торгызырга сәләтле автоматлаштырылган платформага күчерелә. Моның өчен уртача бер минут вакыт җитә. Сүз аерым очрак түгел, ә инновацияле технологияне күпләп һәм эзлекле рәвештә гамәлгә кертү турында бара: ул Казан челтәрләренең 35 проценттан артыгын һәм авыл челтәрләренең 60 процентын колачлый.

Татарстанда Smart Grid проекты бүленгән архитектурага нигезләнә: трансформатор һәм бүлү пунктлары (ТП, РП) контроллерлар, кыска ялганыш индикаторлары һәм телеидарә ителешле коммутация техникасы белән җиһазландырыла. Җайланмалар горизонталь элементәләре булган бердәм мәгълүмат челтәренә берләштерелә – һәр элемент, күрше участокның торышына карап, үзеннән-үзе конфигурацияләнә. Өзеклек барлыкка килгәндә, акыллы модульләр үзара хәбәр алмаша, зарарланган участокны изоляцияләү алгоритмын автоматлаштыра һәм өзеклекне ялгау өчен күчерүләр чылбырын формалаштыра. Барлык операцияләр автомат рәвештә читтән торып башкарыла.

Smart Grid кертү челтәрнең тотрыклылыгын сизелерлек ныгытты инде: 10 ел эчендә ышанычлылык күрсәткечләре 10 тапкырдан артыкка яхшырды – SAIDI хәзер 10 минут чамасы, SAIFI – 0,177, бу югары халыкара стандартларга туры килә.

Проект түбәндәге мөмкинлекләрне бирә:

* авария хәлендәге бер очракны төзәтү өчен транспорт чыгымнарын 3–4 тапкырга кыскартырга;
* бер зыян күрү урынын эзләү буенча хезмәт чыгымнарын уртача 8 кеше-сәг.кә киметергә;
*өзеклекне автомат рәвештә ялгау нәтиҗәсендә электр энергиясен биреп бетермәү күләмен азайтырга.

Ясалма фәһемгә таянып автоматлаштыру сүндереп торулар санын һәм вакытын киметә, көнкүреш һәм сәнәгать кулланучылары өчен уңайсызлыкларны азайта һәм челтәр компаниясе эшенең икътисадый нәтиҗәлелеген арттыра. Тармак өчен проект, акыллы җайланмалар, телемеханика һәм бүленгән алгоритмнар кулланып, бүлү челтәрләрен цифрлаштыруга масштаблы якын килү үрнәге булып тора. «Челтәр компаниясе» АҖндә билгеләп үткәнчә, инновацияле карарлар ышанычлылыкны арттырырга гына түгел, операцион чыгымнарны оптимальләштерергә дә мөмкинлек бирә, республика электр челтәрен экренләп хезмәт күрсәтүнең заманча интеллектуаль моделенә күчерә.

команда RSI GARANT

RSI GARANT[1]: ТЫШКЫ БАЗАРГА СЕЗ САЛГАН ЮЛ

2025 елда Россиянең тышкы сәүдә түләү системасы тулысынча SWIFTтан башка эшләүгә күчте. Әле ике-өч ел элек кенә чикләүләргә котылгысыз реакция буларак кабул ителгән бу ихтыяҗ бүген инде халыкара исәп-хисап юнәлешендә тотрыклы инфраструктурага әверелде.

Үзәк банк финансларны тапшыруның милли системасы аша трансчик операцияләренең эксперименталь режимын киңәйтте. Бу, үз чиратында, базарга яңа маршрутлар төзергә һәм Азия банкларын турыдан-туры Халыкара финанс хәбәрләрен тапшыру системасына (МСПФС) кушарга мөмкинлек бирде. Шул рәвешле, түләүләр тизрәк уза башлады, сату агентлары аша уза торган сделкалар саны артты. Алар үз чиратында юрисдикцияләр арасында комплаенс-тәэмин ителешле элемтәне һәм юридик ярдәмне дә исәптә тотарга булыша.

2025 елның гыйнвар – сентябрь айларында Россиянең тышкы сәүдә күләме 503,9 млрд долларны тәшкил итте, шулардан экспорт – 302,8 млрд, ә импорт – 201,1 млрд. Кытай төп статусын саклап

Ярослав Салиев, физик һәм юридик затларга финанслар күчерү һәм финансларны алмашу буенча RSI GARANT халыкара сервисына нигез салучы.

кала бирә: Россия товар әйләнешендә аның өлеше 35% тан артып китте, өстәвенә, үзара түләүләрнең 70% тан артыгы SWIFT инфраструктурасыннан читтә – CNYда турыдан-туры исәп-хисаплар аша уза. Шулай ук банкара каналлар һәм альтернатив түләү схемалары да үзенең әһәмиятле ролен үти. Шул ук вакытта Кытай банклары транзакцияләр буенча тикшерүләрне көчәйтә, бу кече һәм урта бизнес өчен турыдан-туры күчерүләрне сизелерлек дәрәҗәдә катлауландыра.

Нәкъ менә шуңа күрә 2025 елда базарда халыкара түләүләрнең махсуслаштырылган операторлары роле бик тиз үсә. Түләү агентлары маршрутларны оптимальләштерә, акчаларның дустанә юрисдикцияләр аша үтүен тәэмин итә, килешүләрне документаль рәвештә озата бара һәм контрагентларны тикшерүне үз өстенә ала. Кытай сегментында бу чын мәгънәсендә зарурияткә әверелде: бизнеска акча җибәрү генә түгел, ә ул акчаларның имин һәм дөрес юллар белән узуын да гарантияләргә кирәк. Шул исәптән, инвойсларны CNY аша түләүне, локаль карталарга күчерүләрне, Alipay, WeChat һәм ил эчендә юань алу ихтыяҗларын да исәптә тотып.

Бу фонда RSI GARANT кебек тулы цикллы сервислар тышкы икътисадый эшчәнлекнең төп коралына әверелә. Компания Кытайга җибәрелүче һәм аннан китерелүче товарлар өчен түләүләрне колачлый, халыкара OTC-операцияләрне, Гонконг, Кыргызстан, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Төркия һәм Европа аша исәп-хисапларны, шулай ук КХР эчендә CNY белән эшләүне дә тәэмин итә. Күпчелек компанияләр өчен бу уңайлык кына түгел, ә халыкара түләүләрнең SWIFT чикләүләренә һәм локаль банк сәясәтләренә бәйсез рәвештә эшли торган тотрыклы каналы.

RSI GARANT компаниясенең ел нәтиҗәләре бүгенге базарның трансформациясен чагылдыра. Сервис инде 5 ел эшли, ул 12 000нән артык кешедән торган актив клиент базасын формалаштыра. Шулай ук RSI GARANT – Россия һәм халыкара форумнарның даими катнашучысы, банкларның партнёры, ул банкларга да, шәхси клиентларга да цифрлы финанс активлары буенча консультацияләр дә бирә. Алар хакында РБКда материаллар бастырыла, команда әйдәп баручы AML-системалар белән эшли, Россиядәге һәм чит илләрдәге үз инфраструктурасына таяна. Бу югары ликвидлыкны, килешүләрнең тиз үтәлешен, юридик ярдәм күрсәтү һәм 40 илдә 7 валютада эшләү мөмкинлеген бирә.

Узып баручы ел шуны раслый: халыкара исәп-хисаплар профессионаллар территориясенә әверелә. Бүген Кытай белән югары дәрәҗәдә эшләргә теләгән бизнес өчен ышанычлылык, тизлек һәм операцияләрнең юридик чисталыгы – өстенлекләр түгел, ә яңа стандарт. RSI GARANT бу стандартны 2026 елда тагын да ныгытуын дәвам итәчәк.

[1] Эр-Эс–Ай Гарант
[2] Банк күчерүләре өчен финанс ысулларын алмашуның халыкара системасы.
[3] Кытай юане. [4] Акчалата түләү.
[5] Кытай күпмаксатлы кушымтасы.
[6] AML (Anti-Money Laundering) – Акча юуларга каршы көрәш.

Фото: «Эр-Эс-Ай Капитал» ЖЧҖнән алынды. РЕКЛАМА

GARANT
КЫТАЙ БЕЛӘН ЭШ ИТКӘНДӘ
АДЫМНАРЫН АЛДАН УЙЛАП КУЮЧЫЛАР ӨСТЕН ЧЫГА
КЫТАЙДА ҺӘМ ДӨНЬЯ КҮЛӘМЕНДӘ ЫШАНЫЧЛЫ ТҮЛӘҮЛӘР:
ЭКСПОРТ ҺӘМ ИМПОРТ КОНТРАКТЛАРЫ БУЕНЧА ТҮЛӘҮ АГЕНТЫ ХЕЗМӘТЕН КҮРСӘТҮ
“ЭР-ЭС-АЙ КАПИТАЛ” ҖЧҖНӘН АЛЫНДЫ
ООО «Эр-Эс-Ай Капитал». РЕКЛАМА



ТЫНЫЧЛЫК ХАКЫ:

ГАЗ ӨЧЕН ВАКЫТЫНДА ТҮЛӘҮ – УЛ АКЧА ГЫНА ДИГӘН СҮЗ ТҮГЕЛ...

Цифрлы сервислар һәм автомат түләүләр заманында коммуналь хезмәтләрне вакытында кертеп бару нибары техник мәсьәлә генә шикелле. Әмма без газ өчен үз вакытында түләү кебек гади генә гамәлебезнең финанс ягыннан да, юридик яктан да тулы бер куркынычсызлык комплексы белән тәэмин ителүен яхшы белергә тиешбез. «Газпром трансгаз Казан» ҖЧҖ җиде төп юнәлеш мисалында безгә түләүнең һәр айның 10 нчы числосында узуы формаль булмавын, ә үзебезнең иминлеккә инвестиция дә икәнен аңлата.

Бүген өйдәге җылылык һәм кайнар ризык әзерләү мөмкинлеген без табигый һәм гадәти күренеш буларак кабул итәбез. Әмма бу хезмәтләрнең өзексезлеге тәэминатчылар белән мөнәсәбәтләребезгә турыдан-туры бәйле. Газ өчен даими һәм вакытлы түләү шарт кына түгел, ә үз өеңдә иминлек, җитешлек булсын өчен, көнкүрешне дөрес итеп алып бара белү дә дигән сүз ул.

«Газпром трансгаз Казан» ҖЧҖ, социаль яктан җаваплы компания буларак, абонентларына түләү срокларына җитди карауны таләп итеп куя. Бу мәсьәләгә түләү итеп кенә түгел, ә киңрәк карауны да сорый. Газ өчен түләү килешү шартларын үтәү генә булып калмыйча, финанс куркынычсызлыгын кайгырту һәм күңел тынычлыгына гарантия дә. Боларны раслый торган җиде мәсьәләгә тукталып узыйк әле.

1. ФИНАНС ЯГЫННАН ФАЙДА: ӨСТӘМӘ ЧЫГЫМНАРГА ЮЛ КАЛДЫРМЫЙК

Соңга калып түләгән өчен өстәмә акча – пени алу абстракт төшенчә генә булып күренергә мөмкин, әмма бу, ни генә булмасын, сезнең кесәгездән башка нәрсәләргә тотарга тиешле акчагыз чыга, дигән сүз. Закон тарафыннан кулланылган газ өчен исәп-хисап вакыты – айның 10 нчы числосына кадәр, аннан яңа срок башлана. Шуны истә тотып түләп бару – артык суммаларны сарыф итмәү өчен иң гади ысул.

2. ЮРИДИК ИММУНИТЕТ: СТРЕССЛАРСЫЗ ГЫНА ЯШИК

Бурыч ул квитанциядәге саннар гына түгел, ә ситуацияне суд аша хәл итүгә китерә ала торган сәбәп тә. Бурычны түләтү һәм суд юлына йөртү өстәмә вакытыгызны да алачак, нервларыгызны да талкыячак. Шулай ук суд һәм юрист хезмәтләре чыгымнарын да сезгә күтәрергә туры киләчәк. Вакытында түләп бару – тыныч тормышка һәм хокук ягыннан иминлеккә гарантия.

3. КРЕДИТ ТАРИХЫ: МӨМКИНЛЕКЛӘРГӘ ИШЕК АЧЫЙК

Бүгенге көндә кредит тарихы ул – кешенең финанс ягыннан дисциплиналы булуына дәлил һәм түләүченең визит карточкасы. Вакытында кертелмәгән коммуналь түләүләр

Фото: «Газпром трансгаз Казан» ҖЧҖ нән алынды. РЕКЛАМА

кредит тарихлары бюросына тапшырыла, анда 10 елга кадәр саклана. Начар кредит тарихы ипотека, автомобиль кредиты алганда, шулай ук сезнең өчен кулай кредит картасына дәгъва иткәндә, киртә булырга мөмкин.

4. АКТИВЛАРНЫ САКЛАУ: БУЛГАН МИЛЕКНЕ ҺӘМ КЕРЕМНӘРНЕ БӘРӘКӘТЛЕ ТОТЫЙК

Булган бурыч суд хөкеме нигезендә билгеләнгәннән соң, приставлар банк счётларына һәм барлык милеккә арест салырга, шулай ук эш хакының бер өлешен алып калырга, пенсия, башка керемнәрне бурычны каплар өчен кисәргә дә мөмкин. Вакытында түләү – финанс активларын шундый хәтәрләрдән саклау юлы да.

5. ИРКЕНЛӘП ЙӨРҮ ХОКУКЫ: ТОРМЫШКА ЧИКЛӘР КУЙМЫЙК

Бурычны кайтару буенча суд чыгарган карарны тиешле вакытында үтәмәү чит илгә чыгуга чик куя ала. Отпуск планлаштырган вакытта, эшлекле командировкага йә булмаса чит илдә укырга барырга җыенганда, газ өчен түләмәү очрагы бөтенләй кирәк булмаган проблемага әверелергә мөмкин.

6. УҢАЙЛЫККА ГАРАНТИЯ: ҖЫЛЫЛЫК ҺӘМ РӘХӘТЛЕКНЕ ТӘЭМИН ИТИК

Закон буенча, 2 айдан да артык түләмәү очрагында тәэминатчы газ бирүне туктатырга хокуклы. Димәк, сез җылылыктан да, кайнар судан да, газ плитәсен куллланудан да мәхрүм калачаксыз дигән сүз. Мондый хәл – бөтен гаилә өчен дә көтелмәгән уңайсызлык, әлбәттә.

7. КИЛӘЧӘККӘ КАРАП ЭКОНОМИЯЛӘҮ: ӨСТӘМӘ ЧЫГЫМНАРНЫ АЛДАН КИСӘТИК

Туктатылган газны яңадан бирдерү – ул бурычны түләү генә түгел, ә өстәмә пениларны каплау һәм техник эшләр өчен китәчәк акча да. Андый чыгымнар гадәттә айлык суммадан ике тапкырга зуррак була. Ⓣ

ЦИФРЛЫ СЕРВИСЛАР

«Газпром трансгаз Казан» җәмгыяте экологияне саклауга йөз тотып эшли, шуңа да электрон квитанцияләргә күчүне актив рәвештә алып бара. Бүгенге көндә абонентларның күпчелеге газ өчен түләү һәм техник тәэмин итү квитанцияләрен электрон рәвештә ала. Электрон квитанцияләргә күчү берничә өстенлеккә ия:

ЭКОЛОГИЯНЕ САКЛАУ: электрон квитанцияләр кәгазьне янда калдыра, димәк, өстәмә калдыклар булмый, аларны җитештерергә дә, утильгә чыгарырга да кирәкми.

УҢАЙЛЫЛЫК: электрон квитанцияне алу һәм түләү тиз. Моннан тыш, түләүләр, газ приборларының күрсәткечләре һәрвакыт сезнең кул астында дигән сүз.

Кәгазь квитанцияләрдән баш тартып, без ел саен 35 ел буена үскән 400 төп агачны, ягъни тулы бер агачлыкны саклап калабыз. Татарстан Республикасы халкына «Газпром трансгаз Казан» ҖЧҖ заманча карарлар тәкъдим итә: күпфункцияле мобиль кушымталардан файдалану. Болар – paygas.ru порталындагы Шәхси кабинет һәм «Газ өчен түләү» махсус кушымтасы.

- **Җәһәт түләүләр:** комиссиясез генә теләсә кайсы банк картасы белән күз ачып йомганчы акча күчерү. Срокларны истә тотарга теләмәсәгез, акчаны айга бер тапкыр автомат күчерү ысулын көйләгез.
- **Автотүләү:** үтәкүренмәлек. Түләүләр белән күрсәткечләр барысы да бер тәрәзәдә чагыла.
- **Идарә итү:** күрсәткечләрне тапшыру, электрон квитанцияләрне күрү, исәп приборлары турындагы мәгълүмат – барысы да биредә.
- **Тәэмин итү:** контакт-үзәк хезмәткәрләренә кушымта аша сорау бирергә һәм җавап алу мөмкинлеге.

Газ өчен вакытында түләү – компания таләбе генә түгел, финанс ягыннан тотрыклылыкка, юридик яктан тынычлыкка, өйдә өзеклекләрсез уңайлы шартларга таба атлаган зирәк адымыгыз да. Асылда – гап-гади ритуал, ләкин аның бәһасе – иминлек, нәтиҗәсе – иртәгәге көнгә ышаныч. Заманча сервислардан файдаланыйк, бюджетны алдан планлаштырып куйыйк. Ә Яңа елны бурычларсыз, борчуларсыз каршы алыйк.

Мобиль кушымталарның өстенлеге турында

Абонентның шәхси кабинеты

Мобиль кушымта

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫН САТЫП АЛЫРГА

ozon.ru

market.yandex.ru

tatmedia.shop/ru

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНДА РЕКЛАМА БИРЕРГӘ

Рәссам Л. Гамбургер эше. 1925 ел

«Татарстан» журналының реклама бүлеге:

тел.: (843) 222-09-79, 8-9600-487-900, 8-9033-132-741

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ ЯҢАЛЫКЛАРЫН УКЫРГА

protatarstan.ru

t.me/pro_tatarstan

vk.com/protatarstann

Реклама 16+

акыллы гамәлләр

игелекле эшләр

мәңгелек кыйммәтләр /

Бу санда тәкъдим итәбез:

Ни өчен Казанда чыршы бәйрәмнәрен тыялар

Чыршы уенчыклары киләчәккә **ничек** йогынты ясый

Надежда Моратова урланган балаларның мәнфәгатьләрен **ничек** яклый

Фатирны **ничек** дөрес итеп мираска калдырырга һәм кабул итеп алырга

Бөек Җиңүгә 80 ел тулу уңаеннан, «Кырык беренче ел балалары» рубрикасын дәвам итәбез. Бу юлы Бөек Ватан сугышы елларында өлкәннәр белән бергә тормыш арбасын җигелеп тарткан гади бер авыл баласының язмышын бәян итәбез.

Фото автордан алынды

«ӘЙ, ӘНИ, МИНЕ ШУШЫ НУЖАГА ДИП КАЛДЫРДЫҢМЫ?»

Әлфия Шаһиева

– Әни белән әтинең дәү апасы әткәйне озатырга районга киткән. Фин сугышыннан кайттым, моннан кайта алмам, бәхил булыгыз, дип саубуллашкан әти. Күңеле сизгән, ахрысы – бу юлы ул, чыннан да, әйләнеп кайта алмады. Башта хәбәрсез югалганнар исемлегендә булган, үлем турында хәбәрне 1941 елның декабрендә китергәннәр, – дип башлап җибәрде сүзен Рәйхана апа.

Рәйхана Хисамова ул вакытта Апас районына кергән (хәзер – Олы Кайбыч районы) Иске Чәчкаб авылында 1942 елның февралендә дөньяга аваз сала. Әмма ул әтисенең бу дөньядан инде киткәнен, аннан башка тормышта ятимлек ачысын татып үсәсен белми әле...

«ШӘТ, ШУННАН РӘХӘТ КҮРЕРСЕҢ, БАЛАМ...»

Иң аянычы – Гыйлэҗетдин абый да фронтка бердәнбер кызы туасын белмичә киткән. Хәер, Мәйсәрә апа да көмәнле булып калганын ирен сугышка озаткач кына аңлаган.

– Әтине озаткач, күпмедер вакыттан соң, әни эшкә – уракка төшкәч, йөкле икәнен аңлаган һәм бик борчылган. Тәтәби (әнисенең әнисе – **авт.**): «Шәт, шуннан рәхәт күрерсең, балам...» – дип, баланы табарга киңәш биргән. Мин еш кына, ачуланып: «Әй, әни, ник мине калдырдың, шушы нужаларгамы?» – дия идем. Туасы җан булганмын инде, күрәсең. Әнине картлык көнендә үзем тәрбияләдем, соңгы сулышын минем кулда бирде. Үз гомерендә рәхәт күрмәгәндер ул. Миңа 3 ай булганда, әтинең сеңелләре: «Кызың да, үзең дә кирәкмисең», – дип, безне өйдән куып чыгарган. Әнкәй, гарьләнеп, капка төбенә чыгып утырган. Шулчак югары очтан әнинең бертуганы – кечкенә апа төшеп килә икән. Безне күреп: «Мәйсәрә, нишләп утырасың?» – дигән. «Менә, өйдән куып чыгардылар. Кая барыйм инде хәзер, йә, шушы сабый белән?» – дип, елап җибәргән әни. Төп нигездә абый, килен, дүрт малай бар. Гаилә зур. Анда кайтып булмый... Аллаһка мең шөкер, кечкенә апа безне калдырмаган. Икенче урамда Рабига исемле бер хатын ялгыз яшәп, көн күреп яткан. Ире сугышта ятып калган. Шул мәрхәмәтле хатын йортына безне дә сыендырган.

Бераз хәлләнгәч, Мәйсәрә апа, этисе һәм күршеләр ярдәме белән, йорт салып чыккан. Баштарак йортның тәрәзәләрендә пыяла да булмаган, капкасы да ясалмаган килеш торган. Шулай бернәрсәсез яңа ызбага чыгып утырган ятимнәр.

«УЛ ӨЙРӘТКӘН ДОГАЛАР ӘЛЕ ДӘ ХӘТЕРЕМДӘ»

– Әнием гомере буена савымчы булып эшләде. Йомшак күңелле, сабыр, тыйнак кеше иде, – дип, хатирәләрен дәвам итә Рәйхана апа. – Ирсез яшәде, кабат кияүгә чыкма-

Апабызга 80 яшь

Иске Чәчкаб авылында яшәүче әби-бабабызның җиденче баласы һәм бүгенге көндә шул балалар арасында берданбер исән булган Мәйсәрә апага 24 декабрьдә декабрьдә 80 яшь тула. Ул 40 елга якын "Правда" колхозында ("Беренче май") сыерлар сауды. Аның исеме мактау такталарыннан төшми иде. Аңа дәлил итеп узган еллардан бер истәлекле язма китерәсем килә. Бу язма "Колхоз бригада"сының 1954 елда чыккан 5 сентябрь санында чыккан.

"Беренче май" исемендәге колхозның алдынгы сыер савучысы Мәйсәрә иптәш Хисамова күп еллардан бирле колхозда сыер савучы булып эшли. Ул артельның сыер савымчылары социалистик ярышында алдынгы урын алып тора. Иптәш Хисамова 1953 елның 1 сентябреннән быелгының 1 сентябренә кадәрге вакыт эчендә үзенә бирелгән 10 сыердан 11596 литр сөт савып алды.

Рәсемдә: колхозның алдынгы сыер савымчысы Мәйсәрә Хисамова.

Апабыз нәселебезнең — (Мөхсин — Имәнгөл — Ибраһим — Габдулла — Габделшәкүр — Ситдыйк) горурлыгы. Аның ире, безнең җизнәбез Гыйләҗ Хисамов (нәселләре — бабалары Надириса — Хәбибулла — Хәмбих — Гобәйдулла — Вәлиулла — Бикмулла — Хисаметдин). Ватан сугышында хәбәрсез югалды, ләкин апабыз аңа гомерлеккә тугырылыклы булып, үзенең сагышларын хезмәттә һәм берданбер кызы Рәйхана белән уртаклашып яшәвен дәвам итте. Рәйхана, гомере буе сыер савып, лаеклы ялга чыкты. Мәйсәрә өчен ялкаулык, эшсезлек, булдыксызлык, сабырсызлык ят нәрсә булды. Ул һәрвакыт намуслы һәм кешеләргә, туганнарга, мәрхәмәтле, ярдәмчел булып кала белде. Без — аның абыйсы Галимҗан һәм Миңнехәнифә җиңгәсе, балалары Гөлфәрүз, Кадыйрҗан, Фәүзия һәм Фазылҗан кадерле "тәти" апабызны чын күңелдән ихтирам итеп, 80 яшь тулу көне белән тәбрик итәбез һәм аңа озын гомер, сырхаусыз көннәр, сызлаусыз төннәр, зур бәхет, тынычлык, оныклары һәм ярдәмчел, мәрхәмәтле кызы Рәйхана белән иркен тормышта яшәвен телибез.

К.Галимов, Ф.Шәкүров, Г.Борһанова, Ф.Садыйкова, Чәчкаб авылы.

ды. Динле булды, намазлар укый иде. Миңа да догалар өйрәтте. Хәер, догаларны бер ул гына өйрәтмәде, энинең дәү апасы да. Ул да безнең белән яшәде. «Мәйсәрә барыбер кияүгә китәр, тор шуларда, Рәйхананы карап үстерерсең», – дигән туганнар. Дәү апабызның ире бакыйлыкка күчкән иде, балалары да булмады. Җитмәсә, тиф белән авырганнан соң, бераз гарипләнебрәк тә калган иде. Дәү апа шуңа да карамастан, өйдә бөтен эшләрне эшләде. Эни кайтканчы, кич белән миңа догалар да өйрәтә иде. Ул өйрәткән догалар эле дә хәтеремдә. Шулар белән һаман да яши киләм... Дәү апаны да эни тәрбияләп озатты.

Рәйхана апа белән сөйләшкәндә район газетасында энисе турында чыккан мәкаләләргә дә игътибар иттем. Әңгәмәнең буеннан-буена: «Кызым, менә шушы энкәмнән өзелеп калган кеше инде мин», – дип еш кабатлады Рәйхана апа.

КЫЗЫ ТУГАН ХӘБӘРНЕ АЛЫРГА ЯЗМАГАН

– Әти белән эни берничә тапкыр хат алышкан. Энкәй аңа бала көткәнен әйткән. Әти бик сөенгән, хатларында минем турында кат-кат сорап язган. Ләкин мин 1942 елның февралендә генә дөньяга килгәнмен. Әтигә туган хәбәремне алырга язмаган булган...

Сугыш беткән көнне Рәйхана апа хәтерләми. Күрәсең, бала күңеле белән әле ул аны аңлап җиткермәгән. Җитмәсә, көтеп алыр, кайтып керер кешеләре дә юк бит...

– Олылар сөйләгәннәр дә онытылган, – дип, кыска гына төгәлләде бу хакта сүзне.

«БӘХЕТЛЕ ЧАК ИДЕ...»

– Ярдәм кулы сузар кешегез дә әллә ни булмаган, нәрсә ашап үстегез? – дим.

– Ул чакта бар кешенең дә тормышы авыр булды. Күрше кызы белән бакчадан черек бәрәңге җыеп йөргәнне хәтерлим. Аны арыш онына кушып пешерәсең... Шуның белән тамак туйдырдык, кызым, ул чакта, әйтәм бит, ил белән шулай идек...

Үткәннәрне искә алганнан соң, берара тын тордык. Җелегенә үткән ачлык газабы йөзеннән сызылып үтте аның. Әмма тагын яктырып китте үзе:

– Балачак, дигәч, мәктәптә укыган еллар искә төшә. Тамаклар бик туймаса да, бәхетле чаклар иде. Егетләр гармунда уйный, кызлар бии, кич утырыш, аулак өйләр, урам буйлап җырлый-җырлый төшүләр...

Әле тагын кул эшенә дә бик оста, тырыш булган Рәйхана апа, шуларны да искә алып сөйләде.

– Буш вакытта сөлге чиктем, оекбашбияләйләр бәйләдем. Китап укырга ярата идем. Китапханәгә миннән дә ешрак йөрүче булмагандыр, – дип көлеп тә куйды.

Рәйхана апаның да яшьлек хыяллары булган. Әлбәттә, иң беренче – туйганчы ипи ашау, тамакны туйдыру. Ләкин төп хыялы укырга китү, дөньяга чыгу булган.

– Авылда җидене бетергәч, мәктәп директоры барыбызны җыеп алып: «Кайбычта укуыгызны дәвам итәргә уйлыйсызмы?», – дип сорады. Укуым яхшы булса да: «Фермага төшәм», – дип кырт кистем мин. Югыйсә урта белем алып, укуымны Уфа шәһәрендә дәвам итә алган булыр идем, дим. Әнинең үзен генә калдырасым килмәде. Үкенмим... Үзем шулай хәл иттем.

«ИРСЕЗ ТОРМЫШ ТОРМЫШ ТҮГЕЛ ИНДЕ УЛ...»

Рәйхана апа 38 ел сыер савучы булып хезмәт куя. 21 яшендә кияүгә чыга. Дәүләтша абый белән дистә елдан артык кына яшәргә өлгерәләр. Кызганыч, иренең гомере кыска була. 33 яшендә өч бала белән тол кала. «Әле ярый әнкәй бар иде, ярдәм итте. Тик ул да ике елдан бакыйлыкка күчте шул. Ирсез тормыш тормыш түгел инде ул, кызым», – ди, авыр сулап Рәйхана апа. Аның бу уфтануы гомере буена җыелган, сизелеп тора.

– Балаларым, Гөлфия, Илшат һәм Ильяс, шөкер, үз юлларын таптылар. Инде оныкларым да үсеп буйга җитте. Тик Илшатым гына – йөрәк ярам: 15 ел элек Яңа ел алдыннан гаиләсе белән юл һәлакәтенә очрады. Бик зур хәсрәт булды. Урыннары җәннәттә булсын, көн саен алар рухына дога кылам! Аларны искә төшермәгән көнем юк, фотосурәтләре генә калды.

Мин Рәйхана апаның, бәхетле еллар дигәнен искә төшереп, уйларын балачакка алып кайтам:

– Ә бала чакка кире әйләнеп кайтыр идегезме? – дим.

– Юк, балам, – ди Рәйхана апа, уфтанып. – Рәхәт күрмәдем, нужа гына чиктем... Хәер, мин генә түгел, сугыш чоры балаларының берсенә дә рәхәт булмады.

Рәйхана апа – акъәби, аның 4 оныгы һәм 4 оныкчыгы бар. Улы Ильяс, килене Резедә белән бер-берсенә терәк-таяныч булып яшиләр. Ул балалары, оныкларының игътибарын, ихтирамын тоеп, матур тормышта гомер итә. Намазларын калдырмый, уразаларын тота, һәр туган көн өчен шөкер итеп яши. Т

НИГӘ КАЗАНДА ЧЫРШЫЛАРНЫ ТЫЙГАННАР?

«Татарстан» журналы «Вестник Татарского областкома РКП (б)» дип аталган чакта яңа сулыш алып яшәп киткән илдә чыршыларга әле берни янамый. Большевиклар чыршыларны хуплый. Хупламыйча, Россия империясендә әлеге агачлар кешеләр арасындагы тигезсезлек символы була бит. Алар моны чыршы бәйрәменә керәсе килеп тә керә алмаган бала чагыннан яхшы хәтерли... Кыш бабай чыршы астына куя торган бүләкләр бары тик бай балаларына гына тәтегән чакларны берсе дә, әлбәттә, онытмый. Фәкыйрь балаларга бу хакта хыялланырга гына кала... Әмма революция тигезсезлек белән хокуксызлыкны үзгәртә.

ЛЕНИН – КЫШ БАБАЙ

Беренче пролетар чыршысын 1919 елда Сокольникидагы урман мәктәбендә оештыралар. Ул бәйрәмдә Ленин үзе, Кыш бабай роленә кереп, бүләкләр сатып алып, балалар белән чыршы тирәли әйлән-бәйлән әйләнә. Бу күренешне соңыннан совет рәссамнары белән язучылары барлык балалар китапларында мәңгеләштерә.

1920 елдан балалар оешмаларында чыршылар мәҗбүри уздырыла башлый. Аларны яшь совет иле матбугатында шулай ук мәҗбүри яктырталар да. «Вестник Татарского областкома РКП (б)» дә читтә калмый, билгеле:

«Р.К.П. (б) ның барлык канткомнарына!

Татар балалары өчен оештырылган барлык коммунистик пролетар чыршыларын актив һәм колачлы рәвештә пропагандалау таләп ителә! Барлык район һәм кантон комитетларына үз утырышларында бу мәсьәлә буенча бөтен яклап сөйләшү бурычы куела. Киң массалар арасында агитация уздыру һәм эшне иң югары дәрәҗәдә башкару кирәклеген җиткерү өчен барлык партия, совет һәм яшүсмерләрнең басма органнарын җәлеп итәргә кирәк!

Иптәшләр! Инициатива күрсәтүегез, Кызыл Татариядә яшәүче совет балаларына пролетар чыршысын оештыруда мөмкин булган барлык көчегезне һәм шартларны куллануыгыз сорала!» – ул вакытта журналны чыгару буенча җаваплы (баш) редактор һәм Татар төбәк комитеты РКП (б) ның тарихтагы беренче секретаре Александр Таняев Татария халкына басма битләреннән нәк шулай мөрәҗәгать итә.

ПАРТИЯ ЙОГЫНТЫСЫ ҺӘМ ДИНИ ХАТАЛАНУЛАР

Әмма дөнья пролетарийларының юлбашчысы вафат булгач, инде пролетарныкы саналса да, чыршы да тәнкыйть утына тотыла. Дингә каршы көрәш ачкан партия Яңа ел бәйрәмендә борынгыдан калган инанулар калдыгын күреп ала, нигездә, Раштуа белән бәйле булганга күрә. 1924 ел азагына әлеге искелек калдыгы булган йоланы матбугат-

та мыскыл итәргә керешәләр – карикатуралар бер газетадан икенчесенә күчеп йөри.

«Вестник Татарского обласккома РКП (б)» үзе дә инде ул арада «Коммунистический путь»ка әверелгән була, бу хакта тагын фикер белдермичә кала алмый, әлбәттә:

«Дингә партия йогынтысы турында.

Октябрь революциясенең башка кайбер казанышлары белән беррәттән, пролетариат дини пропаганда коткысына бирешмәү хокукын да яулады. «Раштуа көннәрендәге дингә каршы пропаганда материаллары»на сылтама ясап, болай дип цитата бирәбез: «Балаларның динилеге нәкъ менә чыршыдан башлана. Безнең өстән хакимлек иткән эксплуататор класслар «ягымлы» чыршы белән «яхшы» Кыш бабайны хезмәт кешеләрен капиталга баш иярге һәм түземле, умырткасыз хезмәтчегә әйләнергә өнди».

РӘСМИ РӘВЕШТӘ ТЫЮ

Баштарак партия органнары бастырып түгел, әмма дә ләкин бик җитди итеп Раштуаны уздырмаска һәм чыршыларны бу бәйрәм алдыннан бизәмәскә өндиләр.

1926 елда ВКП (б) ҮК Раштуа чыршылары кую йоласын советка каршы дип игълан итә, ә 1919 елда Раштуаны бәйрәм итү СССРда рәсми рәвештә тыела. Яңа ел һәм Раштуа бәйрәмнәрендә комсомол активистлары өй борынча йөреп, яшәү шартларын һәм кергән өйдә чыршының булу-булмавын тикшерә. «Чыршы шикаятьләре» чәчәк ата башлый: күршеләрнең тәрәзәсендә бизәлгән чыршы, ә чыршы булмаса, фикус булса да күргән кешеләрнең саны бермә-бер арта.

Чыршы һәм чыршыга каршы оештырылган вакыйгаларны Татариядә республиканың «Спутник партийного активиста» һәм әлеге журналга параллель рәвештә татарча чыга башлаган «Җитәкче» басма органы җентекләп күзәтә. Җаваплы редактор Мендель Хатаевич әле өстәвенә ВКП (б) Татар өлкә комитеты секретаре вазыйфасында да була. Бу, билгеле, аның турыдан-туры контроленә керә. Ул чакта бик катгый язалар һәм өндиләр: «Эшчеләр сыйныфы яңа тормыш елъязмасын 1917 елның октябреннән башлый, ә чын Яңа елын – иптәш Ленин пролетар дәүләтне җитәкли башлаган көннән».

«Спутник партийного активиста» битләрендә ВЛКСМ ҮК, Наркомпрос, Бөтенсоюз профессиональ союзлар үзәк советы (ВЦСПС) исеменнән инструкцияләр басыла. Мәсәлән, менә мондый:

Фото: Екатерина Ежова, vyatkawalks, diletant.media, rus-biography.ru

«Мәктәптә каникулларны ничек оештыру турында». Анда «каникуллар вакытында шәһәр һәм авыл балаларын җанлы итеп оештырылган мәдәни-массачыл һәм сәламәтләндерү чараларына җәлеп итәргә» диелгән. Әлбәттә, бу чаралар «артта калган халык белән безгә сыйнфый яктан чит элементларның дини йогынтысын кысрыклап чыгару» максатын күздә тота.

СИГЕЗ ЕЛГА СУЗЫЛГАН ТЫЮ

Шулай итеп, чыршы сигез ел буена тыелып килә. Һәм кинәт кенә 1935 елның декабрендә «Правда» газетасында Киев өлкә комитетының беренче секретаре Павел Постышевның язмасын бастыралар: «Әйдәгез, Яңа елга балалар өчен яхшы чыршы бәйрәме оештырабыз!»

Башта ул бу тәкъдим белән Сталинга килгән, диләр. Һәм Сталин рөхсәт биргән: «Раштуа чыршысы» түгел, ә «Яңа ел чыршысы» оештырырга.

Постышев чыршы бәйрәмен саклап кала-калуын, ләкин аның үзен 1939 елда чираттагы «халык дошманы» буларак атып үтерәләр. Ә «Правда» газетасындагы «яхшы чыршы бәйрәме» турындагы мәкаләне шунда ук бөтен газета-журналлар үзләрендә бастырып чыга. Шул исәптән, «Татарстан большевигы» да.

Давайте организуем к новому году детям хорошую елку!

В дореволюционное время буржуазия и чиновники буржуазии всегда устраивали на новый год своим детям елку. Дети рабочих с завистью через окно посматривали на сверкающую разноцветными огнями елку и веселящихся вокруг нее детей богатеев.

Почему у нас школы, детские дома, ясли, детские клубы, дворцы пионеров лишают этого прекрасного удовольствия ребятишек трудящихся Советской страны? Какие-то, не иначе как «левые», загибщики ославили это детское развлечение, как буржуазную затею.

Следует этому неправильному осуждению елки, которая является прекрасным развлечением для детей, положить конец. Комсомольцы, пионер-работники должны под новый год устроить коллективные елки для детей. В школах, детских домах, в дворцах пионеров, в детских клубах, в детских кино и театрах — везде должна быть детская елка! Не должно быть ни одного колхоза, где бы правление вместе с комсомольцами не устроило бы накануне нового года елку для своих ребятишек. Горсоветы, председатели районных исполкомов, сельсоветы, органы народного образования должны помочь устройству советской елки для детей нашей великой социалистической родины.

Организации детской новогодней елки наши ребятишки будут только благодарны.

Я уверен, что комсомольцы примут в этом деле самое активное участие и искоренят нелепое мнение, что детская елка является буржуазным предрассудком.

Итак, давайте организуем веселую встречу нового года для детей, устроим хорошую советскую елку во всех городах и колхозах!

П. ПОСТЫШЕВ.

МАСКА, МИН СИНЕ БЕЛӘМ!

Ә аннары, зур тиражлар белән чыккан язмадан соң, чыршы бизәргә һәм Яңа елга багышлап балалар бәйрәмнәре уздырырга дигән директиваны барлык мәктәпләр, балалар бакчалары, шугалаклар, балалар йортлары, пионер йортлары, кинотеатрлар һәм театрлар кабул итеп ала.

Беренче мәртәбә рөхсәт ителгән чыршы бәйрәмнәре без хәзер ияләшкәннәрдән, билгеле, бик нык аерыла. «Чыршы шикаятьләре» башланганга кадәрге бәйрәмнәрдән дә. Карнавалга балалар Кызыл Армия һәм хезмәт ударниклары, очучы-каһарманнар, Арктиканы яулаган геройлар костюмнарыннан килә. Шундый ук уенчыклар – йолдызлар, парашютлар, әләмнәр белән чыршыны да бизиләр. Яңа ел бәйрәм-тамашалары Совет илендәге сыйнфый көрәш темасын чагылдырырга тиеш була, башкача – ярамый. Истәлек өчен коллектив фото да – иптәш Сталин портреты фонында, бу – катгый канун. Чөнки, яшәү – шул чактан башлап, бездә күпкә яхшырак та, күңеллерәк тә!

БАРЛЫК ОБРАЗЛАР БУЙСЫНГАНДА...

Елена Вальцефер балалар өчен әкиятне Яңа елда вакытында гына тудырмый. Ул – «ДжуниорЛайф» кино сәнгате мәктәбе директоры, димәк, үсеп килүче буынны тәрбияләүдә иң эчкерсез ысул турында барысын да белә.

— Кино – ул гаҗәеп бер дөнья. Кино безне башка галәмнәргә юл салырга, геройлар өчен дулкынланырга, үзеннән соң матур хатирәләр калдырырлык һәм кәеф күтәрелерлек итеп көләргә, шатланырга яисә, киресенчә, тирән хисләр уятып, күз яшьләре түгәргә мәҗбүр итәргә сәләтле...

Кино, үзебезне аңларга булышып, эчке дөньябызны баетып, күңел дәвасына да әйләнә ала.

Шулай да әлеге дөнья аның үзенчәлекле жанры – балалар киносыннан башка беркайчан да тулы була алмас иде.

«ШКОДНИКИ» «ЕРАЛАШТАН» БАШЛАНДЫ

Менә инде 14 ел дәвамында мин, үземнең «ДжуниорЛайф» кино сәнгате мәктәбен җитәкләү белән бергә, «Шкодники» юмористика киножурналының продюсеры да булып торам.... Барысы да «Ералаш»тан башланды. Атаклы киностудия Казанда үз мәктәбен ачты. Мине директор итеп чакырдылар, гәрчә кино дөньясына кастинглар яки сценарийлар аша түгел, ә хисап счётлары һәм финанс отчётлары аша кагылсам да. Тик, кем әйтмешли, физикадан лирикага – бер адым. Ә минем очракта – кечкенә генә укытучы роле тормышымны «аңа кадәр» һәм «аннан соң»га бүлде. Төшерү мәйданчыгында әлеге рольгә кеше булмау сәбәпле, режиссёр аны миңа тәкъдим итте. Ә инде «Ералаш» Казаннан киткәч, мин балалар киносыннан китә алмадым.

МИССИЯНЕ ҮТӘП БУЛА!

Шулай килеп чыкты ки, балалар киносы минем миссиямә әверелде. Һәм ул тормышымны үзенчәлекле эчтәлек белән баета, үземне кирәкле, булдыклы итеп тоярга мөмкинлек бирә. Бу минем язмышым да, шәхси үсеш юлым да. Бөтен күңелемне биреп эшлим, вакытымны, көчемне кызганмыйм һәм шуннан ләззәт һәм канәгатьлек алам. Һәм инде бу эштән башка яши алмыйм. Чөнки балалар киносында барысы да – чып-чын, бары тик бер чеметем тылсым, могҗиза гына кушылган.

«Шкодники» балалар юмористика киножурналы – JuniorLife кино сәнгате мәктәбе проекты. Ул Канн (Франция) фестиваленең V һәм VI халыкара һәвәскәр һәм яшьләр киносы фестивальләрендә катнашты һәм призёр булды, күпсанлы республика конкурслары, балалар һәм яшүсмерләр иҗаты фестивальләре лауреаты исеменә ирешә. Мәгариф хезмәтләре базарында без инде 14 ел эшлибез, бүләкләр сандыгында – 100 дән артык диплом һәм премия!

«Шкодники» – позитив, җылы юмористик гаилә скетчкомы. Ул теләсә кайсы яшьтәге максатчан аудиториягә кызыклы, аның нигезендә көлкеле кыска сюжетлар ята. Без аларны Казан шәһәре мәктәпләрендә, музейларда, мәдәният һәм спорт комплексларында төшерәбез. Төп геройлар – шәһәр балалары, мәктәп укучылары. Безнең проект эксклюзив, чөнки Татарстанда балалар өчен кыска метражлы кино – ул яңалык. «ДжуниорЛайф» кино сәнгате мәктәбе әлеге аудиовизуаль әсәргә аерым хокукка ия.

НАПОЛЕОН ПЛАННАРЫ

Минем планнарым Наполеонныкына тиң диярлек – Татарстанда балалар өчен тулы метражлы уен киносын үстерү. Балалар киносы – ул балалар турында һәм алар хакында. Җиңел һәм самими – бала кебек үзебезнеке. Нәкъ менә без – өлкәннәр – аңа нәрсә салабыз, нинди мәгънә белән тутырабыз, шул безнең җәмгыятьнең киләчәген билгеләячәк, чөнки бүгенге балалар – ун-унбиш елдан соң ил язмышын хәл итәчәк кешеләр.

Балалар киносы – карарга, аңларга, анализларга өйрәтә торган уникаль ысул. Бу тәрбия бирүнең шактый нәтиҗәле ысулы, тик шул ук вакытта ул бик эчкерсез, самими дә.

ГАДИЛӘШТЕРЕЛГӘН ТӘРБИЯ ТӨРЕ

Кино карарга, күрергә, уйларга, аңларга, анализларга өйрәтә. Бу тәрбиянең гадиләштерелгән төре – тәэсирле, рухи. Минем төп бурычым – нәкъ менә балаларга аңлаешлы контент булдыру. Ул караганнан соң ук онытылмаска, ә уйларга, үзеңне герой урынына куеп карарга, мондый ситуациядә мин нишләр идем, дип уйланырга мәҗбүр итәргә тиеш.

Үз мәдәниятебезгә, тарихыбызга, идеологиябезгә нигезләнгән фильмнар тәрбия бирүдә, гади әхлак кагыйдәләрен үзләштерүдә күп кенә бурычларны җиңел хәл итәргә мөмкинлек бирә.

Фото: Екатерина Ежова, Анна Арахамия. РЕКЛАМА

Гастон кушаматлы ат.
Хуҗасы – Руслан Нуриев.

2025 ЕЛДА ЕЛЕНА ВАЛЬЦЕФЕР **«ЕЛ ХАТЫН-КЫЗЫ 2025» БИЗНЕС-ПРЕМИЯСЕНЕҢ «ИҢ ЯХШЫ ПРОДЮСЕР»** НОМИНАЦИЯСЕНДӘ ҖИҢҮЧЕ ДИП ТАБЫЛДЫ.



КАДЕРЛЕ УЕНЧЫКЛАР

Без югары тизлекләр, үзгәрешләр чорында яшибез. Дөньяның 10–20 елдан соң нинди булачагын күз алдына да китерә алмыйбыз. Хыял артыннан тагын да ераккарак омтылып, кайчак үткәннәрне онытып җибәрәбез, ә ул шундый ук кызыклы бит, бигрәк тә Яңа елга кагылган мизгелләре. Әйдәгез, өлкәннәр ашыга-ашыга киләчәкне якынайткан арада, «ДжуниорЛайф» кино сәнгате мәктәбенә йөрүче балаларны тыңлыйк. Алар үз гаиләләрендә саклана торган кызыклы Яңа ел уенчыклары турында сөйләргә әзер. Әлеге ялтыравык уенчыкларда бик күп елларның шатлыгы, сөенече, рухы чагыла кебек.

ВАЛЕРИЯ ДАНИЛОВА:
– Без гаиләдә өч кыз. Апам – Арина, сеңлем – Ева, ә мин, Валерия, – уртанчы кыз. Һәрберебезнең үз Яңа ел уенчыгы бар. Кызлары туган саен, эти белән әни курчак бүләк иткән, алар безне сакласын дип, – шундый традиция. Һәм чыршы бизәгәндә без, әлбәттә, үз курчакларыбызны шунда элеп куябыз. **Кулымдагы курчагымның исеме Мери** – әнием хөрмәтенә шулай дип атадым.

ВИКТОРИЯ СУНЦОВА:
– Бу бик матур **колибри кошы** әбиемнеке. Уенчык узган гасырда ук ясалган, дип сөйләде әбием. Аңа бу уенчык әнисеннән калган. Әбиемнең әнисе кечкенә чагында ук бу колибри гаилә чыршысын бизәгән. Ә кызы, ягъни минем әбием, кияүгә чыккач, ул уенчыкны аңа бүләк иткән. Без өйдә чыршы бизәгәндә, һичшиксез, бу колибрины иң күренеп торган урынга элеп куябыз.

ЕЛИЗАВЕТА ЗАЙЦЕВА:
– Гаиләбез белән театр һәм балет яратабыз. Әбием балет белән шөгыльләнгән, әни һәм мин – бию белән. Шуңа күрә **уенчык балерина** безне берләштерә. Бу уенчыкны әбиемә укучылары бүләк иткән. Без аны Яңа ел алдыннан күренеп торган урынга элебез һәм аңа карап сокланабыз. Ул безгә матурлыкның янәшәбездә булуын искәртеп тора. Әлбәттә, мин бу уенчыкны балаларыма, бәлки, оныкларыма тапшырырмын, дип уйлыйм – алар да балеринага карап соклансыннар.

Фото: Анна Арахамия

ВАЛЕРИЯ МИРОНОВА:
– Миндә бу уенчык чагыштырмача күптән түгел генә пәйда булды. Берничә ел элек без сыйныфыбыз белән Түбән Новгород шәһәренә бардык, анда чыршы уенчыклары фабрикасына алып керделәр. Мастер-класста мин **пыяла шарга** рәсем төшердем. Димәк, үзенә күрә бердәнбер, башка кабатланмый торган уенчыклы булдым. Киләчәктә бу уенчыкны саклармын һәм, ихтимал, гаиләм белән бергә яңаларын ясармын.

ОЛИВИЯ МИРОНОВА:
– Бу кечкенә **пыяла фәрештә** әбиемнеке, әле сугыш чагыннан ук калган. Аның өчен бу өмет һәм яклау символы булган. Ә безнең гаиләдә бу фәрештә гаилә бердәмлеген һәм бәйрәм җылысын чагылдыра. Ел саен без аны чыршыга элеп куябыз. Бу бизәк кенә түгел, ә тарихыбызның бер өлеше. Уенчык кулдан эшләнгән, шуңа ул бигрәк тә кадерле. Үскәч, бу фәрештәне балаларым белән бергә чыршыга элеп куячакмын.

ЗЛАТА ҺӘМ МИХАИЛ (ӘТИСЕ) ОГНЕВЛАР:
– **Кыш бабай белән Кар кызы** безнең чыршыны инде күп еллар бизәп тора. Алар әбиебез кулы белән ясалган. Кыш бабай белән Кар кызы металл каркаска беркетелгән, шуңа күрә алар аскуймада яхшы басып тора, мәчебез дә аларга тими. Уенчыкларның битйөзләре полимер балчыктан эшләнгән.
Златаның үз гаиләсе булгач, ул балаларына әлеге Яңа ел уенчыкларының каян килгәне турында сөйләр, дип өметләнәбез.

ӘМИНӘ ХӘЛИЛОВА:
– Бездә чыршы уенчыклары күп һәм мин аларның барысын да яратам. Узган ел без әни белән чүлмәкче остаханәсенә мастер-класска барган идек, һәм хәзер бездә үзебез ясаган уенчыклар да бар. Ә тагын без кәгазьгә теләкләр язабыз һәм чыршы уенчыкларына беркетәбез. Аларны уку һәм былтыргылары белән чагыштыру бик күңелле.

АЛИСА КОНДРАТЬЕВА
– Мин – эти-әниемнең озак көтеп алынган баласы. Яңа ел төнендә алар, теләк теләп, чыршыга уенчык фәрештә элеп куйганнар. Һәм нәкъ менә бер ел узганнан соң, гыйнвар аенда, дөньяга мин аваз салганмын. Менә шундый могҗиза. Шуңа күрә бу уенчык – шатлык, могҗизага ышану символы. Чөнки җир йөзендә иң кадерле нәрсә – тормыш, ә аның мәгънәсе – якыннарыбыз һәм туганнарыбызны яратуда.

АМЕЛИЯ НӘҖИПОВА:
– Яңа елны һәм Гарри Поттер турындагы фильм һәм китапларны бик яратам. Хогвартс геройлары белән мин бик кечкенә чагымнан ук таныш. Әлеге сериягә кергән беренче китапларны миңа апам укыган иде. Шуңа күрә быел мин өйдәге чыршыны оча торган себеркеләр, Хогвартстан килгән хатлар, 9 нчы һәм 3/4 нче платформаларга билетлар һәм ак ябалаклар белән бизәргә телим. Ә чыршының очына, әлбәттә, тылсымлы эшләпә кидертәчәкмен!

КИРИЛЛ АФАНАСЬЕВ:
– Бу **шарны** әбием кечкенә чакта ук сатып алганнар. Ул эти-әнисе белән чыршы базарына барган һәм шунда уенчыкны күреп алган – шар аңа тылсымлы тоелган. Без шарны чыршыга элеп куйганда, әбием: «Бу шар, югалмыйча, чыршыга эленгәндә, өйдә бәхет һәм Яңа ел могҗизасы булачак», – дияргә ярата. Уенчык үзе кичергән барлык Яңа ел бәйрәмнәре рухын саклый кебек.

ВАСЕЛИНА ГАВРИЛОВА:
– Мин бу **ике уенчыкны** бик яратам, чөнки эчендә аю булганында кечкенә тишек бар, ә йөрәклесендә – ялтыравыклар, аларны алырга була. Бу уенчыклар миңа шатлык, соклану бүләк итә. Аю баласы бик сөйкемле, ә йөрәк ниндидер тылсым өсти. Алар, бәйрәм рухы тудырып, тирә-юньне үзенчәлекле ямьгә күмә.

ЭЛИНА ХАМИТОВА:

– Без ел саен чыршы уенчыклары саклана торган тартманы ачканда дулкынланабыз. Минем өчен иң кадерлесе – **иске Кыш бабай сыны**. Ул бит миңа яраткан әбиемнән калган. Кечкенә чагымда бу уенчыкны кулыма алганда, теләк теләп, аны чыршыга элеп куя идем. Ел саен мин теләгәннәрнең барысы да үтәлә иде. Ул чакта мин бу уенчыкны чыннан да тылсымлы, дип уйлый идем...

САФИНА ХӘСӘНОВА:

– Безнең гаиләдә төрле сәяхәтләрдән чыршы уенчыклары алып кайту традициясе бар. Соңыннан алар безнең Яңа ел чыршысында үз урыннарын таба. Һәм, әлбәттә, без әбиләремдә сакланган, кечкенә чакларында әти-әнием үз чыршыларын бизәгән уенчыклар турында да онытмыйбыз.

ГАБРИЭЛЛА СӘЛАХЕТДИНОВА:

– Мин тугач, әти-әнием үз традицияләрен булдырырга уйлаган – һәр Яңа ел саен алар миңа яңа чыршы уенчыгы бүләк итәләр. Беренчесе яктырткычлы фәрештә иде, аннары – чанага утырган сөйкемле песи баласы, пыяла ат... Бу уенчыклар – балачагымның кадерле мизгелләре. Аларны мин саклыйм һәм алга таба дәвамчыларыма тапшырырмын, дип уйлыйм. Быел мин киләсе ел символы – **ат ясалган шарны** сайладым.

УЛЬЯНА ОСИПЕНКО:

– Бу **Кыш бабайны** әбиемнең әтисе 1968 елда – кызына нибары сигез яшь булганда сатып алган. Әби үз гаиләсен коргач та, ул чыршы астында дәрәҗәле урында торган. Әтием сөйләгәнчә, бала чакларында алар абыйсы белән теләкләр язылган хатларны Кыш бабай янында калдыра торган булганнар. Ә иртән чыршы астында бүләкләр тапканнар. 57 ел узгач та, Кыш бабай элеккечә әби белән бабай йортындагы чыршы астында тора. Әби аны миңа бүләк итәм диде...

КИЛӘЧӘККӘ ЮНӘЛГӘН ПРОФИЛЬ

КАЗАН ЛИЦЕЕ ПЕДАГОГЛАРЫ БАЛАЛАРНЫ ЛИДЕРЛЫККА, ЯСАЛМА ФӘҺЕМГӘ ҺӘМ АРКТИКАДАГЫ ПРОЕКТЛАРГА НИЧЕК ӘЗЕРЛИ

Олеся Бондаревская

Бүген техник белем бирү – илнең технологик суверенитетының төп инструментларыннан берсе. «Технарь»ларга ихтыяҗ хезмәт базарында теләсә нинди башка белгечлеккә караганда тизрәк үсә. 2025 елда югары уку йортларындагы бюджет урыннарының яртысын диярлек дәүләт инженерлык юнәлешләренә бүлеп бирде. 2026–2027 елларда квота артачак. Казан Лицей – инженерлык үзәге әлеге трендларны алдан күрә белде һәм аларны инде 10 ел директор Венера Хәйретдинова җитәкчелегендә актив рәвештә тормышка ашыра.

Лицей – белем бирү сыйфаты буенча Рособрнадзор рейтингының «Белем бирүдә югары нәтиҗәләр» номинациясендә төбәк лидерларыннан берсе, һәм бу факт инженерлык юнәлешен үстерү карарының бик вакытлы кабул ителүен, перспективалы булуын раслый.

Лицейда укыту «лингво + техно» концепциясенә һәм инженерлык белеме бирүнең өзлексезлеге принцибына корыла – балалар бакчасыннан алып урта мәктәпкә кадәр, шулай ук көннең беренче яртысында Федераль дәүләт белем бирү стандартларында (ФГОС) каралган дәресләрдән алып икенче яртысында махсус техник дисциплиналарга кадәр. Үсеш векторларын лицейның үз стратегиясе билгели: ул өч ел саен республиканың әйдәп баручы икътисадый һәм технологик югары уку йортларыннан килгән фәнни җитәкчеләр катнашында яңартыла. Әлеге стратегия – «нишләргә?» дигән төп сорауга, ә лицей командасы «ничек эшләргә?» дигәнгә җавап бирә. Белем бирү процессына карашларның бердәмлеге, һәр педагог һәм хезмәткәрнең югары квалификациясе лицейга, төбәктә күптән эталон дип саналган белем бирү дәрәҗәсен саклап калып, алга барырга ярдәм итә.

Фото: Лицей – Инженерлык үзәге архивыннан. РЕКЛАМА

КЛИПЛЫ ФИКЕРЛӘМӘСКӘ ӨЙРӘТҮ

«Һөнәри белем бирү системасын хезмәт базары таләпләренә акрынлап җайлаштыру» – РФ Мәгариф министрлыгының Мәгарифне үстерүнең яңа стратегиясе проектында тармак проблемаларының берсе шулай формалаштырылган. Инженерлык лицееның стратегиясе әлеге ихтыяҗны исәпкә ала: 2024–2027 елларга төп уку юнәлешләре итеп әйберләр интернеты, мәгълүмат иминлеге, экология һәм сәламәтлек саклау, ясалма фәһем һәм социаль фәннәр билгеләнгән. Әмма өстәмә фәннәрне өйрәтү өчен, мәктәп программасындагы төп предметларны яхшы укыту кирәк.

– Балаларның кызыксынуын саклап калу һәм «клиплы» фикер йөртүне гадәткә керттермәс өчен, традицион алымнарны заманча методлар белән яраштырам, дәресләргә төрле стандарт булмаган һәм кызыклы биремнәр кертәм. Бу үҗәтлек таләп итә, әмма балалар тема буенча китерелгән мисалларга охшамаган катлаулы бурычны үтәгән саен, мин тырышлыкның юкка түгеллеген күрәм. Лицейда эшләү педагогик тәҗрибәмне баета. Тәнкыйди фикерләвемне үстерүгә, бурычларны гадәти булмаганча хәл итүгә һәм проектлар төзү эшчәнлегенә күбрәк игътибар бирәм, – ди **беренче категорияле математика укытучысы Мария Дементьева.**

ЧАТТАГЫ ДИАЛОГТАН – КИТАП БЕЛӘН ДИАЛОГКА

– Балалар иҗади эшләрен язу өчен ясалма фәһемнән файдалана, һәм бу зур проблема. Иҗат күнекмәләрен һәм фикерләүне үстерү тоткарлана, мондый эшләр буенча белемнәрне объектив бәяләү авыр. Моннан тыш, зур текстларны аңлап укуда кыенлыклар да бар. Күпләр смартфон тасмасы скроллингыннан яки берничә секундлы тик ток видеолар караудан җиңел «дофамин» алырга күнеккән, һәм аларга басылып эшләү катлаулы бирелә, – ди **беренче категорияле рус теле укытучысы Сергей Мурзаев.** – Шунлыктан дәрестә мин текстны өлешләп бирәм. Иң кызыклы, сораулар тудыра торган өзекләрне, аерым бүлекләрне укыйбыз. Кайвакыт, укыганнан соң, балаларга комикс ясарга, геройлар исеменнән мессенджер стилендә диалог төзергә яки кыска ТикТок видео төшерергә тәкъдим итәм. Балалар күнеккән форматның китап эчтәлеге белән шундый синтезы барлыкка килә.

Инде берничә ел буе Сергей Николаевич укучылар һәм педагогларның «Миниатюра» мәктәп театрын җитәкли. Сәхнә – әдәбиятны аңлауның иң яхшы ысулы, дип саный ул. Текст белән мондый җитди эшкә гадәти дәрестә ирешеп булмый. Аның коллегасы, **югары категорияле рус теле һәм әдәбияты укытучысы Светлана Девятых,** балалар еш кына тиз форматлар сайласа да, дөрес шартлар тудырганда, аларның текстны тирән тоярга сәләтле булуы белән килешә:

– Рус теле бай, матур һәм гаҗәеп зирәк. Ул һәрвакыт кешегә юл таба – шул исәптән бүгенге заман укучысына да. Ләкин бу юл үзгәреп тора. Кайвакыт укучыга тәэсир итү өчен ниндидер уңышлы образ, төгәл билгеләмә дә җитә, – ди Светлана Николаевна. – Кеше һәм тел – бербөтен. Аннан башка без дөньяны аңлый да, анда яши дә алмыйбыз. Балаларның бу бәйләнешне тоюы мөһим. Рус теле – мәгънәләр хәзинәсенә ачкыч. Мин әдәбият, бигрәк тә классик һәм көмеш гасыр әсәрләре аша, балалар бу матурлыкны ачсын, күрсен, тойсын дип тырышам.

Лицейда китап белән аралашу дәресләр белән генә чикләнми: уку күнекмәләре китапханәдә дә формалаша.

– Миңа һәрвакыт үземә яңа китапны уку һәм аның кемгә туры киләчәген аңлау мөһим, – ди **лицейның китапханә мөдире Елена Лебедева.** – Беренче сыйныфларны китапханә укучысы итеп теркәгәндә, ниндирәк икәннәрен чамалыйм да, Носов, Драгунский, Бианкины киңәш итәм. Башлангыч мәктәпне тәмамлаганда, һәр баланың үз зәвыгы тәрбияләнә. Сайлау мөмкинлеге булсын өчен, китап фондын даими тулыландырып торабыз. Бу җиңел түгел, әмма 13 ел инде без «Китапка икенче тормыш бүләк ит» акциясен үткәрәбез, һәм ата-аналар тапшырган китаплар хисабына яңа әдәбият пәйда була тора.

Лицейда Елена Александровнаның үз проекты

бар – «Әдәби кунак бүлмәсе». Биредә лицей укучылары танылган авторларның бигүк билгеле булмаган әсәрләрен укый һәм анализлый, геройлар турында фикер алыша, яңа һәм аңлаешсыз сүзләрне өйрәнә, ә ахырдан сюжет буенча рәсемнәр ясыйлар. Шулай итеп, китап балалар өчен шәхси диалог һәм уйлану пространствосына әйләнә.

АРКТИКАГА ЮЛ БИРЕДӘ БАШЛАНА

«Укытуда табигать фән профилен аз сайлау» – РФ Мәгариф министрлыгы заманга хас тагын бер мәгариф проблемасын шулай формалаштыра. Лицей моңа җавап йөзеннән предметлар һәм балалар мәнфәгатьләре арасындагы уртак нокталарны эзли. Проект эшләре дә шуңа багышланган. Мәсәлән, аларга якын экологик тема буенча. Ел саен лицей укучылары Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының төбәк һәм йомгаклау этапларында бу фән буенча призлы урыннар яулый.

– Экология фәненең нигезендә биология ята. Минем өчен андагы һәр тема мөһим, чөнки ул безне дөньяны аңлауга якынайта. Мәсәлән, фотосинтезны өйрәнгәндә, без тормыш нигезләрен өйрәнәбез, – ди **югары категорияле биология укытучысы Нурсинә Мельникова.** – Мин үз фәнемне бик яратам, һәм лицейда укыту мине илһамландыра. Биредә укытучыга дәресләрне кызыклы итү өчен кирәкле бөтен нәрсә дә бар – заманча җиһазлар, компьютер симуляцияләренә һәм виртуаль лабораторияләргә кушылу мөмкинлеге, балаларны проектлар төзү эшенә җәлеп итү, фәнни конференцияләр оештыру, үзеңә дә яңалыкны өйрәнү мөмкинлеге. Һәм, әлбәттә, фикердәш коллегалар, алар белән яңа идеяләр турында сөйләшергә, аларны проектлар аша гамәлгә ашырырга мөмкин.

Материалны үзләштерүдә әлеге ысулларны куллану башка предметлар өчен дә мөһим. Мәсәлән, география, аны өйрәнүдә күзәтү, чагыштыру һәм тирә-яктагы мохитне аңлый белү күнекмәләре ярдәм итә.

– География инде күптән илләр, аларның башкалаларын тасвирлауга гына кайтып калмый. Ул табигатьне белән җәмгыятьне бәйли торган фән, планетада барган процессларны аңларга һәм хәтта киләчәкне модельләштерергә ярдәм итә, – ди **югары категорияле география укытучысы Резеда Кондратенко.** – Ул дөньяның фәнни картинасын, гражданлык позициясен, туган якка мәхәббәтне формалаштыра. География укучыларга һөнәр сайларга ярдәм итә. Бүген шулкадәр кызыклы, перспективалы проектлар бар: Арктиканы, Төньяк диңгез юлын үзләштерү. Шуңа күрә мин үз фәнем белән кызыксындыру өчен бөтен көчемә тырышам: заманча платформалар, карталар, видеолар, презентацияләрдән файдаланам. Үзем дә географияне, шул фәннән кергән укытучымны яратып укыдым. Аның үрнәгендә әлеге һөнәрне сайладым да һәм моңа бер тапкыр да үкенмәдем.

МОЛЕКУЛЯР ДӘРӘҖӘДӘ КЫЗЫКСЫНУ

Дөньяга тикшеренүчеләр карашы белән карау химия дәресләрендә дә хуплана. Анда балалар табигать төзелешен тагын да тулырак дәрәҗәдә күрергә өйрәнә. Химия кабинеты – ачышлар өчен чын мәйдан, өстәвенә, дәресләрне әлеге фән шәхси биографияләренең бер өлеше булган педагоглар алып бара. **Беренче категорияле химия укытучысы Вера Кашапованы** кайчандыр дөньяның атом һәм молекулалар дәрәҗәсендәге төзелеше кызыксындырган. Бүген ул бу белемен укучылар белән уртаклаша.

– Күптән түгел Казандагы Арбузов исемендәге институтта очраклы рәвештә үземнең элеккеге укучымны очраттым. Ул фән юлыннан киткән. Икебез дә очрашуга бик шатландык. Мөгаен, минем өчен һөнәремдә иң мөһиме – укучыларымда үземнең дәвамны күрүдер, – ди Вера Николаевна. Аның педагогик осталыгы – катлаулы әйберләрне гади сүзләр белән аңлата белүендә. Дәресләрдә Вера Николаевна стехиометрия һәм органик химия кебек катлаулы темаларны мөмкин кадәр җиңелрәк итеп аңлатырга тырыша. Косметика һәм парфюмериядән алып полимерларга һәм медицина препаратларына кадәр – тормыштан мисаллар китереп, укытучы предметны кабул итүне гадиләштерә, химияне аңлаешлы фәнгә әверелдерә.

Мөршидә Гомәрова белгечлеге буенча – метеоролог. Фәнгә һәм педагогик эшчәнлеккә мәхәббәт аны лицейга алып килә, һәм менә күп еллар инде ул биредә лаборант булып эшли:

– Мәктәптә шулай озакка калырмын дип уйламаган идем. Ләкин монда бик яхшы.

Миңа балалар белән эшләү ошый, коллектив искиткеч. Лаборатория лицейның бурычлары белән бергә үзгәрә: яңа реактивлар, җиһазлар, микроскоплар пәйда булды. Минем тәҗрибәмнең монда бик кирәк булуы да сөендерә, – ди Мөршидә Кәрим кызы.

ТАРИХНЫ ТОЮ, ГЛОБАЛЬ МАСШТАБТА ФИКЕР ЙӨРТҮ

Зур күләмле мәгълүмат гасырында материал белән эшли белү, фактларны чагыштыру һәм җитлеккән тәнкыйди фикерләүгә ия булу аеруча мөһим. Нәкъ менә тарих мондый күнекмәләрне табигый рәвештә формалаштыра торган предметка әйләнә.

– Дәресләрдә тәнкыйди фикерләүне үстерү алымнарын кулланам: игълан ителмәгән тема, бергәләп тикшерү, «идеяләр кәрзине». Укучыларга зур күләмле материалның аңлаешлы схемага сыеша торган итеп, кластерларга туплап бирелүе аеруча ошый. Кайчак фикер алышу барышында планда булмаган ысул туа. Иң мөһиме, ул балаларга материал белән эшләргә ярдәм итсен, – **ди югары категорияле тарих укытучысы Наталья Якупова.** – Тарих – минем язмышым ул, уйларга сәләтле кеше формалаштырырга ярдәм итә торган фән. Пушкин: «Үткәнгә хөрмәт – укымышлылыкны наданлыктан аера торган төп сыйфат», – дигән. Бу сүзләр – минем өчен төп ориентир.

Лицейның гуманитар блогында балаларга бүгенге тиз үзгәрә торган дөньяда ышанычлы юл табарга ярдәм итә торган тагын бер фән бар – инглиз теле. «Лингво + техно» техника һәм тел күнекмәләрен параллель үстерү концепциясе кысаларында инглиз теле дәрес яки инструмент кына түгел, ул укучыларның профильле компетенцияләре формалаша торган эш мохитенә әйләнә.

– Инглиз телен 25 елдан артык укытам һәм һөнәр буларак аны сайлавыма бер тапкыр да үкенмәдем. Минем өчен бу гадәти тормышның бер өлеше: зирәк, кутъяклы, элеккечә

үк фән, халыкара коммуникация һәм технологияләрдә әйдәп бара торган тел. Лицейда сигез ел укыту дәверендә мин, белем бирү белән шөгыльләнәсең килә икән, нәкъ менә шушында эшләргә кирәклеген аңладым, – ди **югары категорияле инглиз теле укытучысы Валерия Салманова.** – Лицей укучылары югары максатлар куя, олимпиадаларга, конференцияләргә, көчле югары уку йортларына керергә әзерләнә. Шуңа күрә минем педагогик максатым – укучыларда нәкъ менә инглиз телендә фикер йөртү теләген тудыру һәм бу күнекмәне саклау. «Русча уйлап таптым – тәрҗемә иттем – әйттем» моделеннән китү, идеяләрне инглиз телендә формалаштырырга өйрәтү, ягъни лицей белән киләчәктә укучыларыбыз лидер булырга тиешле дөнья арасында үзенчәлекле күпер булдыру.

БИРЕДӘ ҺӘРКЕМ – MVP* (ИҢ КИРӘКЛЕ УЕНЧЫ)

Лидерлык нигезен ниндидер йогынты, мотивация, максатны ачык күрү һәм нәтиҗәле аралашу формалаштыра. Бу сыйфатларны үстерергә спорт ярдәм итә. Әмма спортның кыйммәтен балаларга ничек тапшырырга? Артык каты таләпләр куймыйча, биздермичә, ничек өйрәтергә?

– Минем үземнең спорттагы мотивациям – баскетбол. Беренче тапкыр тренировкага 6 яшьтә килдем һәм бүгенге көнгә кадәр актив шөгыльләнәм, Казан федераль университеты җыелма командасының гамәлдәге уенчысы булып торам. Уенда үз гамәлләреңне берничә адымга алгарак уйларга, бөтен мәйданчыкны күз уңында тотарга, теләсә нинди очракка тактика булдырырга һәм тиз җавап та бирергә кирәк. Әмма иң мөһиме – һәр уенчының динамикасы һәм үсеше бөтен командага тәэсир итә, – ди **физкультура укытучысы Никита Николаев.** Баскетбол принципларын ул укыту процессында да модель буларак файдалана. – Минем педагогик алымым – даими прогресс белән максатка бергәләп якынлашу. Без командага әйләнәбез: уртак бурыч куябыз, авырлыкларны җиңеп, аны бергәләп гамәлгә ашырабыз һәм бергә ирешкән нә-

*Most Valuable Player – иң мөһим уенчы

тиҗәбез – җиңүне бәйрәм итәбез. Балалар белән аралашу, аларның хис-кичерешләре, елмаюлары, шатлыклары һәм ышанычлы мөнәсәбәте миңа көч бирә

ПОСТ-КОД ЧОРЫ УКЫТУЧЫСЫ

Спортта формалашкан җиңүче психологиясе югары технологияләр өлкәсенә җиңел күчә. **Информатика укытучысы һәм өстәмә белем бирү педагогы Никита Ильин** компетенцияләр кыю нәтиҗәләргә китерә торган мохит тудыра. Лицейда ул дрон пилотлары командасын өйрәтә, алар даими рәвештә үзебездәге һәм чит илләрдәге зур ярышларда призлы урыннар яулый – Идел буе федераль округы чемпионатыннан алып робот техникасы, пилотсыз авиация системалары, программалаштыру һәм ясалма фәһем буенча Кытай Россия халыкара ярышларына кадәр. Ноябрь аенда Циндао шәһәрендә (Кытай) узган әлеге ярышта Никита Ильин шәкерте – 8 «В» сыйныфы укучысы Даниил Федотов «Дроннар узышында һава остасы» номинациясендә икенче урын яулаган.

Никита Ильин технофәннәрне системалы рәвештә өйрәтә. Көннең беренче яртысында ул информатика дәресләре алып бара, икенче яртысында – БПЛА дәресләре. Аның белем бирү ысулы балаларга программалаштырудан алып әйберләр интернетына кадәрге төрле актуаль ИТ-юнәлешләрне сайларга, алга таба үсәргә мөмкинлек бирә. Яисә мәгълүмат технологияләрен табигать-фән өлкәләрендә эшләү өчен ярдәмче корал буларак үзләштерергә булыша.

– Программалаштыру үзмаксат түгел. Аның ярдәмендә тудырыла торган продукт мөһим, мәсәлән, шул ук пилотсыз система, – ди Никита Александрович. – Хәзер, ЯФ чорында, мин шулай ук укучыларымның программалаштыруда үзләренең мөстәкыйль үсеше өчен инструмент, ресурс күрүләрен телим. Уйламыйча күчерү генә бернәрсә дә бирми, әлбәттә. Нейрочелтәрне үз проектының бер чылбыры буларак файдалану, аның ярдәмендә үз мәнфәгатьләрең өлкәсендәге белем яки күнекмәләрне киңәйтү – балаларны менә шуларга өйрәтергә тырышам.

ИНЖЕНЕР + ЛИНГВИСТ = УҢЫШ

Инженерлык лицеенда директоры урынбасары Руфина Дәүләтбаева җитәкчелегендә Өстәмә белем бирү үзәге эшли. Үзәк уку траекториясенең тулыканлы һәм дәвам ителә торган өлешен формалаштыра. Көннең икенче яртысындагы 5 нче сыйныфтан 11 нче сыйныфка кадәрге предметлар вертикалендә һәр этап икенче этап өчен нигез сала. Укучылар программалаштыру һәм 3D модельләштерү аша физика һәм электроника нигезләреннән төрле өлкәләрдәге катлаулы интегратив проектларга – экологиядән мәгълүмат технологияләренә кадәр юл уза. ФГОС буенча каралган дәрес белемнәрен гамәли куллану бирелә реаль инженерлык компетенцияләрен формалаштыру белән берләштерелгән. Һәм алай гына да түгел.

– Һәр баланың көчле һәм йомшак яклары бар. Берсенә халык алдында чыгыш ясау авыр, икенчесенә ярдәмне тою мөһим, ә кемдер кырысрак таләпләргә мохтаҗ. Тупланган тәҗрибәм һәр баланың индивидуаль үзенчәлекләрен аңларга, аралашуны «кырыс» һәм «йомшак» күнекмәләрне бертигез дәрәҗәдә уңышлы үстерергә булышырлык итеп оештырырга ярдәм итә, – ди **өстәмә белем бирү бүлеге мөдире Лилия Садыйкова.** – Ә ел саен яңартыла торган «Профильле вакыйгалар навигаторы» лицей укучыларына техник юнәлештәге абруйлы конкурс һәм конференцияләрне сайларга, анда катнашырга ярдәм итә. Укучылар, өстәмә белем бирү кысаларында башкарылган проектлары белән катнашып, Бөтенроссия ясалма фәһем олимпиадасы, «Спутник» Бөтенроссия яшь инженер тикшеренүчеләр конкурсы, «Большие вызовы» Бөтенроссия фәнни технологик проектлар конкурсы кебек бәйгеләрендә даими призерлары һәм җиңүчеләре булды. Мондый уңышлар югары белем профилен сайлау һәм бу юнәлештә уңышка ирешү өчен нигез тудыра да инде.

– Без куәтле технологик профиль шундый ук көчле лингвистик әзерлек белән кулга-кул тотынышып барган белем бирү мохитен тудырабыз. Төп телләр – инглиз һәм немец телләре, күптән түгел корея һәм кытай телләре өстәлде. Заманча инженер өчен лингвистик компетенцияләр – дөньякүләм документация, тикшеренүләр белән эшләү, коллегалар белән хезмәттәшлек итү коралы. Көннең икенче яртысындагы программаларны эшләгәндә, без трендларга, алдынгы югары уку йортларындагы фәнни җитәкчеләребез тәҗрибәсенә таянабыз һәм иң заманча дисциплиналарны кертәбез. Моннан тыш, без әтиәниләр белән гел киңәшеп торабыз һәм безнең күзаллаулар туры килә, –

Лицей командасы робот техникасы, БПЛА, программалаштыру һәм ясалма фәһем буенча ярышларда (Циндао, Кытай), 2025 ел.

ICL хисаплау техникасы заводына экскурсия.

ди **гамәли лингвистика секторы мөдире Ләйсән Нигъмәтуллина.** – Лицей гаҗәеп күркәм һәм бай тормыш белән яши, профильле белем бирү чаралары һәм фестивальләр оештыра, еш кына башка мәктәпләрдән делегацияләр кабул итә һәм рәхәтләнеп тәҗрибә уртаклаша.



КАЙГЫРТУЧАНЛЫК ОСТАЛАРЫ

Лицейның тыгыз эш көннәрен оештыруда «бэк-офис»ның да өлеше зур. Иминлек хезмәте, ашханә хезмәткәрләре, машина йөртүчеләр, медблок, клининг хезмәте – бу белгечләр ышанычлы тыл булдыра, педагогларга игътибарны тулысынча укытуга юнәлтергә, ә балаларга үзләрен яклауларын һәм кайгыртуларын тоярга мөмкинлек бирә. **Лицей тормышының төп «координаторы» Оксана Сергеева** – документлар рәсмиләштерүдән алып, администрация очрашулары расписаниесенә кадәр-көн саен бик күп эшләр белән идарә итә. Бусагадан атлап кергәч, һәркемнең шунда ук үзен «өйдәге кебек» хис итә башлавы – аның зур казанышы.

– Безнең лицей – барыннан да элек, искиткеч коллектив һәм теләсә кайсы балага аерым якын килә белү ул. Биредә һәр хезмәткәрнең һөнәри үсеше өчен барысы да эшләнә: мастер класслар һәм башка шәһәрләрдә педагогик стажировкалардан алып, татар һәм рус телләрендәге педагогик театр кебек гадәти булмаган форматларга кадәр, – ди Оксана Вадимовна. – Шәхсән минем өчен төп бүләк – үземә йөкләнгән бурычны үтәү хисе: ул бөтен эш сыйфатлы башкарылган һәм бездә бөтен җирдә дә тулы тәртип булган чакта туа.

Укучылар һәм педагоглар сәфәрләренең ышанычлылыгын һәм иминлеген профессиональ машина йөртүчеләр тәэмин итә. **Илһам Зарифуллин** лицей коллективында беренче көннәрдән үк эшли.

– Без эшне бу бинаны ремонтлаудан башлаган идек.

Хәзер дә мин монда рәхәтләнеп эшлим. Машина йөртергә яратам (лицей проектлары буенча Татарстан районнарына еш йөрибез), техниканы яратам. Безнең коллектив зур түгел, бик дус, без инде бер тату гаилә кебек, бер-беребезне барыбыз да яхшы беләбез. Бергә ял итәбез, сәяхәт итәбез. Лицейны бүтән оешмага беркайчан да алыштырмас идем, – ди Илһам Илмас улы.

Рөстәм Шәйхлисламов 35 елдан артык рульдә, соңгы алты елын лицейда эшли.

– Автомобиль – югары куркыныч зонасы ул, шуңа күрә теләсә нинди вазгыятьтә дә мин кагыйдәләрне төгәл үтим. Миңа бездәге мохит һәм ярдәмчел коллективыбыз бик ошый, үземне команданың бер өлеше итеп тоям һәм хезмәтем сыйфатлы булсын, миңа күрсәтелгән ышаныч аклансын өчен барысын да эшлим, – ди Рөстәм Шәйхаттар улы. Аның хезмәттәше **Фәнис Мөхәммәтҗанов,** 16 ел стажлы шофер, инде дүрт ел лицейда транспорт йөртә. Аның өчен төп принциплар – пунктуальлек һәм намуслы мөнәсәбәт.

– Хәзер лицейның җылы һәм уңайлы яңа автобуслары бар. Паркны яңарту – лицейның бу эшкә ничек җаваплы каравының бер кечкенә генә мисалы, – ди Фәнис Фәрит улы. – Үз өлешеңне кертү күңелле. Биредә безнең эшебезнең кадерен белүләре, аңа лаеклы түләүләре, ә коллективның безгә хөрмәт белән каравы сөендерә.

ҺӘРКЕМ ФАЙДАЛАНЫРЛЫК ТӘҖРИБӘ

Һәр мәктәп уникаль. Һәрберсенең үз старт шартлары, ресурслары, бурычлары бар. Әмма Казан инженерлык лицееның тарихы шуны раслый: алга китеш идеаль шартлардан түгел, ә дөрес кәефтән туа. Аның нигезендә команда энергиясе, тукттарга ирек бирми торган дисциплина, теләсә нинди хәлдән чыгу юлын табарга ярдәм итә торган оптимизм ята. Һәм, әлбәттә, куәтле эчке мотивация. Болар барысы бергә киләчәккә җайлашырга гына түгел, ә аны кыю рәвештә үзләренә үк булдырырга да мөмкинлек бирә торган көчне тәшкил итә.

«Әстәгъфирулла», 2024 ел

КҮЗ ЯШЬЛӘРЕ, ЕЛМАЮЛАР – БОЛАР БАРЫСЫ ДА «ӨМЕТ»

Олеся Бондаревская

Татарстандагы укытучылар һәм белем бирү учреждениеләре вәкилләре уйный торган бердәнбер милли театрга шушы арада 15 яшь тула.

– Китмә, Мәдинә! Бәлки, әле үзгәрергә соң түгелдер, – дип ялвара ул.

– Син үзгәрмәячәксең. Менә нәрсәдән куркам мин, – дип кистерә Мәдинә җавапка.

Һәм китеп бара. Тик бу безнең тарихның башы гына.

ИҢ ӘҺӘМИЯТЛЕ НӘРСӘЛӘР ТУРЫНДА

«Җәяүле Мәхмүт» драмасында барган вакыйгалар шулкадәр үзенә җәлеп итә ки, сәхнәдә профессиональ актёрлар булмавын онытып ук җибәрәсең. Болар – Казандагы Лицей – инженерлык үзәгенең «Өмет» труппасы үзешчәннәре. «Җәяүле Мәхмүт» Мостай Кәрим пьесасы буенча әзерләнгән, труппа куйган тамашаларның 15 нчесе, димәк, юбилей спектакле дияргә дә мөмкин. «Өмет»нең барлык репертуары шикелле үк, ул катлаулы булмаган сюжетка корылган, әмма тамашачының күңелен кузгата торган тормышчан хәлләрне үзәккә ала. Пьесаларны һәм актёрларны **труппаның режиссёры Раил Мөхетдинов** сайлый.

– Яхшы педагог яхшы актёр да була ала дигән канун юк, әлбәттә, әмма бу ике һөнәр кайсыдыр яклары белән охшаш. Мин кешенең күз карашыннан ук сәхнәдә ничек уйнайсын тоеп, әйтеп бирә алам. Без лицей директоры Венера Хәйретдинова белән бүгенге актёрлар труппасы составын берничә ел буена тупладык. Аның хәерхаһлыгы нәтиҗәсендә, коллектив яхшы үсеш кичерә, без елга бер спектакль чыгармый калмыйбыз, – ди ул.

«Өмет» труппасы сәхнәгә куйган спектакльләрнең беренче тамашачысы – лицей укучылары, педагоглары һәм монда белем алучы балаларның әти-әниләре. Бу аудиториягә теләсә кайсы пьеса туры да килми, кызык та булмаска мөмкин.

– Мин нигездә мәхәббәт, гаилә кыйммәтләре һәм мөнәсәбәтләре турындагы әсәрләрне сайлап алырга тырышам, – ди Раил Фәргать улы. – Алар үзәктә булырга тиеш. Көндәлек мәшәкатьләр эчендә без еш кына бу кадерле нәрсәләрне онытып җибәрәбез, әмма тамашачы спектакльдән чыкканда, үзенең нинди олы байлыгы бар икәнен аңлап чыксын – шул иң әһәмиятлесе.

КОЙМАК – МӘХӘББӘТ, ДИГӘН СҮЗ

Режиссёрның нияте һәрчак тормышка аша икән. Ун ел узганнан соң да, тамашачылар «Күз нурларым» спектаклендәге героиняның ничек итеп коймак пешерергә йөргәнен онытмый. Айгөл Әхмәтгалиева пьесасы буенча куелган спектакль була ул. Коймак – гаилә җылысы, рәхәтлек, газиз өй, ярату, кайгыртучанлык символы. Без аларны еш кына күз уңыннан ычкындырабыз... ә югалткач, тирән әрнибез. Кадерле беләбезме икән?

«Күз нурларым» спектаклен карaганда, тамашачы күз яшьләрен тыя алмаган. Наил Гаетбаев әсәре буенча сәхнәгә куелган «Әстәгъфирулла»ны караганда исә көлеп эчләре катканн. Төп героиня тормышына бәреп килеп кереп, аны пыран-заран китерүче дус кызы ролен **Гүзәл Чернова** башкара – аңа карап туя алмыйсың. Актриса труппада оешкан көннән бирле, аның портфолиосындагы рольләр шулкадәр төрле ки, сокланып тел шартлатырга гына кала: «Әстәгъфирулла»дагы дуамал Бикә булсынмы ул, «Син бит минем бергәнем»дәге хәлиткеч хәбәр китерүчеме...

– Героиням – улы Чечняга китеп, сугышта һәлак булган дип саналган, ә күп еллар узганнан соң, сукырайган килеш исән-сау әйләнеп кайткан хатынның дусты. Пьесадагы сюжет буенча, мин бу хәбәрне егетнең элеккеге йөргән кызына җиткерергә тиешмен.

Фото: Лицей – Инженерлык үзәге архивыннан. РЕКЛАМА

Әмма ул инде – башка берәүнең хатыны...

Минем дә улым бар, героиняны уйнаганда көчле хисләр өермәсе кичердем. Билгеле, барлык без уйнаган спектакльләрдә дә мондый ук драмалар булмый, әмма нәрсә генә уйнасак та, бөтен йөрәгебезне биреп уйнарга омтылабыз. Һәр рольне үзебез аша уздырабыз. Залда чын эмоцияләр тусын өчен, синең сәхнә әсәрендә тәмам эреп югалуың кирәк. Караган тамашачыларның кичерешләре – безнең өчен иң зур бүләк, – ди Гүзәл Чернова.

«ӨМЕТ» ХЫЯЛЛАРНЫ ЧЫН ИТӘ

«Өмет» иҗади хобби гына түгел, ул лицей коллективын берләштерә һәм илһамландыра торган пространство да. Аларга бүгенге дөньяда үзләренең нинди урын тоткаларын ваемларга да ярдәм итә икән ул.

– Театр – үзең булып калу белән беррәттән, башка тормышны да яшәп карау мөмкинлеге. Педагог һәм шулай ук актёр юлын мин егерме бер яшемдә башладым. Гомер буе театр белән математика янәшә барды: һәр икесендә материалны яхшы белү, тырышлык белән иҗадилык кирәк. Педагог кичен репетиция ясый, ә иртән дәрескә керә. Бу – бик зур, фидакарь хезмәт, әмма аның әҗере дә бар. Сәхнәгә чыгасың да, бөтен авырлыклар онытыла, чын йолдызга әверeләсең! Лицейнең безгә мондый мөмкинлек бирүенә чын күңелдән рәхмәт, – ди **мөгаллим Газинур Җиһаншин**. Юбилей спектаклендә ул хатыны ташлап киткән кече күңелле тегүче Мәхмүтне уйный. Әмма хатыны берничә елдан кабат әйләнеп кайта. Бәлагә очраган яңа иренә булышуын үтенә. Хатыны Мәдинә ролен **Инара Краснова**

«ӨМЕТ» КОЛЛЕКТИВЫ СОСТАВЫ

Раил Фәргать улы Мөхетдинов, режиссёр
Сирин Римгил улы Гасимов, физик культура укытучысы
Роберт Радик улы Харрасов, административ-хуҗалык бүлеге хезмәткәре
Газинур Нурмөхәммәт улы Җиһаншин, сак хезмәте җитәкчесе
Ранил Рифат улы Гобәйдуллин, физика укытучысы
Гөлнара Әхкам кызы Әхмәтова, туган тел (татар теле) һәм әдәбият укытучысы
Гөлназ Габдулла кызы Гыйлаҗетдинова, туган тел (татар теле) һәм әдәбият укытучысы
Гүзәл Әнсар кызы Чернова, кадрлар буенча белгеч
Лилия Рифкать кызы Газизҗанова, тәрбияче, туган тел (татар теле) укытучысы
Нурсинә Ильяз кызы Мельникова, биология укытучысы
Карина Сергей кызы Верховцева, немец теле укытучысы
Инара Хамат кызы Краснова, педагог-психолог

«Син бит минем бергенәм», 2025 ел

башкара. Юбилей спектакле – аның өчен дебют.

– Сәхнәдә уйнарга кечкенәдән хыялландым, – ди ул. – Үзешчәнлектә инде – бик күптәннән. Лицейда эшләгән биш ел дәвамында барлык спектакльләрне дә карап бардым. Коллегаларның сәхнәдә бөтенләй яңа, көтелмәгән яклары белән ачылуын күрү бик ошый, – ди Инара Краснова. – Быел Раил Фәргатович миңа да роль тәкъдим итте. Мин баштарак шикләндем, чөнки җәй көне җитди дәвалану узган идем. Әмма режиссёрыбыз да, коллегаларым да: «Әйдә, син булдырасың!» – диделәр. Бу – бик зур ышаныч та, җаваплылык та. Безнең хөрмәтле коллектив белән лицей аудиториясе алдында имтихан тотуга тиң. Әзерләнә торган спектакль мине бик илһамландыра, премьераны түземсезлек белән көтәм.

ЙӨРӘК СӨЙЛӘГӘНДӘ, ТӘРҖЕМӘ КИРӘКМИ

«Өмет» гастрольләргә күп йөри. Коллектив спектакльләр белән Татарстан районнарына еш чыга, алай гына да түгел, Кырымда, Краснодар өлкәсендә, Кыргызстанда да булып кайтканнар. Татар диаспорасы ярдәме һәм чакыруы буенча, Германиядә үк чыгыш ясаганнар.

Аларны һәрчак алкышлап каршы алалар һәм озаталар. Хәтта телне белмәгән тамашачылар да. «Өмет» актёрлары тамашачыга бүләк иткән җылылык алар сәхнәләштергән тарихларны һәркемгә аңлаешлы итә.

– Безнең артистлар мөгаллимнәргә хас булган төрле талантларны сәхнәдә дә күрсәтә. Чит ил аудиториясенә татар теле – яңалык, ә ватаннан еракта яшәүче милләттәшләр өчен ул – зарыктырган, кадерле сөйләм. Аларның кичерешләре бик көчле, труппабызның башка төбәкләрдә, илләрдә уңышы шул сусауга да бәйледер, – ди Раил Мөхетдинов.

Шулай да, иң яратып уйный торган урын – үзләренең лицей сәхнәсе. Коллегалар, укучылар, ата-аналар – иң рәхмәтле аудитория. Иҗади эзләнүләр дә, ролеңне тиешле дәрәҗәгә җиткерү өчен төн йокыларын кызганмау да, мизансценаларны өзлексез камилләштерү дә – аларның йөрәкләре кабул итсен, бер ритмда типсен өчен!

Педагоглар уены бередә икеләтә мәгънәгә, әһәмияткә ия: чөнки театр аларның барысын да берләштерә.

БЕР ЕЛ – ҺӘМ ОЗЫН ТАРИХ

КАЗАН ЭНЕРГЕТИКА УНИВЕРСИТЕТЫ ӨЧЕН 2025 ЕЛНЫҢ УҢЫШЛЫ НӘТИҖӘЛӘРЕ

Евгения Чеснокова

Узып баручы ел Казан дәүләт энергетика университеты өчен мөһим һәм күпмедер дәрәҗәдә юбилей елы булды. Ни өчен күпмедер дәрәҗәдә соң? Уку йортының бүгенге исеме – КДЭУ – 25 ел элек, 2000 елның октябрендә пәйда була, гәрчә аңа кадәр дә Казанда энергетика буенча белем бик күптәннән бирелсә иде.

Әменә вуз өчен 2025 елның ни өчен әһәмиятле булуы турында җентекләбрәк сөйләрбез. Башта бераз – тарих. Беренче Казан энергетика институты 1930 нчы елларда ук ачыла, тик өч елдан соң уку йортын ябалар. Бүген эшләп килә торган вуз Казанда 1968 елда ачылган Мәскәү энергетика институты филиалының варисы санала. 1999 елда ул мөстәкыйль уку йорты итеп үзгәртелә, ә инде бер елдан соң университетка әйләнә.

Бу еллар эчендә вузда көчле инженерлык мәктәбе оеша. Инженерлык белеме өр-яңа дәрәҗәгә күтәрелгән, 20 ел элек әле хыялланырга да базмаган технологияләр пәйда булган хәзерге вакытта КДЭУ үз тармагындагы үзгәрешләрнең башында тора. Моңа тагын бер дәлил – 2025/26 уку елында вузга бюджет урыннары моңарчы күренмәгән санда бүлеп бирелә – 2401 (урыннарның 95 проценты – инженер белгечлекләре буенча).

Уку йортының 2025 елдагы казанышларына тукталыйк. Мәсәлән, быел КДЭУ ил Хөкүмәтенең сыйфат өлкәсендәге премиясенә лаек булган бердәнбер Россия университеты дип табылды. Шулай ук 2025 елда Казан энергетика университеты RAEX агентлыгы версиясе буенча И (б) ФОнда Россиянең җирле вузлары рейтингының беренче бишлегенә керде.

2025 елның июлендә КДЭУ мәйданчыгында беренче тапкыр Киләчәк энергетикасы инженерларының халыкара җәйге мәктәбе («ИНЖИР») дип аталган зур федераль проект гамәлгә ашырылды. Казанга Россия энергетика министры Сергей Цивилёв килде һәм җәйге мәктәптә шөгыльләнүчеләр каршында ачык лекция белән чыгыш ясады. Ул вузда мәгариф өлкәсендә энергетика суверенитеты стратегиясенең уңышлы гамәлгә ашырылуын бик рәхәтләнеп билгеләп үтте.

Агымдагы елның казанышлары турында сөйләгәндә, һичшиксез, университет хезмәткәрләренең кайбер шәхси уңышларын да әйтергә кирәк. Мәсәлән, КДЭУның «Сәнәгать предприятиеләрен электр белән тәэмин итү» кафедрасы доценты Василий Басенко Татарстанның иң яхшы яшь галиме дип табылды. Ул шулай ук Алемасов исемендәге ТР Дәүләт премиясенә лаек булды – электр җиһазларының техник торышына контактсыз контроль ясау өчен цифрлы лазер контроль-исәпләү комплексын эшләүгә керткән зур хезмәте өчен. Ә аспирант һәм вузның яшьләр бизнес-инкубаторы җитәкчесе Алсу Җәмилева «Иң яхшы яшь стартап» номинациясендә «Фәнни ыргылыш» Республика премиясе лауреаты булды. Аның проекты топ-1000 Россия стартаплары арасына керды.

Энергетика университеты галимнәренең башка кайбер проектлары да югары бәяләнә – быел вуз ТР Фәннәр академиясенең шундый проектларга тәгаенләнгән өч грантын алды.

КДЭУ эшчәнлегендә мөһим принцип – энергетика тармагы предприятиеләре белән тыгыз хезмәттәшлек. Һәм бу урында күптән түгел генә узган әһәмиятле бер вакыйганы билгеләп үтәргә кирәк – ноябрьдә «Газ-турбина җиһазлары заводы» АҖ базасында «ТурбоПИШ» кафедрасы ачылды. Кафедра эшенең юнәлеше – «Энергетика машина төзелеше». КДЭУ ректоры Эдвард Абдуллаҗанов һәм «Газ-турбина җиһазлары заводы» АҖ генераль директоры кафедра оештыру турындагы килешүгә заводның тантаналы ачылышы вакытында кул куйды. Тантанада ТР Рәисе Рөстәм Миңнеханов та катнашты. Яңа мәйданчыкта студентлар гамәли әзерлек үтә, заманча җиһазлар һәм технологияләр белән таныша ала. Ә әле яңарак кына, декабрь аенда, республика әһәмиятендәге алдынгы инженерлык мәктәпләрен төзү буенча конкурс нәтиҗәләре билгеле булды – КДЭУ белән «ТурбоПИШ» «Амкор» компанияләр төркеменең уртак гаризасы җиңүчеләр исемлегенә кергән.

«Без энергетика тармагының киләчәге белем бирү, фән һәм җитештерүнең интеграциясенә бәйле булачак дигән ныклы карашта торабыз. Сәнәгатьтәге партнёрларыбыз белән хезмәттәшлек инженер кадрларын әзерләүнең сыйфатын күтәрүдә гаять мөһим фактор булып тора», – диде Эдвард Абдуллаҗанов.

Фото КДЭУ матбугат хезмәтеннән. РЕКЛАМА

ТАТАРСТАН

журналын кайдан сатып алырга:

ВЕНДИНГ АППАРАТЛАРЫНДА

- **«Мегастрой»**
  Гаврилов ур., 5
  тәүлек буе
- **Казан-2 тимер юл вокзалы,**
  көтү залы.
  Воровский ур., 33
  тәүлек буе
- **«Тукай мәйданы» метро станциясе**
  6:00 дән 00:00 гә кадәр
- **Аэропорт терминал 1**
  тәүлек буе
- **«Дубравная» метро станциясе**
  (Зорге урамына чыгу)
  6:00 дән 00:00 гә кадәр

ozon.ru

market.yandex.ru

tatmedia.shop/ru

РЕКЛАМА. 16+

редакция кухнясы

Фото: Ната Смирнова. РЕКЛАМА

АДВОКАТ НАДЕЖДА МОРАТОВАДАН – СЕЛЬДЬ БАЛЫГЫ БЕЛӘН КАТЛЫ САЛАТ

Татьяна Вафина

Бер генә Яңа ел өстәле дә бу салаттан башка була алмый. Әгәр сездә ул юк икән, безне бәйрәмгә чакырып та тормагыз хәтта. Чөнки сельдь балыгы белән эшләнгән катлы салат – Яңа елның затлы гастрономия бизәге генә түгел, ә законы! Ә инде законнарны безнең бүгенге пешекчебез, адвокат буларак, бик яхшы белә.

ЮРИСТ ТА, ЖУРНАЛИСТ ТА, ҖИТӘКЧЕ ДӘ...

Законнарны гына да түгел. Аның белгечлекләре берничә: юрист та ул, журналист та, әле тагын психолог та, диләр.

– Төп белемем буенча мин – юрист, – ди Надежда, салат өчен кирәкле яшелчәләрне юа-юа. – Казан дәүләт университетының юридик факультетын тәмамладым. Юрфакның 1 нче курсыннан соң, журналистика факультетына да керергә булдым, анда читтән торып укыдым. Журналистикага кермәгән булсам, бу кадәр әдәби әсәр укымас идем. Ә сүз белән якыннан танышу сөйләм культурасына, текстларны тоюыма яхшы йогынты ясады. Юридик документлар, мәкаләләр язганда, бу сәләт бик яхшы ярдәм итә. Мин «Адвокатлар газетасы»нә һәм башка төр юридик басмаларга күп язам.

Психология буенча белемем юк-югын, әмма Югары икътисад мәктәбендә идарә итү буенча докторантурада белем алганда, юридик администрацияләү докторы дәрәҗәсен алдым. Идарә итү – ул бер үк вакытта психологияне белү дә. Үзеңне яхшылап аңлау, шулай ук командада эшләргә өйрәнү, клиентлар белән элемтә булдыру... «Адвокатлар бюросы белән идарә итү» темасына диссертация яздым.

Адвокатлык эшчәнлеге психология өлкәсендәге күнекмәләрне таләп итә, без бит һәр көн диярлек конфликтлы ситуацияләр, катлаулы кеше язмышлары белән очрашабыз. Шуңа да, адвокатурага килгәч, «Адвокатның аралашу күнекмәләре» дигән курсны узарга булдым, соңрак тагын берсен – «Медиация» буенча. Алга таба инде эштәге һөнәри талчыгуны исәптә тоткан профилактика курслары узылды, психологик экспертиза буенча курслар...

Киләчәккә планнар – ким дигәндә, тагын бер югары белем алу, анысы спорт белән нутрициология өлкәсендә. Җан белән тән өчен дә булсын, диюем!

ПАРАЛЛЕЛЬ УКУ

– Сез университетны тәмамлаганда, КДУның йөз иң яхшы чыгарылыш составына эләккәнсез. Ничек шулай булып чыкты?

– Мин гел «отлично»га укыдым, уку миңа бик җиңел бирелде. Юриспруденция яңа юнәлеш булмаганга, бәлки. Чөнки әле мәктәптә укыганда ук параллель рәвештә юридик көллияттә дә белем алдым. Иртән – мәктәп, төштән соң – көллият. Актив рәвештә фән белән дә шөгыльләндем, һәртөрле конференцияләрдә күп катнаштым, илебезнең төрле вузлары уздырган фәнни чараларда да. Хокук грамоталыгын арттыру буенча проектлар башкардым.

БЕЗГӘ КИРӘК БУЛАЧАК:

- Сельдь балыгы – 2 данә
- Бәрәңге – 2 данә
- Чөгендер – 4-5 данә
- Суган – 1–2 данә
- Йомырка – 6 данә
- Каймак – 300 г
- Кунжутлы серкә – түменчә

ТИКШЕРҮЧЕДӘН – АДВОКАТЛЫККА

– Адвокат – нәкъ менә шушы һөнәр турында хыялландыгызмы? Бу гаилә традициясеме?

– Балачакта тикшерүче булырга хыялландым. Яшьтәшләрем биш яшендә курчак уйнаганда, мин тикшерүче булып уйный идем, – дип елмая Надежда, яшелчәләрне пешерергә куеп. – Бу хыял юрфакка китерде, уку елларында прокуратурада өлкән тикшерүченең җәмәгать ярдәмчесе булдым. Бик кызыклы тәҗрибә, әмма тора-бара үз холкыма, табигатемә туры килә торган башка юлны сайладым. Адвокатурага 2002 елда килдем, адвокат ярдәмчесе булып эшләүдән башладым. Юридик факультетны тәмамлагач, ТР Адвокатлар палатасында стажёр булып урнаштым.

Әлбәттә, һөнәр сайлавыма балачактан юридик факультетта вакытымны күп уздыру тәэсир итми калмагандыр, чөнки әнием дә – адвокат, ул анда укыта иде.

«МОРАТОВА ҺӘМ ПАРТНЁРЛАР»

– Үз адвокатлар бюрогызны эшләтеп җибәрү идеясе ничек башыгызга килде?

– Табигый рәвештә килеп чыкты, үсеш этабының бер борылышы булды, дисәм дә, ялгышмам. Шәхси яктан да, һөнәри яктан да. Югары уку йортында белем бирү дәверендә (2015 елда адвокат статусын алганда, мин кафедрада доцент идем) юридик практика белән үзем шикелле үк мавыккан укучыларым барлыкка килде. Без профессиональ яктан бергәләп үстек. Ниндидер бер моментта үземнең адвокатлар бюросы ачарга әзер икәнлегемне тойдым. Бу – зур җаваплылык, билгеле, әмма идарә итүче партнёр буларак, мин моңа керешергә әзер идем.

– Гаилә, милек, бизнесны яклау – сезнең адвокатлар бюросында хезмәтләр киң колачлы. Болар белән идарә итү катлаулымы, сездә никадәр кеше эшли?

– Гаилә мөнәсәбәтләре безнең белән – тумыштан. Гаилә нигезендә безнең һөнәри юнәлешебез дә формалаша, милек алына, бизнес башлап җибәрелә. Шуңа да бу очракта хезмәтләрнең төрлелеге турында сүз алып барганчы, аларның комплекслы булуына күбрәк басым ясар идем. Законндагы үзгәрешләр дә шундыйрак, без хәзер ирле-хатынлы уртак мирас калдыру очракларын, шулай ук уртак банкротлык хәлләрен дә шактый күрәбез. Тикшерү мәсьәләләре, милекне бүлү, банкротлыкны тану, үзара җаваплылык һәм башка шундый якларны анализлау таләп ителә.

Бюрода алты партнёр-адвокат эшли, һәркайсының – үз өлкәсе. Аерым бер өлкәдә эш алып бару адвокатка конкурентлык ягыннан өстенлекләр бирә. Мин адвокат барлык эшләрне берьюлы алып барырга тиеш, дигән позиция белән килешеп бетмим. Кайвакытта коллегалар артыннан эшләрен җиренә җиткереп бетерергә туры килә. Мәсәлән, кемдер гаилә низагы очрагын үз өстенә алган, ди, әмма махсуслашу җитеп бетмәгәнгә, бар нечкәлекләрен белмәскә мөмкин.

Мин үзем балалар белән бәйле гаилә низаглары буенча махсуслашам: кем белән калуы, яшәве, аралашу хокуклары, ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителү, аларны кысу, балалар белән чит илләргә чыгу, халыкара масштабта балаларны урлап китү һ.б. очраклар. Шулай ук – милек бүлү, кайбер очракларда ул халыкара юрисдикция белән бәйле була, бизнесны үзара бүлешү, кыйммәтле активлар мәсьәләсе... Төзелеш өлкәсендәге килешүләр буенча да специализациям бар. Заказчы, генподрядчы һәм подрядчы арасындагы бәхәсле очраклар – минем өлкә, республикадагы шактый гына төзелеш объектлары буенча җиңеп чыккан эшләрем дә күп җыела. Тагын бер юнәлеш – тикшерүче дәүләт һәм муниципаль органнары, прокуратура тарафыннан башланган эшләр очрагында билгеле бер оешмаларның юридик хокукларын яклыйм. Дәүләт органнары һәм вазыйфаи затларның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата башланган эшләрдә катнашам. Җинаять процесслары буенча юридик фәннәр кандидаты буларак, гражданнарның җинаять эшләрендә яклаучы буларак катнашам. Гадәттә, икътисадый эчтәлекле эшләрдә аналитик функцияне башкару өчен дә кушылам.

Регина Хәсәншина исемле адвокатыбыз җир бәхәсләре өлкәсендә махсуслаша. Ул шулай ук зыян күрү очрагында бәхәсләрне ничек алып барырга, зыян күрүчене ни рәвешле якларга икәнен барыбыздан да яхшырак белә. Медицина эшләре буенча да белгеч. Регина – юридик фәннәр кандидаты, диссертациясе зыян күрүчеләргә шул зыянны каплау мәсьәләләренә багышланган. Шулай ук аның һөнәри осталык өлкәсе булып пенсия бәхәсләре дә тора. Аңа еш кына гражданнарның аерым бер категориясенә

(Эчке эшләр министрлыгы хезмәткәрләре, хәрби затлар, сәламәтлек өчен зарарлы шартларда эшләгәннәр) яклау күрсәтергә туры килә.

Бюро партнёрлары Рәнат Сверигин белән Айрат Гатауллин юридик затларга хезмәт күрсәтү буенча махсуслаша, салымнар белән банкротлык юнәлешендә эшкуарларга яклау күрсәтә.

Влада Железнова арбитраж эшләрен алып бара, тәэминат, арендаларны әйбәт белә. Ул хезмәт белән тәэмин итүдәге бәхәсләрне дә хәл итә, шул исәптән эш бирүчеләргә бәйле уңышлы кейсларга ия. Ә бу чыннан да катлаулы өлкә, чөнки судта хезмәткәр һәрчак диярлек хаклы.

Адвокат Диана Хөснуллина, минем шикелле үк, гаилә бәхәсләрен алып бара, алиментларны түләттерү очракларын хәл итә, кулланучылар хокуклары буенча белгеч санала, банклар һәм иминият компанияләре белән гражданнарны яклап, дәгъвалар белән шөгыльләнә. Торак буенча бәхәсләрне дә колачлый: торакта яшәүчеләрне дә, әлеге милеккә ия затларны да, ТКХ оешмаларын да, идарәче компанияләрне дә яклый.

АЛДАН УЙЛАП, БӘЯЛӘП ЭШЛӘНГӘН ПРОЦЕССУАЛЬ ЭШ ТӘРТИБЕ

– Сез аерым горурлана торган эш булдымы? Һәм, киресенчә, адвокатлык практикасында булган, их, ул вакытта башкача эш йөртәсе калган икән, дия торган очрак, мәсәлән...

– Әлбәттә, аерып куеп горурланган эшләр бар. Кызганыч, аларны кычкырып әйтергә, дөньяга чыгарырга гына ярамый. Адвокат аларны читкә чыгармаска тиеш, канун шундый.

Һәр эш буенча да, теге яки бу юридик юл белән киткәнче, фактлар һәм алшартларны анализлау этабы бар. Миңа документлар белән эш материалларын ышанып тапшырганда, анда бит закон чыгару базасы да, судка кадәрге практика да исәпкә алына. Мин, үз чиратымда, эше кулыма килеп кергән затка (оешмага) аның нинди юллары һәм нәтиҗәләре була алганын җентекләп аңлатам, бергәләп яклау тактикасын корабыз, әлбәттә, килеп туган шартлар белән, куркыныч янаган борылышларны да күздә тотып. Шуңа һәрбер «монда нәрсәдер башкача борылыш алды, без болай уйламаган идек» дигәнгә каршы, адвокат буларак, алдан уйлап, бәяләп куйган процессуаль кагыйдәләрем бар. Әгәр сүз суд утырышы турында бара икән, мин дә, бюро адвокатлары да, аның процессуаль яктан ничек узасын алдан күзаллап чыгабыз. Димәк, төрле документлар (гаризалар, үтенеч язулары) әзерлибез. Теләсә нинди штаттан тыш хәлләргә алдан ук әзер булырга тырышабыз.

БАЛАЛАРНЫ УРЛАП КИТҮ ОЧРАКЛАРЫ

– Сезнең адвокатлар бюросы күрсәтә торган хезмәтләр арасында балаларны урлап китү очраклары белән шөгыльләнү дә бар. Андый хәлләр Россиядә ни дәрәҗәдә еш күзәтелә? Татарстанда? Практикада булган берәр очрак белән бүлешә аласызмы? Ничек булышты-

гыз? Гомумән, ничек булышып була андый чакта?

– Әйе, андый очраклар алай ук күп түгел. Хәзерге трендларның берсе – балаларны чит илгә алып чыгуны тыю. Статистика буенча, Россиядә ел саен безнең ил гражданнары белән чит ил гражданнары арасында корылган гаиләләр арта бара. Шулай ук теркәлмәгән, чит илләрдә теркәлгән гаиләләр дә шактый. Интернациональ гаиләләрнең артуына бәйле рәвештә, шундый гаиләдә ата-аналар үзара конфликтка кергәндә, балаларны ничек тә яклау таләп ителә.

Мондый эшләрне 1980 елның 25 октябренә караган балаларны урлап китү очрагында гражданнарның хокук аспектлары буенча халыкара Гаага конвенциясе тәкъдим иткән механизмга нигезләнеп алып барабыз. Шулай ук 1996 елның 19 октябренә караган, балаларны яклау чаралары һәм ата-аналарга кагылышлы юрисдикция, кулланылган хокуклар, гаебен тану, эшне башкарып чыгу һәм үзара хезмәттәшлек турындагы Гаага конвенциясенә таянабыз. 2016 елда бу конвенцияләрне махсус өйрәндем, уку уздым, хәзер дә ел саен квалификациямне күтәрәм.

Мондый эшләргә алынган адвокат, иң беренче чиратта, менә нәрсәләрне белергә тиеш: төрле ил гражданнары булган ата-аналар гаиләсендә тәрбияләнүче балалар белән аларның мөнәсәбәтләрен яклый ала торган халыкара инструментлар нинди?

Россия территориясендә эш алып барганда, адвокат түбәндәге очракларда яклау ихтыяҗы белән очрашырга мөмкин:

- башка илдә яшәгән баланы РФ территориясенә алып кергән ата-ананы яклау;
- Россиядә яшәгән баланы башка илгә алып чыккан ата-ананы яклау;
- баласын урлаткан һәм ул бала РФ территориясендәге очракта ата-ананы яклау;
- баласын урлаткан һәм ул бала РФ территориясендә булмаган очракта ата-ананы яклау.

НАДЕЖДА МОРАТОВА,
Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы адвокаты, адвокатлар бюросының идарә итүче партнёры, медиатор. Казан дәүләт университетының юридик факультетын, шулай ук журналистика, социология һәм психология факультетын тәмамлаган. Юридик фәннәр кандидаты. Юридик администрацияләү докторы. Биш җыентык һәм монография авторы, автордашы. Күпсанлы юридик конференцияләр һәм түгәрәк өстәлләрдә катнашучы, спикер. Йөгерү, сәяхәтләр, дөрес туклану, тән сәламәтлеге һәм идарә итү турында китаплар укырга ярата.

1 Кисәбез

1 Тозлыйбыз

2 Салабыз

2 Уабыз

3 Майлыйбыз

3 Ягабыз

4 Чистартабыз

4 Чыгарабыз

5 Уабыз

5 Сылыйбыз

6 Ягабыз

6 Бизибез

Димәк, Россия чигендәге, чит ил дәүләтендәге коллега белән үзара аралашып эш итәргә туры киләчәк.

ГЕРМАНИЯ ПРЕЦЕНДЕНТЫ

Ике бала анасы белән булган очрак һич онытылмый... Балаларның язмышы хәл ителгән диярлек: немец суды Германиягә киткән хатынның элеккеге тормыш иптәше дәгъвасын канәгатьләндергән. Балаларны Россиягә кайтарырга дип карар кабул ителгән... Бу шактый типик очрак: хатын, чит ил кешесенә кияүгә чыгып, Германиягә күченергә карар кылгач һәм балаларны да үзе белән алгач, элеккеге ире пәйда булып, дәгъва белдерә. Клиент моңарчы булган судлар тарихы белән килде – Германиядә карар чыгарылган ике суд очрагы, алар балаларны ватанына кайтарырга дигән караштa тора. Казанның район судында туктатылган суд карары, үз балаларын «урлау» очрагы буларак теркәлгән ялгышлар эзе, юристлар хатасы... Әмма без, бернигә дә карамастан, башкарып чыгып булмастай карарга китерә алдык: судлар практикасында чит илгә бала белән чыкканда һәм даими яшәү урыны күздә тотылганда, икенче ата-ананың рөхсәте таләп ителүне бу очракта чыгарма иттердек.

Эшне «ерып» чыккач, чит ил юрисдикциясе белән мөнәсәбәтләрдә иң төп уңыш чыганагы төрле ил авдокатлары арасындагы аңлаша алу шарты булуына янә инандым. Һәрберсенең дә үз илендәге хокукый системаны гына белүе түгел, ә бер үк вакытта тиешле эшләр категориясендә белгеч булуы, һөнәри махсуслашуы да гаять әһәмиятле. Бу, билгеле, бик зур таләп, ул кыйммәткә дә төшә. Миңа эшен тапшырган ханымның адвокаты рус телен дә, Россия хокук системасын да белми иде, бездәге менталитетны да күз уңында тотмый. Элеккеге иренең адвокаты көчлерәк – телне дә белә, Россия хокук системасын да, шулай ук гаилә бәхәсләрен, бала урлау очракларын алып баруда да тәҗрибәсе бар. Аны җиңеп чыгу безгә җиңел бирелмәде. Әмма гаделлек урнашты.

«БАЛАЛАР ЭШЕ»

– «Балалар эше»ндә сез, адвокат буларак, иң әһәмиятлесе нәрсә дип әйтә аласыз?

– Иң беренче чиратта, балаларны яклауны. Ата-аналар нәрсәгә омтыла һәм нәрсә хакына көрәшә – анысы икенче урында. Моңа ирешер өчен, иң беренче эш итеп, балаларның нинди шартларга эләгәсен, аларга кайсы очракта кулайрак буласын уйлау зарур. Бала хокукларын яклау махсус белемнәр, күнекмәләр, халыкара стандартлардан хәбәрдар булуны да таләп итә.

ГАИЛӘ БӘХЕТЕНЕҢ СЕРЕ

– Сез – өч мәртәбә әни. Билгеле, балалар бәхете серен сездән дә яхшырак белүче юк... Гаилә белән эшне ничек параллель алып

барасыз, ничек өлгерәсез? Сезнең балаларыгыз әниләрен эштә югалтмыймы?

– Бу сорауны еш ишетергә туры килә, күп балалы әни булганга, күрәсең. Инде үсеп беттеләр, хәзер алар белән бик җиңел. Улыма 18 яшь тула, мәктәпне тәмамлый, МГИМОга керергә җыена. Уртанчы кызыма 15 тулып килә, ул да хокук классында белем ала, бик тырыша. Кечкенә кызыма 9 яшь, ул искиткеч мөстәкыйль. «Дәресләрең әзерләнгәнме?» – дигән сорау бирсәм: «Әнием, бар да контрольдә, борчылырга урын юк», – дип кенә җавап кайтара. Аларның башка әниләре юк. Алар җитди статусы һәм һөнәри яктан мәшгульлеге булган шушы әниләре белән үсте, яши һәм аңа ияләшкән. Болар барысы да мөстәкыйльлекләренә дә, социаль IQ дәрәҗәсенә дә йогынты ясамый калмагандыр. Алар белән өй эше эшләп утырмыйм, бу – аларның үз җаваплылык зонасы. Гаиләдә дә без кем нәрсә өчен җавап биргәнен ачыктан-ачык сөйләшәбез.

«Эш – гаилә» балансын саклау җиңел нәрсә түгел, әмма башкарып чыгарлык эш. Ял итүне дә планлаштырып була: әйтик, театрга бару, чит илләргә чыгу һәм башкаларны... Балалар белән без шундый чакта тагын да якынаябыз Безнең, мәсәлән, шимбә көнне коймак пешерү һәм барыбыз да бергәләп утырып иртәнге ашны ашау йоласы бар. Билгеле бер мизгелдә, балалар үсә төшкәч, моны тормышка ашыру кыенлаша төште, чөнки алар иртән мәктәпкә бара. Үзем бу очракта гаилә традициясенә тугрылык саклыйм. Чөнки шимбә иртәсе барыбыз да өйдә булган бердәнбер көн, анда беркем беркая ашыкмый.

Әни буларак, төп бурычым – балаларны ярату. Һәм мин аларны яратам: барлык эшләрендә дә теләктәшлек белдерәм, булышам, фикер алышам, нәрсәнедер аңлатам, нидер сөйлим. Ярату ул бөтен нәрсәне дә рөхсәт итү түгел, ул «ярдәм итү, инәңне куя белү». Һәр кичне без кичке ашка җыелабыз, кемнең көне ничек узган икәнен сорашабыз, йоклар алдыннан чәй эчәргә утырабыз, иртәгәге көнгә планнар белән бүлешәбез. Бу кечкенә генә гаилә мизгелләре бер-беребезне ныграк тоярга ярдәм итә. Гаилә бәхетенең сере әнә шундый гади ул.

УҢЫШКА ШАТЛАНУ БӘҺАСЕ

– Ә эштәге уңыш – һөнәри уңыш сере нәрсәдә?

– Һөнәреңне бик яхшы үзләштерү, механизмнарын белүдә. Моңа бик зур хезмәт белән генә ирешеп була, кайчакта гаиләңә игътибар җиткереп бетермичә дә. Боларын, әлбәттә, кычкырып йөрмисең. Әмма һәр профессионалның уңыш бәһасе артында четерекле көндәлек эш тора.

2025 елда улым, 10 нчы сыйныф укучысы, хокук буенча Бөтенроссия олимпиадасында җиңү яулады. Призёр дипломы аңа илебездәге теләсә кайсы вузга укырга керергә хокук бирә, билгеле, имтиханнарсыз. Бу инде – һөнәри уңыш. Әмма аның нинди бәһагә килүен бездән, өйдәгеләрдән кала, беркем дә белми. Бу – йокысыз төннәр, очсыз-кырые юк күнекмәләр, яшүсмерләр рәхәтләнеп күңел ача торган нәрсәләрдән читтә калу...

ИРТӘНГЕ ЙӨГЕРҮ ГЕОГРАФИЯСЕ

– Шимбә коймакларыннан кала, сез әле иртән йөгерергә дә өлгерәсез дип беләм?

– 2019 елдан башлап йөгерәм, бу – минем иртәнге ритуалым. Җиде ел эчендә инде Тын океан ярындагы Калифорния яр буенда да йөгерү бәхетенә ирештем, Итуруп (Курил утраулары) яр буенда да. Иртәнге йөгерүләр географиясе киң, шөкер! Таң атканда шәһәрнең уянуын күзәтергә яратам, шәһәр читендә чакта – табигать тантанасын. Көн буена җитәрлек эмоцияләр бирә торган, илһамландыра торган файдалы шөгыль.

«Ә ӘНИ ДӘГЪВАЛАР ӘЗЕРЛИ...»

– Әни йөгергән арада иртәнге ашны кем хәстәрли?

– Кәефенә карап, һәркем. Кем буш, шул. Балалар гадәттә иртән ашап тормыйча чыгып китә. Үземнең аерым туклану ысулым бар, аны берәүгә дә такмыйм, тик шул стильдә генә тукланам. Ит ашамыйм, глютен, баллы камыр ризыклары, йогуртлардан ерак торам... Балалар ит ашый, әмма башка яктан дөрес туклану яклы. Бигрәк тә өлкән улым: бик тәмле рецептлар табып, продуктларны яраштырып, ашарга пешерә ул.

– Ит, глютен, баллы камыр ризыкларыннан башка ни белән тукланасыз?

– Запеканкалар яратам – баллы җиләк-җимешләр белән дә, яшел үләннәр, тозлы әйберләр, сыр, балык белән дә. Һәр иртәне нинди дә булса төрен ашыйм. Әмма минем очракта иң яхшы әзерләнә торган нәрсә... ул – шикаятьләр белән дәгъвалар. Бу гаилә шаяруы: «Ә әни чираттагы дәгъваны әзерли». Гаиләбездә ризыкны миннән яхшырак әзерли торган ирләрнең булуы – бәхет ул.

ҺӘР ЕЛНЫ, 31 ДЕКАБРЬДӘ...

– Яңа елны ничек каршылыйсыз?

– Яңа ел – гаилә бәйрәме, өйдә, якыннар белән. Берәү дә беркая ашыкмый, йокы туйдыра, бер-беребез белән янәшәлекне тоюдан рәхәтлек кичерә. Яңа ел алдыннан, 24–25 декабрьләрдә, ыгы-зыгы башланганчы, шәһәрдән китеп бару традициясе бар. Бер биш көнгә тауларга китәбез. Чаңгы шуарга. Әмма бәйрәмгә өйгә кайтабыз, сельдь балыгы белән катлы салатны һичшиксез әзерлибез. Бу безнең гаиләнең яраткан Яңа ел салаты. 31 декабрьдә аны әзерләмичә калмыйбыз. Алдагы көнне, кичтән, чөгендер, бәрәңге, йомырканы пешереп калдырабыз. Балыкны гадәттә үзем тозлыйм. 31 декабрьдә, барлык мәшәкатьләр артта калгач, яраткан салатны ясарга керешәбез. Һәркем катнаша: кем – эш белән, кем сүз белән...

Бу гаилә белән җыелышып Яңа елга әзерләнү дә, түгәрәк кухня өстәле артында утырып, бергәлек хисен кичерү дә. Телевизорда Яңа ел фильмнары бара, ә син өйдә – җылыда, кадерле кешеләр арасында, беркая ашыкмыйсың.

«СЕЛЬДЬ БЕЛӘН КАТЛЫ САЛАТ» ТУРЫНДА ЛЕГЕНДА

Имештер, аны 1918 елда Мәскәү трактирщигы Анастас Богомолов уйлап чыгарган. Һәр ингредиент үзенең махсус символикасына ия булган: сельдь балыгы ул – эшчеләр, бәрәңге – крестьяннар, ә кызыл төстәге чөгендер – армия һәм революционерлар. «Шуба» дигән сүз дә ябышып кала салатка. Ә аның үз сере бар. Баксаң, бу аббревиатура икән: «Шовинизму и Упадку – Бойкот и Анафема».

ГАИЛӘ, МИРАС ҺӘМ БУЫННАР БУЫНГА НИ КАЛДЫРА?

Танылган адвокат, гражданлык-хокук бәхәсләрен хәл итүдә уналты еллык тәҗрибәсе булган суд яклаучысы, гаилә һәм мирасны планлаштыру буенча киңәшче Юлия Кәбирова мәңгелек сорауларга җавап эзли һәм кешеләрнең Яңа ел алдыннан гаилә юристларына нинди мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итүләре турында сөйли.

БҮЛӘК ИТӘРГӘМЕ, ВАСЫЯТЬ КАЛДЫРЫРГАМЫ?

Якынлашып килгән һәр Яңа ел алдыннан күпләр җыелган барлык мәсьәләләрне хәл итәргә омтыла, бигрәк тә якыннары һәм туганнары белән мөнәсәбәтләргә кагылганнарын. Шуңа күрә Яңа ел алдыннан милек (шул исәптән күчемсез милек) бүләк итү, никах килешүләре һәм васыятьләр төзүгә караган проектлар саны кискен арта. Соңгы елларда мондый документлар төзү алдыннан эксперт киңәшенә мохтаҗлык арту тенденциясе сөендерә – милек белән эш итә башлаганчы, ышаныч белдерүчеләр (клиентлар) башта «мондый бүләк»нең нәтиҗәләре турындагы хакыйкатьне белергә тели.

Мәсәлән, фатирда яшәүче ата-анадан милкен балигъ булган балаларына бүләк итү шартнамәсен төзетү кыен түгел, Росреестр яңа милекче

Фото: Юлия Кәбирова архивыннан. РЕКЛАМА

турында мәгълүмат керткәннән соң, бүләк итүче ата-ана исән чагында ук әлеге торакның милекчесе булудан туктый. Һәм менә монда сораулар туа – ата-ана алга таба да бу фатирда яшәргә планлаштырамы? Әгәр бүләк ителгән фатирда яшәвен дәвам итсә, баласы, ягъни яңа милекче аны әлеге фатирдан куып чыгара аламы? Бу хәвефләрне ничек тә булса булдырмый калырга мөмкинме?

Мондый сорауларга җаваплар катлаулы түгел, иң мөһиме, аларны вакытында белү кирәк – шартнамәгә, бүләк итүче әлеге торакта гомерлек яшәү хокукын саклап кала, дигән пунктны кертсәң, фатирны бүләк иткәннән соң да ата-ана аннан элеккечә тоткарлыксыз файдаланырга хокуклы булачак. Әгәр бүләк итү шартнамәсендә «Бүләк итүче бүләк иткән кешедән озаграк гомерле булса, РФ Гражданлык кодексы 578 маддәсенең 4 пункты нигезендә бүләк итүне гамәлдән чыгарырга хокуклы» дигән пункт күрсәтелсә, ата-ана үзе өчен инде болай да катлаулы – баласын югалту мизгелендә үз торагыннан мәхрүм ителмәячәк.

Әгәр хәзерге моментта балага милек хокукын рәсмиләштерү максатка ярашлы булмаса (мәсәлән, ул әле балигълыкка җитмәгән), бу очракта васыятьнамә төзергә мөмкин. Әмма васыятьне язганда мәҗбүри өлеш кагыйдәсен онытмау бик мөһим.

Бүгенге көндә гамәлдәге законнарда варисларның кайбер категорияләре өчен гарантияләр каралган – бу эшкә сәләтсез варислар (балигъ булмаганнар яки картлык буенча пенсия яшенә җиткәннәр) яки инвалидлык төркеме булган варислар. Хәтта мирас калдыручы васыять буенча бөтен мөлкәтен бөтенләй башка затка тапшырса һәм аларга бернәрсә калдырмаса да, бу варисларга закон мирас алу хокукын гарантияли. Бу төр варислар үзләре закон буенча дәгъва итә алырлык милекнең яртысын алуга хокуклы булачак.

Мисалга мондый хәлне күз алдына китерик: Иван Ивановичның өч баласы, өлкән яшьтәге эти-әнисе һәм яшь хатыны Вера Петровна бар. Иван Ивановичның өлкән балигъ булган улы беренче никахта туган, ике кече баласы, балигъ булмаган игезәк кызлар, никахтан тыш туган, әмма эти булуын ул шунда ук таныган һәм юридик яктан рәсмиләштергән. Безнең танышу вакытына Иван Ивановичның яшь хатыны белән уртак балалары юк иде. Нотариуска Иван Иванович үз ихтыярын белдерә: мирас вакыйгасы килеп чыкса (ул вафат булса), бөтен мөлкәтен яшь хатынына калдыра (аңа бик нык гашыйк була). Әмма нотариус васыятьне төзегән вакытта аның дүрт мәҗбүри варисы булуын аңлата – яшь буенча эшкә сәләтсез эти-әнисе һәм балигъ булмаган кызлары. Шуңа күрә мондый вакыйга очрагында аның мирасы варис хатынының берүзенә генә булмаячак. Барлыгы алты варис: этиәнисе, өлкән улы, балигъ булмаган кызлары, яшь хатыны. Әгәр васыять язылмаса, күрсәтелгән туганнарның һәркайсы Иван Ивановичның бөтен мирасының 1/6 өлешенә хокуклы булачак. Әгәр васыятьтә яшь хатын гына күрсәтелсә, аның ата-анасы һәм кызлары, мәҗбүри варислар буларак, Иван Ивановичның бөтен мөлкәтенең 1/12 өлешенә хокуклы булачак. Ә бу аның вафатыннан соң һичшиксез бәхәсләр тудырачак. Шуңа күрә профессиональ консультантлар һәрвакыт варислар даирәсен анализлый, васыять төзетүченең (ышаныч белдерүченең) мәҗбүри варисларын ачыклый. Туганнар арасында бәхәсләрне алдан кисәтү өчен, милекнең күпмедер өлешен васыять итмичә калдырырга кирәк. Алай-болай булган очракта ул мәҗбүри варисларга бүленәчәк. Ә мирасның икенче өлеше, варис теләгәнчә, васыятьтә күрсәтелгәннәргә тулы күләмдә калачак.

КАЙБЕР ТУГАННАР ОЗАК КАЙГЫРАЧАК, Ә КАЙБЕРЛӘРЕ ТИЗ ГЕНӘ «КВАДРАТ МЕТРЛАРНЫ» САНЫЙ БАШЛАЯЧАК

Еш кына ышаныч белдерүчеләр (клиентлар) юристларга, адвокатларга без судта хәл итәргә тиешле конкрет проблема белән мөрәҗәгать итә. Мирас бәхәсләре кысаларында мирасны кабул итү вакытын озайтуга, ир белән хатын өлешен бүлешүгә, туганлык мөнәсәбәтләрен ачыклауга, теге яисә бу мөлкәткә милек хокукын тануга кагылышлы сораулар еш очрый.

Еш кына шулай да була: ышаныч белдерүчеләр (клиентлар), туктале, боларның барысын да булдырмый калу мөмкин идеме соң дип, аерылышканнан соң яки туганнары үлгәннән соң катлаулы мирас кабул итү юлын узгач кына уйлана башлый. Мирас калдыручыга, үзе вафат булгач, кайбер туганнарының озак кайгырачагын һәм югалтуны авыр кичерәчәген, ә кайбер варисларның тиз генә «квадрат метрларны» саный башлаячагын аңлау җиңел түгел.

Безнең һәркайсыбызга туганнары һәм якыннары өчен мирас калдыручы ролендә булырга туры киләчәк. Исән чагында ук үзенең активларын варислары һәм якын кешеләре арасында бүлеп, берничә юридик документ төзегән мирас калдыручы гына мирас низагларын булдырмый кала яки һичьюгы минимальләштерә ала. Әгәр мирас калдыручы никахта тора икән, безгә никах шартнамәсе ярдәм итә ала: без аның мирасы составына мөлкәттән нәрсәләр керәчәген беркетәбез. Аерым васыять, ир белән хатынның уртак васыяте, мирас килешүе мирасны туганнар арасында низаг тудыомаслык итеп бүлешергә ярдәм итәчәк.

ГАИЛӘ ҺӘМ НӘСЕЛ ПЛАНЛАШТЫРУЫ. БУ ТУРЫДА КЕМГӘ УЙЛАНЫРГА КИРӘК?

Нәкъ менә беренче чираттагы варислары (ә аларга без ир белән хатынны, балаларны һәм ата-ананы кертәбез) бер-берсе белән катлаулы мөнәсәбәттә булганнарга: ир яки хатын потенциаль мирас калдыручының ата-анасы белән аралашмаганда; милек мәсьәләсе рәсми рәвештә (нотариус аркылы яки судта) җайга салынмаган элекке никах булганда; алдагы никахтан туган балалары яки әтисе тарафыннан танылган никахтан тыш балалары булганда, уйлану мөһим. Яки, мәсәлән, балалар законлы никахка кергән, әмма сайланган кеше мирас калдыручы тарафыннан хупланмаганда. Әгәр инде хәзер үк варисларның уртак тел таба алмаулары ачык икән (кемдер хәтта беркайчан үзара аралашмаган да), мирас вакыйгасы (мирас калдыручының вафаты) башланганнан соң барысы да мирасны тыныч кына бүлә алачак дип уйлау – беркатлылык ул.

Мирас составына катлаулы активлар: күчемсез милек, күчемле мөлкәт, бизнес-активлар, кыйммәт-

ле кәгазьләр, криптовалюта, трансформацияләнгән мөлкәт (гамәлдәге никахта, ләкин ир яки хатынның берсенең шәхси акчасына алынган) һ.б. кергән ышаныч белдерүчеләргә (клиентларга) мирасны планлаштыру белән шөгыльләнүне мөһим дип саныйм.

Әгәр каршылыклар, бурычлар, кредит йөкләмәләре бар икән, шуны аңларга кирәк: мирас хокукларын һәм мирасның катлаулы составын дөрес бүлү генә мирасчы тарафыннан булдырылган бөтен мөлкәтне саклап калырга һәм варисларның бетмәс-төкәнмәс суд бәхәсләрендә югалтмаска ярдәм итәчәк.

ОЧРАШУ УРЫНЫ – КАЗАН

Быел Казан беренче тапкыр гаилә һәм нәсел планлаштыруы буенча бөтен илдән җыелган киңәшчеләрнең очрашу урынына әйләнде.

Соңгы елларда бу өлкәдә профессиональ консультантлар саны артты, һәм миндә төрле төбәкләрдәге коллегаларның тупланган тәҗрибәсе белән уртаклашу теләге барлыкка килде. Шул рәвешле Казанда юристлар һәм адвокатлар өчен гаилә һәм нәселне планлаштыру буенча беренче форум уздыру идеясе туды.

Федераль масштабтагы мондый чараны оештыручы булу – зур җаваплылык, чөнки форум Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы советы химаясендә һәм Федераль адвокатлар палатасы ярдәмендә уздырылды.

2025 елның 2 августында Казан форумы илебезнең 18 төбәгеннән килгән нотариус, адвокат һәм юристларны кабул итте.

Экспертлар һөнәри тәҗрибә белән уртаклашты һәм ышаныч белдерүчеләргә (клиентларга) варисларына милекне бүләк итү (исән чакта) яки васыять һәм мирасны планлаштыруның башка инструментлары (мирас килешүе, ир белән хатынның уртак васыяте) аша тапшыру максатка ярашлырак булуы хакында фикер алышты. Соңгы елларда клиентларның күпчелеген кызыксындырган мәсьәләгә – мирасчының вафатыннан соң да зур капиталны саклап калу өчен нинди очракларда шәхси һәм мирас фондларын булдырырга кирәклегенә зур игътибар бирелде.

Казан хокук форумы нәсел стратегиясен төзү мәсьәләсен тирәнтен белгән һәм бу юнәлештә әзерлекле белгечләр күбрәк булсын, нәсел планлаштыруын гамәлгә ашыруда ышаныч белдерүчеләргә (клиентларга) тагын да профессиональ ярдәм күрсәтелсен өчен хезмәттәшләре белән тәҗрибә уртаклашкан белгечләрне бер мәйданда берләштерде.

2026 елның августында без хезмәттәшләребез белән бу тәҗрибәне кабатлауны планлаштырабыз.

игелекле эшләр

акыллы гамәлләр

мәңгелек кыйммәтләр /

Бу санда тәкъдим итәбез:

Бүгенгенең «зур» китаплары арасында **ниләр** бар

Түбән Бәрәскәдә тарихны **ничек** саклыйлар

Эммануил Пёльцам йорты **кайда** урнашкан

Баландышта «Түгәрәк уен» **ничек** узган

«РИВАЯТЬЛӘРДӘ, ӘКИЯТЛӘРДӘ ХАЛЫКНЫҢ ТАРИХИ ХӘТЕРЕ ЯТА»

Луиза Янсуар

Без университетта укыган 90 нчы еллар азагы – милли хәтернең әйләнеп кайткан чоры. Мәктәпләрдә дә, югары уку йортларында да тарихны укытуга гаять зур игътибар бирелә. Безгә борынгы төрки дәүләтләр белән Идел буе Болгар чоры тарихын укыткан галимнәрнең берсе – тарих фәннәре докторы, профессор, 300 дән артык фәнни хезмәт, дәреслекләр авторы Гамирҗан Дәүләтшин.

Гамирҗан абыйның Төрки каһанлыгы, Хәзәр каһанлыгы, Бөек Болгар дәүләте, Идел буе Болгарстаны, Җучи Олысы, Казан ханлыгы тарихын зур ватманнарга таблицалар ясатып, ятлатып өйрәткәнен барыбыз да яхшы хәтерли. Таләпчәнлеген, борынгы дөньялар белән җилкетә, кызыксындыра алуын. Без – алар әнә шул милли хәтергә мәхәббәт тәрбияләгән, аны киләчәккә илтергә кирәк, дигән инану орлыклары салып үстергән буын. Шуңа да әңгәмәбезне университетның, гомумән татар фәнни, мәдәни дөньясының гөрләп торган елларын искә алудан башладык.

– Гамирҗан абый, безгә 90 нчы еллар азагында тарихны, сездән кала, Миркасыйм Госманов, Җәүдәт Миңнуллин, Динә Мостафиналар укытты. Без ул вакытны университетның «алтын чоры» дип искә алабыз...

– Рәхмәт, Луиза, сеңлем, димәк, без аз гына булса да остазларыбыз салган оеткыны саклый, сезгә дә китереп җиткерә алганбыз. Мин моңа бик сөенәм. Чынлыкта, университетның «алтын дәвере» ул без укыган еллар булгандыр... Нил Юзеев, Диләрә Тумашева, Альфред Халиков, Мөхәммәт Мәһдиевләр укытты ул вакытта. Төркем кураторыбыз яшь галим Хатыйп Миңнегулов иде. Һәр буын үз чорын ностальгия белән искә ала, билгеле. Сез укыган һәм аспирантурада калган елларда да университетның, Гуманитар институтның күтәрелеп, көчәеп

Фото: Александр Ефремов, Гамирҗан Дәүләтшин архивыннан

киткән чоры иде. Әдәбият кафедрасында – фәнни җитәкчегез Резеда Ганиева бик көчле теоретик та, практик та галим. Татар теле кафедрасында – Фәһимә Хисамова, татар теленә өйрәтү кафедрасында – Флера Сафиуллина, методика кафедрасын Тәлгать Галиуллин җитәкли. Яшь галимнәр плеядасы үсеп килә...

– Ни өчен сез, филология юнәлешен сайлаган, шигырьләр яза торган егет, кинәт кенә тарихка йөз белән борылдыгыз?

– Сүземне гаиләдән башлыйм әле. Без этидән ятим калып, ишле гаиләдә үстек, мин – алтынчысы, төпчек. Әниебез Икълимә бик булдыклы, эшчән, намуслы, кешелекле иде, искиткеч иҗади да. Ул үз гомерендә укый-яза белмәде, әмма бик оста җырлар чыгарды. Халык җырларына охшатып, эчтәлекле дә, мәгънәле дә, моңлы да, фәлсәфи дә шул дүртьюллыкларын әни олыгайган көндә махсус дәфтәргә язып алдым. 50 ләп шигырь, ул гаилә архивыбызда кадерләп саклана. Аңа хәтта эткәй дә сугыштан хатларны шигырь белән язган. Бер хатында мондый юллар бар:

Йөзләремне яктыртучы
Илкәемдә син идең.
Газизем, дип, көтеп алыр
Бердәнберең мин идем.

– Ник шагыйрь булып китмәдегез?

– Әни минем бик тә югары белемле, һөнәрле кеше булуымны теләде. Белемгә тартылуымны да, шактый гына зиһенле икәнлегемне дә күзәтеп йөргән, күрәсең. Мәктәптә укытучыларым да укуга бик рухландырды. Шигырьләрне 5 сыйныфтан яздым, авылыбыздан танылган журналист Дамир Гарифуллин, үсендереп, аларны матбугатка тәкъдим итте. Мәктәпне тәмамлагач, язучы, журналист булам, дип омтылдым. 1968 елда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга кердем. Без бер курста Фәннур Сафин, Марсель Галиев, Роберт Миңнуллин, Сәетбаттал Закировлар белән укыдык. Тулай торактагы бүлмәбез штаб кебек иде: анда Мөдәррис Әгъләм, Зөлфәт, Рәдиф Гаташ, Разил Вәлиев та килеп керә, актлар залында шаулап шигырь кичәләре уза. Шунда үземә әйттем: «Юк, Гамирҗан, боларның шигърияте – әллә кайсы югары катлардан, син бу өлкәдә беренче була алмыйсың, сиңа башка юлны сайлап, шунда үзеңне табарга кирәк...»

– Бәхетегезгә, Диләрә апа Тумашева сездә фәнни нерв барлыгын күреп ала...

– Нил Юзеев белән алар миндә фәнни потенциал күрде, Диләрә Гарифовна археолог Альфред Халиков белән таныштырды. Альфред Хәсәнович искиткеч кече күңелле, кайгыртучан һәм кызыксынучан кеше иде. Аның иң беренче соравы: «Син ач йөрмисеңме? Ашарга акчаң бармы?» – булды. Чын галим дә! Ул мине ат кебек җигелеп эшләргә һәм бик дикъкатьле булырга, барлык фактларны төбенә төшеп өйрәнергә, кат-кат тикшерергә күнектерде.

Гаилә альбомыннан истәлекле бер сурәт. Әнисе Икълимә алдында – төпчек, сабый Гамирҗан.

Ул чакта фәнни өлкәдә борынгы гарәп, иске татар язуларын укырдай яхшы потенциалы булган кешене эзләгәннәр. Эпиграфика, мифология белгече Һарун Йосыпов вафат булу сәбәпле, аңа алмаш тәрбияләгәннәр. Мин аның архивын өйрәндем һәм тасвирладым, алга таба фәнгә кереп киттем.

– Тарих ул фантазияне түгел, ә математик төгәллекне ярата торган фән: саннар, табылдыклар сөйләп торган фактлар... Сезнең өчен үз гомерегездә иң тетрәнгеч экспедиция кайсы булды? Кайсылары белән чын мәгънәсендә горурланасыз?

– Мине экспедицияләргә Халиков алып чыкты, беренче табылдыкларны Тәтештәге казу эшләре вакытында кулга тотып карадым, алкалар иде ул.

Университетның беренче курс студентлары. Кураторлары – яшь галим Хатыйп Миңнегулов.

Студент чактан дуслар, коллегалар – шагыйрь Роберт Миңнуллин һәм тарихчы Фаяз Хуҗин белән.

Археологиянең нәрсә икәнен, аның михнәтен дә, тәмен дә шул чакта белдем. Баш та күтәрмичә тәүлекләр буе эшлим, кызыксынуымны күреп, Альфред Хәсәнович тагын да күбрәк эш бирә. Биләрдә дә без дистә еллар буе казу эшләре алып бардык... Халиков үзе татар телен начар белә иде, ул минем мифология буенча белемемә, язуларны укуыма таяна, тора-бара телне дә миннән өйрәнә башлады. Әкиятләр сөйләтә иде. Ул чакта мин әле – яшь малай, әкият әкият инде, дип кенә карыйсың бит. Әмма Альфред Хәсәнович риваятьләр белән әкиятләрдә халыкның тарихи хәтере ятуына чын күңелдән ышанды.

– Сез кандидатлык диссертациясен яклаганда, Болгар тарихы турында әле авыз тутырып сөйләмәгәннәр дә. Шуңа да аны яклау катлаулы булдымы?

– Миңа теманы Альфред Хәсәнович тәкъдим итте. Укуны тәмамлаганда, «Татар мифологиясенең тарихи тамырлары» дигән диплом эше яздым, кандидатлык диссертация темасы «Идел буе Болгар дәүләте халкының рухи мәдәнияте» иде. Мине башта бик куркыттылар – авыр тема, рухи мәдәнияткә алынасың, чыганаклар бит юк!

Аны яклау алты елга сузылды. Ә ул арада, 1976 елда аспирантураны тәмамлагач, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының фәнни архивына мөдир итеп билгеләделәр. Дистә ел эшләү дәверендә татар язучылары, әдәбиятчы, телче, тарихчы, мәдәният эшлеклеләренең шәхси фондлары, борынгы кульъязмалар, фольклор материаллары күпләп тупланды, фондлар эшкәртелде, тасвирламалары төзелде. Мәскәүдә 1982 елның 11 ноябрендә яклауның ничек узганын да һич онытасым юк. Аеруча дини аспектка игътибар иттеләр: динне мәдәнияткә кертеп карыйсызмы, дип кат-кат сорадылар, ни өчен мөселман мәдәнияте турында язуымны сораштылар, андый мәдәният юк бит, дип төпченделәр... Мин мөселман ренессансы турында әйттем, аны инглиз галимнәре өйрәнеп язуын. Шул чакта Мәскәүнең Алтын Урданы өйрәнүче олпат галиме Герман Алексеевич Федоров-Давыдов, ярдәм рәвешендә хуплап, «әйе, әйе» дип ымлый башлады. Аның репликаларыннан соң, башкалар да инде егып салмады. Эчкә җан керде... Шулай да диссертацияне озак кына расламадылар әле. Ә инде 2002 елда, докторлык диссертациямне яклаганда, бар да бик җайлы узды. Үземнең дә тәҗрибәм шактый иде.

– Тарих ул, иң беренче чиратта, сәясәт, илдәге хакимиятнең курсы белән турыдан-туры бәйле. «Татар тарихы» кайчаннан башлап «чыгарма» булудан туктады?

– Ул чакларда инде вазгыять үзгәрде: бездә дә ышаныч барлыкка килде, күпләп археологик табылдыклар да табып алынды, методика да булдырылды. Татар тарихы турында чорлап, периодлап дәреслекләр язылды, вуз программалары эшләнде. Аларны укыта-укыта, үзебез дә камилләштек. Мин Идел буе Болгар дәүләтенә кадәрге җирле мәдәни катламны да тикшердем, тәңречелек белән бәйле сәхифәләрне дә җентекләп өйрәндем. Моннан ике гасыр элек «халык» булып оешып җитешкән татарларның этник составы гаять катлаулы, бай, төрле. Ул үз эченә исламга кадәрге бай мәдәни пластны да ала, ислам белән бәйле этапларны да, Урда чорының озак елларга сузылган гаять үзенчәлекле дәверен дә... Болгар, Сувар архитектурасы белән корылмаларын «ачкач», мәсәлән, андагы пропорцияләргә шаккаттык – бу халыкның математик төгәллеге авыр хисапларга сәләтле булуы, абстракт фикер йөртә белүе турында сөйли...

– Бүгенге шартларда татар тарихы дөнья күләмендә нинди урын алып тора? Объектив яктыртыла һәм бәяләнәме? Халыкара конференцияләр, симпозиумнар, форумнарда татар тарихы ни дәрәҗәдә яңгырый?

– Дөнья күләмендә «татар тарихы» турында беләләр, аны хәттә бик яхшы белүчеләр

Фаяз Хуҗин белән сәфәрдә.

дә, тирәнтен өйрәнүчеләр дә бар. Шуны да онытмаска кирәк: бик күп чыганакларыбыз чит илләрдә саклана. Европа илләрендә, Иран, Төркия, Урта Азиядә... Аларны әле өйрәнәсе дә өйрәнәсе! Халыкара җыеннарда төрле темалар белән проблемалар күтәрелә, аларда безнең урыныбыз, һичшиксез, бар. Тарихчылар арасында бәхәс, килешмәү нокталары да, билгеле.

Бүгенге көндә иң катлаулысы – кадрлар мәсьәләсе. Әйтик, без «Татар тарихы» томнарын эшләп чыктык, мин моны бик зур җиңүебез, дип саныйм. Шул томнарны эшләү барышында, әйтик, бер төркем тарихчылар тырышлыгы белән «монгол игосы» дигән төшенчәне тарих фәнендә өр-яңадан күздән кичерүгә өнди алдык. Аңа караш үзгәрде, татар халкын да хәзер ул күзлектән бәяләми башладылар. Хәтта федераль дәрәҗәдә ул төшенчәне дәреслекләрдә дә инде башкача аңлату зарурлыгына килдек. Иң борчыганы – томнар бар, капиталь хезмәт башкарылды, хәзер инде үзләштерү дә кирәк. Ягъни бу тарихны киң җәмәгатьчелеккә җиткерер, вузларда, мәктәпләрдә укытыр кадрлар җитенкерәми...

– Бүгенге яшьләр тарихка гомумән киләме? Аларга бу өлкәдә перспектива бармы?

– Бар, әлбәттә, әмма тарих фәнендә аңа зур энтузиазм белән караган кешеләр генә чыдый да, кала да. Бүген галимнәрнең эшчәнлеге бик вак һәм бюрократик нәрсәләр белән «вакланa». Фән бик тармакланды, кайсы өлкәсендә кем нәрсә белән шөгыльләнә – очына чыгу да катлаулы. Элек ИЯЛИ да кысанлыкта утырсак та, энтузиазм – зур, барыбыз да бик зур бердәм эш башкарабыз дигән ышаныч көчле иде. Нәрсәнедер өйрәнәсең, шунда ук – фольклорчылар да, әдәбиятчылар да, тотынасың бергә анализларга... Архивларны өйрәнгәндә дә, һәркем кемнеңни өйрәнгәнен белеп, «томшыгына кабып» диярлек мәгълүмат белән килә, уртаклаша, булыша...

– Хәзер күпләп тарихи мираска әйләнеп кайту, опералар язу, сәхнә әсәрләре тудыру күзәтелә. Яңа буын иҗатчылар ни дәрәҗәдә тарихны белеп эш итә? Сез караган, укыган, тыңлаган әсәрләр тарихны дөрес чагылдырамы?

– Әдәбият кайчакта тарихны да, үткәнебезне дә психологик яктан яхшырак ваемларга ярдәм итә, дигән караштa торам. Тарихчылар корырак затлар, фактлар, табылдыклар белән эш итә. Филология белән тарих, археология чигендә торган кеше буларак, күбрәк синтезга ышанам, әдәбиятның гаҗәеп көче барлыгына басым ясыйм. Укып барырга да тырышам яңа әсәрләрне, матбугатны күзәтәм. Әйтик, заманында Нурихан Фәттах, Флүс Латыйфилар язган романнар халыкның хәтерен без тарихчылар язган трактатлардан яхшырак сугарды. Шагыйрьләрне әйткән дә юк, алар – гел алдынгы сызыкта. Нәкъ менә шагыйрь бер сүзе, җөмләсе белән тулы эпоханы аңлауны һәм кабул итүне үзгәртеп куярга сәләтле. Яшь авторларга да тарихи темаларга алынудан, тирәнгә чумудан курыкмаска киңәш итәм. Булсын, фантазия дә кереп китсен, кайчакта язучы үзенең рухы белән без тарихчылар барып җитә алмаган тирәнлекләрдән нидер «казып чыгара».

Гаилә җылысы.

– Тарихчылар арасында конкуренция көчлеме? Бүгенге әйдәп баручы белгечләр дип кемнәрне атый аласыз?

– Без бит төрле өлкәләрне өйрәнәбез, кисешәбез дә, урыны-урыны белән үзара килешмибез дә. Фән өчен бу – нормаль күренеш. Үз чорында мин Миркасыйм ага Госмановка соклана идем, ул гаять көчле, колачлы команданы туплый алды, бик продуктив эшләр эшләнде. Болгарчылардан дустым Фаяз Хуҗин бар, аның белән фикер дә алышабыз, бәхәсләшәбез дә, кайчак ачуланышыбрак та куябыз, әмма без – бер татар тарихы сагында торучылар. Бүгенге тарихчылардан Дамир Исхаков, Радик Салихов, Искәндәр Измайловлар бар... Тарих өлкәсендә манипуляцияләр, спекуляцияләр белән шөгыльләнү дә бар-барын, әмма монысы инде – намус эше.

– Гамирҗан абый, ярагызга кагылуым булса, кичерегез, әмма сезнең эздән киткән улыгызның хезмәте дөнья күрү – зур нәрсә...

– Маратның хезмәтен дөньяга чыгарулары һәм аның презентациясен уздырулары өчен Мәрҗани институты галимнәренә, рецензенты, оппоненты булган тарихчыларга бик рәхмәтлемен. Аеруча – Илдус Заһидуллинга, әгәр ул булмаса, китап дөнья күрә алмас иде. Бу эш алга таба Алтын Урда дәверен өйрәнүдә файдалы була күрсен...

– Сез гомерегез буена бик күп өлкәләрне колачлаган галим. Өйдәге тыл яхшы булмаса, бу кадәргә өлгерә алыр идегез микән?

– Чыннан да, Фирдәвескә бик таянам. Һөнәре буенча стоматолог ул, бик уңган кеше. Аның белән киңәш-табыш итешми калмыйм, барлык мәсьәләләрдә дә Фирдәвес – беренче киңәшчем. Инде оныклар да үсеп җитте, алар – яңа заман балалары, үз юлын эзлиләр. Бәхетләре булсын...

– Гамирҗан абый, форсаттан файдаланып, басмабыз һәм шәкертләрегез исеменнән 75 яшьлек юбилеегыз белән тәбриклим!

– Рәхмәт! Сезнең журналны да 105 яшьлеге белән котлыйм, иҗади уңышлар телим! Шәкертләремнең уңышларын күзәтеп барырга тырышам. Чөнки сез – безнең киләчәк, сеңлем!

БҮГЕНГЕНЕҢ «ЗУР» КИТАПЛАРЫ: ЧЫНБАРЛЫК БЕЛӘН УЙДЫРМА ЧИГЕНДӘ

Луиза Янсуар

Ел азагы китап дөньясында гадәттә уңыш җыеп алу вакыты. Язучылар өчен дә, нәшер итүчеләр өчен дә, тәнкыйтьчеләр өчен дә, китапханәләр һәм китап сәүдәсе белән шөгыльләнүчеләр өчен дә. Ел саен даими көтеп алына торган тагын бер әһәмиятле декабрь вакыйгасы – «Большая книга» Россия Милли премиясе нәтиҗәләре.

Китап дөньясында барган реформацияләргә тукталып тормыйча гына, быелгы XX юбилей сезоны нәтиҗәләренә күз салыйк. Җиңүчеләрне бүләкләү тантанасы, гадәттәгечә, Россия дәүләт китапханәсенең Пашков йортында 3 декабрьдә узды. 2025 елда яңа регламент буенча премия ике юнәлештә тапшырылды: «Әдәби проза» һәм «Нон-фикшн».

Премиягә дәгъва иткән 400 эштән озын исемлеккә 40 әсәр сайлап алынган иде. Экспертлар советы кыска исемлекне 15 автордан формалаштырды.



ЭДУАРД ВЕРКИН. «СОРОКА НА ВИСЕЛИЦЕ», INSPIRIA

«Әдәби проза» буенча премиягә Эдуард Веркин «Сорока на виселице» романы өчен лаек дип табылды. Әсәрне «элеккеге совет фантастикасы рухында» дип бәялиләр. Жанр кысаларына утыртып куелган «фәлсәфи роман» диючеләр дә бар. Веркинны Стругацкийлар дәвамчысы буларак та тәгаенләделәр.

Исеме үк атаклы Нидерланд рәссамы, аллегорияләр остасы – өлкән Питер Брейгельнең 1568 елда язылган һәм хәзерге көндә Дармштадта саклана торган картинасына ишарә. Роман чыннан да символлар, аллегорияләр территориясендә һәм утопия чигендә яши.

Сюжет буенча, без киләчәк дөньясына аяк атлыйбыз. Анда авырулар да, сугышлар да, картлык та, ачлык та юк, ике йөздән артык экзопланета ачылган һәм кешелек галәми киңлекләрдә таралып урнашкан. Җир экспансиясе дәвам итә, яңа галәм пространстволарын тикшерү, үзләштерүләр дә. Һәм менә гади генә тыюлык караучысы Ян кинәт, очраклы рәвештә, Җир цивилизациянең киләчәген хәл итәргә тиеш-

Фото: bigbook.ru, books.yandex.ru, mann-ivanov-ferber.ru

ле Олы Жюри составына сайлап алына. Бу Жюри вәкилләре барысы да үз тармагы буенча мәртәбәле экспертлар, ә Ян – инде популярлыгы күптән сүнгән һөнәр иясе, ул – коткаручы.

Веркин китабы катлаулы лабиринтлар белән нарратив сөючеләр өчен, монда гади генә берничә линиянең соңыннан бербөтенгә тоташуына өметләнергә кирәкми. Әмма без төп каһарман белән бергә күпкатламлы дөньяларга сәяхәт итәчәкбез, абсурд белән чынбарлык чикләрендә тибрәләчәкбез. Асылда, без болай да шунда тибрәләбез түгелме соң инде?

Юкка гына әйтелми ләбаса автор тарафыннан бу сүзләр: «Жизнь – это абсурд, а абсурд – это жизнь. Ну а все остальное – уже литература».

ЗОЯ БОГУСЛАВСКАЯ. «ХАЛАТНАЯ ЖИЗНЬ», КОЛИБРИ

Нон-фикшн юнәлешендә премияне 101 яшьлек Зоя Богуславская алды, бу, әлбәттә, вакыйга буларак кабул ителде. Сүз дә юк, Богуславская XX йөз рус әдәби-мәдәни контекстында уникаль урынны тотучы фигура. Тормыш иптәше Андрей Вознесенскийның аркадашы, тулы бер эпоханы теркәүче елъязмачы буларак кына түгел, ә 1991 елда сәнгать дөньясында гаять әһәмиятле иректә премияне һәм зур суммаларга ия «Триумф» фондын нигезләве белән дә. Шәхес үзе – бер хәл, ә аның китабы чыннан да иң яхшы нонфикшнга дәгъва итә аламы, дигән сораулар да яңгырады, чагыштырулар да, бәхәсләр дә булды... Тик шунысы бәхәссез: «Халатная жизнь» XX йөзнең икенче яртысыннан алып бүгенгә кадәрге дистәләгән шәхесне һәм аларның даирәсен, тормыш төеннәрен, иҗади эзләнүләрен – дәвер сүрәген чагылдыра. Монда без Высоцкий, Солженицын, Битов, Аксёнов, Любимов, Табаков һ.б. белән тормышчан, табигый атмосферада очрашабыз, аларның ничек яшәгәнен, нинди булганнарын күзәтәбез, үзебез өчен нәтиҗәләр чыгарабыз.

Бүгенге вазгыятьтә китапны нәкъ менә чор идеологиясе, яшәү фәлсәфәсе, кешеләрнең нинди сайлау алдында калуы ноктасыннан уку да кызыклы.

ВЕРА БОГДАНОВА. «СЕМЬ СПОСОБОВ ЗАСОЛКИ ДУШ», РЕШ ЕЛЕНА ЛЕВКИЕВСКАЯ. «БЕЛОРУССКИЕ МИФЫ», МИФ

«Укучылар сайлавы» номинациясендә шушы китаплар җиңде. Вера Богданованың психологик триллеры башта Яндекс.Книги платформасында аудиоформатта атна саен өлешләп чыкты – интрига сакланып,





һәр яңа сериясе көтеп алынды. Аудиоформатны тыңлаучылар хәйран иде. Тагын бер интрига: кәгазьдәге форматның финалы аудиоварианттан аерылып тора.

Әсәр Россиядәге реаль очракларны анализлап, 90 нчы еллардагы секталар турында язылган. Шулардан иң билгелесе – «Ашрам Шамбалы». Романда ул «Сияние» буларак күрсәтелә. Сюжет тоталитар сектаның башында торган шаман һәм секта вәкилләре харап иткән җаннар буенча бүлекләргә бүленгән: әйтик, «Беренче җан. Беренче сулыш алу» («Душа первая. Выдох первый»). Сулыш алу роле кайчандыр секта башлыгы булган легендар Катаевның еллар буе психбольницада аунаган һәм, терелеп, ниһаять, кире Староалтайск шәһәренә (прототибы – Барнаул. – **Авт.**) әйләнеп кайткан кызы Никага бирелгән. Әллә аның чынлап та психик яктан тайпылышы бар, әллә ул этисеннән күчкән шаманлык сәләтенә ия, без әсәрнең буеннан-буена бу сорауга җавап таба алмый шомаланабыз.

Никаның әйләнеп кайтачагын вафатына кадәр Катаев үзе әйтеп куйган була, сектантларның кайберләре дә аның каршына: «Бөек аватар!» – дип, табынып егыла. Ника әле бала вакытында сектада яшәгән, бер-бер артлы үтерелгән кызлар белән аралаша, аларның өрәкләре аны шәһәрдә яңа дулкын булып сузылган канлы үлемнәр эзе буйлап йөртә. Ә тайга чигендә һәм кар күмгән урамнарда аны һәрчак дәү аю сагалап тора: Ника бит – паралелль дөньяларны тоташтыручы...

Балачагыннан чынбарлык белән уйдырма чигендә яшәргә мәҗбүр ителгән кыз язмышы аша без җинаятьләр маршруты буйлап узабыз, тәүбә һәм ирекккә юл бармы икәнен ваемлыйбыз. Ата-ана кылган гамәлләр өчен балалар җаваплымы – шул сорауга җавап эзлибез.

«Белорус мифлары»на килгәндә, аны мавыктыргыч сәяхәт буларак та, энциклопедия итеп тә укырга мөмкин.

Тагын кемнәр бүләкләнде һәм кемнәрне укырга?

– **«Әдәбиятка керткән өлеше өчен»** – атаклы серб тәрҗемәчесе Радмила Мечанин. Аның тәрҗемәсендә Сербиядә рус язучыларының 60 тан артык китабы дөнья күргән.

– **«Буын сайлаган автор»** – Анна Баснер («Парадокс Тесея» романы) һәм Илья Кочергин («Запасный выход» романы).

– **«Иң яхшы аудиокитап»** – Яна Вагнер («Тоннель» романы).

XX юбилей сезонын йомгаклап, Экспертлар советы рәисе – язучы Дмитрий Данилов әлеге постны калдыруы турында игълан итте, моны үзенең алдагы иҗади планнары белән бәйләде.

ТҮБӘН БӘРӘСКӘ: ЧАЛ ТАРИХКА КАЙТУ...

ТҮБӘН БӘРӘСКӘ



Фото: Лилиана Вәлитова

Гадәттә, декабрь санында чыгасы авылны язарга килгәч, яңа яуган ак карны шыгырдатып атлап уза идек. Быелгы кыш үзгә: декабрь башында әле карның бер бөртеге дә күренмәде. Шәрә калган агачлар ак шәл ябынырга зар-интизар булып утыра кебек. Караңгы, карсыз кышка ияләнмәгән шул. Кояшны да күптән күргән юк... Тик ни хикмәт, Әтнә районының Түбән Бәрәскә авылы безне кояш белән каршы алды. Шул нур яктылыгында авылның өске башында ак манара калыкты. Башкалабыздагы Мәрҗани мәчете диярсең, нәкъ икесе бертөрле!

Руфия Фазылова

«ТУКАЙ ЧЕМОДАНЫ БУЛЫРГА ТИЕШ...»

Түбән Бәрәскә зур, борынгы авыл – бүген биредә 750 кеше яши, 350 хуҗалык бар. Авыл бик төзек, халык эш белән тәэмин ителгән, чөнки биредә «Ленин исемендәге нәселле терлек заводы» авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы эшли. Авылның ике йөздән артык кешесе шушы хуҗалыкта хезмәт куя. Шәһәргә йөреп эшләүчеләр дә байтак, чөнки Казан белән Түбән Бәрәскә авылы арасы алтмыш чакрым гына. Урта мәктәп, ФАП, китапханә, балалар бакчасы, берничә кибет – тормыш өчен барысы да бар.

Ләкин Түбән Бәрәскә турында сөйләгәндә, иң беренче аның данлы тарихы турында әйтергә кирәк: Казан арты төбәгенең танылган мәгърифәт үзәкләренең берсе булган ул. Бүген дә биредә ике мәчет, мәдрәсә эшли. Һәм өч зират бар. Шуларның Каенлык зиратында Казан ханлыгы дәверенә караган дүрт кабер ташы саклана. Алар 1537, 1539, 1543 нче елларга карый. Бу каберлекләрне берничә галим өйрәнгән. Кыскасы, Түбән Бәрәскәнең борынгы булуына дәлил бар.

Татарстанда салынган беренче таш мәчет – Түбән Бәрәскәдә.

Без әлеге каберлекләргә бармадык, ләкин авылның йөзек кашы булган борынгы, 1769 елда салынган мәчетен күрү бәхетенә ирештек. Татарстанда салынган беренче таш мәчет ул! Нәкъ бер елдан соң Казанда да шундый ук проект белән Мәрҗани мәчете ачыла.

– Безнең авыл мәчетенең тарихы фаҗигале һәм шул ук вакытта бәхетле дә, – диде Түбән Бәрәскә авыл җирлеге башлыгы Аида Фатыйхова. – Аллаһ йортын чыгышы белән Түбән Бәрәскә авылыннан булган танылган сәүдәгәр Ибраһим Борнаев салдыра. Әмма совет власте килгәч, мәчетнең манарасы киселә һәм ул озак еллар мәдәният йорты булып тора. 2012 елда ТР Мәдәният министрлыгы тарафыннан ул тарихи-мәдәни бина буларак теркәлде. Менә шул вакытта күңелдә өмет уянды – мәчетне төзекләндерү турында сүз чыкты. Ленин исемендәге кооператив җитәкчесе Илгиз Вилданович бу эшнең башында торды: республика җитәкчелегеннән ярдәм сорады. Нәтиҗәдә, 2020 елның җәендә, Корбан бәйрәме алдыннан, мәчетебезнең гөмбәзенә ярымай урнаштырылды. Бүген монда биш вакыт намаз укыла, балалар да, өлкәннәр дә дин сабагы укый.

Мәчетнең ян ягында аерым бүлмәләр бар, реставрация вакытында аларга музей ясаганнар икән. Иң сөенечлесе – Ибраһим Борнаев заманында диварлар ничек булган, шул килеш калган, нәтиҗәдә, мәчетнең эчендә дә, музей бүлмәләрендә дә үзгә бер рәхәт рух хөкем сөрә...

– Заманында бу бүлмәләрдә кибет складлары булган, – диде Аида Фатыйхова. – Музей ясыйбыз дип мөрәҗәгать иткәч, тиз арада халык өендә булган кадерле, борынгы әйберләрен алып килде. Элеккеге Коръән китаплары, көнкүреш кирәк-яраклары, хәтта Тукай чемоданына кадәр бар. Тукай кунак булып киткән йорттан китерделәр аны. Шуңа Тукайныкы түгелме икән, дигән фараз бар.

Ибраһим Борнаев үз заманының атаклы сәүдәгәре саналган, аның белән Казанда да, Мәскәүдә дә санлашканнар. Борнаевның Түбән Бәрәскәдә зур кирпеч заводлары булган, туган авылындагы мәчетне шуңа да тиз төзегән ул.

Мәчетнең бүгенге имамы Рамазан хәзрәт Юмангулов белән дә таныштык.

– Тумышым белән Ульяновск өлкәсеннән мин, – диде Рамазан хәзрәт. – Түбән Бәрәскә бик данлыклы, тарихлы авыл. Халкы да бик

– Музей ясыйбыз дип мөрәҗәгать иткәч, тиз арада халык өендә булган кадерле, борынгы әйберләрен алып килде.

– Заманында бу бүлмәләрдә кибет складлары булган, – диде Аида Фатыйхова.

– Тукай чемоданы булырга тиеш...

тырыш, җигелеп тормыш тарталар. Мин дә алардан калышмыйм: Ленин исемендәге кооперативта эшлим дә. Әнә шулай дин белән дөньялыкны бергә алып барырга тырышабыз, Коръәндә дә шулай диелгән бит.

БӘХЕТЛЕ НИГЕЗ

Түбән Бәрәскәдә матур гаиләләр күп: зур йортлар салып, шәһәрдәге кебек яшәп яталар. Без исә өч буын бергә яшәүче Хисмәтуллиннарга кердек, чөнки хәзер мондый гаиләләр сирәк. Гаилә башлыгы Хәмит абый җәмәгате Галиябану апа белән утыз җиде ел бергә гомер итә икән. Ике бала – бер кыз, бер ул үстергәннәр. Кызлары гаиләсе белән Кама Тамагы районында яши, ә уллары Салават яннарында калган. Алисә исемле сөйкемле кызга өйләнеп, күп балалы гаиләгә әйләнгәннәр. Яшь гаиләнең өч кызы үсеп килә – Сәйдә, Сылу, Самирә.

– Бер-берегезгә бигрәк охшагансыз икән, – дибез.

– Аны сез генә түгел, барысы да шулай ди. Таныш булмаган кешеләр дә: «Сез абыйлысеңеллеме?» – дип сорый.

Хатын-кызлар табын әзерләп йөргәндә, ир-атлар белән бакчага чыктык. Ишле гаилә яңа мунча салып ята икән, өч өлештән тора ул: юыну бүлмәсе, бассейн ягы һәм ял зонасы. Монда шашлык, коймак пешерү өчен аерым мич тә бар.

– Авылларда бассейнлы мунчалар күргән юк иде әле, – дибез.

– Оныкларга бассейн да булсын дибез инде, – дип дәвам итте Хәмит абый. – Салават кемдәдер күреп кайткан иде. «Әти, аны без дә эшли алабыз бит», – дип кызыктырды. Без булдырмаган эш юк ул. (Көлә.) Быел җәебез шушы мунчаны салып узды.

Хәмит абыйның кулыннан килмәгән эше юк: колхозда машина йөртүче дә, бригадир да булган. Аннан исә балта остасына әйләнгән – бер төркем ирләр белән төзелештә йөргәннәр.

– Туксанынчы елларда эштә хезмәт хакын тоткарлый башладылар, акча урынына азык-төлек тә бирдедәр. Болай булмас дип, колхоз эшен ташладым. Шуңа да без начар яшәмәдек.

Хәмит абыйның җәмәгате Галиябану апа – Арча районыннан. Уллары Салават та Арча кызына өйләнгән. Нәтиҗәдә, килен белән каенана бу нигездә сүзсез дә аңлаша икән.

– Киленемә күзләр тимәсен, андыйлар сирәк, – диде, өйгә кергәч, Галиябану апа. – Сабыр да, уңган да, шигырьләр яза. Әле үзегезгә укып күрсәтер. Без аның шулай шигырь укыганын тыңларга яратабыз.

Алисә исә каенанасының сүзләренә елмаеп куйды. Яшь киленнең шигырьләр җыентыгы басылып чыккан. «Яңа исем» иҗат лабораториясендә шөгыльләнә икән. КФУның татар теле һәм мәдәниятара багланышлар бүлеген тәмамлаган. Бүген Түбән Бәрәскә урта мәктәбендә башлангыч сыйныфлар укыта.

– Ә мин каенанам белән каенатамны мактыйм әле, – диде Алисә. – Олы кызыбызга унбер ай булганда эшкә чыктым. Әти белән әни балаларны карады. Төпчеге белән дә шулай, яшь ярымлык баланы алып калдылар.

Мәчетнең бүгенге имамы Рамазан хәзрәт Юмангулов.

Өч буын бергә яшәүче Хисмәтуллиннар.

Салават Казанга йөреп эшли, мин дә иртүк чыгып китәм. Олы кызыбыз Сәйдә мәктәптән кайткач, дәү әнисе пешергән кайнар ризыкны ашый, аннары дәү әтисе белән туйганчы сөйләшәләр. Әбиле-бабайлы йортта яшәү оныклар өчен бик күңелле ул.

Чынлап та, без аралашып утырганда биш яшьлек Сылу дәү әтисе яныннан китмәде дә, бакчада да аның тирәсендә бөтерелде. Тулы гаилә бәхете шушы буладыр ул.

– Хәзер яшьләр шәһәрдә калу ягын карый, ә сез менә эти-әни янында яшәргә уйлагансыз, – дидек, сораулы карашыбызны төбәп, Салаватка.

– Уйлап та түгел, ул үзеннән үзе шулай килеп чыкты кебек. Өйләнешкәч тә Алисә белән Казанда фатир арендалап яшәп алдык. Җәен исә туган якка кайтып тордык. Шуннан инде китәсе дә килмәде. Казан якын бит, мин мәсәлән һаман да шәһәргә йөреп эшлим. Кирәк чакта Алисәне дә Казанга алып барам.

КЕНДЕК ӘБИСЕ

Авыл җирлеге башлыгы белән җыйнак кына бер йортка кердек. Түр яктан нурлы бер әби күренде – Кәүсәрия Гыйззәтуллина икән, сиксән сигез яшен тутырган. Тумышы белән Әтнә районының Яңа Мәңгәр авылыннан. Күрше авылларга йөри-йөри башта җиде еллык мәктәпне, аннан соң урта мәктәпне тәмамлаган. Шуннан соң ике ел Казанда фельдшерлар курсында белем алган. Нәтиҗәдә, егерме ике яшендә Әтнә районының Олы Өшкәтә авылында фельдшер булып эшли башлаган.

– Әнием гомер буе авыргач, кечкенәдән табиб һөнәренә кызыктым, – диде Кәүсәрия апа. – Өшкәтәдә унбиш ел эшләдем, халык бик яратты үземне. 1971 елда Түбән Бәрәскәнең фельдшер-акушерлык пунктына күчерделәр. Монда егерме биш ел халыкка хезмәт иттем. Мин эшли башлаганда Түбән Бәрәскә мәктәбендә 550 бала иде. Аның өстенә мөмкинлеге чикле кешеләр – авыру балалар, Бөек Ватан сугышы инвалидлары, йөзләп кеше... Аларның эше белән кайчагында Әтнәгә көненә икешәр тапкыр бардым. Җәяү бит ул, утыз ике чакрым дигән сүз! Ләкин монда килгәч, шунысы яхшы булды: йөкле хатын-кызларны бәби табарга алып барырга колхоз машина бирә иде. Өшкәтәдә эшләгәндә күп хатын-кызны өендә бәбиләттем. Ә нишлисең, тулгагы башланган, алып барырга машинасы да, юлы да юк. Тиз генә тәвәккәллисең.

Кәүсәрия Гыйззәтуллина – дистәләгән баланың кендек әбисе.

Кәүсәрия апа дистәләгән баланың кендек әбисе. Иң сөенечлесе – бер генә бәхетсезлек очрагы да булмаган. Дөньяга аваз салырга ярдәм иткән ул балаларны әбекәй һаман да исемләп әйтә ала. Хәер, Түбән Бәрәскә халкы да Кәүсәрия апаны зур хөрмәт белән искә ала. Үз балалары булмаса да, йөзләгән балага авыр чакта ярдәм иткән изге җан ул. Бүген биш вакыт намазын калдырмый, бөтен кешегә карата хәер-догада.

– Ятимлек белән үстек, гади булып яшәдек, кызым, – диде әбекәй. – Болай озын гомерле булырмын дип уйламаган да идем. Гомер иткән бабам берничә ел элек бакыйлыкка күчте. Аллаһ насыйп итмәгәндер, балаларыбыз булмады, аның каравы, бөтен авылның баласын карап үстердем. Кайбер төннәрне йоклап та тормый идем, әле берсе килә, әле икенчесе. Авыл зур, кеше күп, ләкин эшемне бик яратып башкардым, язмышыма рәхмәтлемен.

«БЕЗНЕҢ КОЛХОЗ ЗУР ИДЕ»

Әйткәнемчә, авылда Ленин исемендәге кооператив бар. Нәкъ элеккеге колхоз системасы буенча эшли ул, ләкин алымнары заманча: сыерларны роботлар сава, техника да компьютерлашкан. Иң кызыгы, совет замангында да Ленин исемендәге колхоз исемен йөрткән булган ул. Дөрес, 1984 елдан башлап, 2004 елга кадәр «Татарстан» хуҗалыгы булып йөреп ала. Бүген инде кабат асылына кайткан, дисәк тә була.

Авыл тарихын, колхоз чорлары турындагы истәлекләрен авылның аксакалы Әдеһәм Гайнуллиннан сораштык. Армияне санамаганда, бөтен гомерен Түбән Бәрәскәдә яшәгән, эшләгән тынгысыз кеше ул. 1944 елда, этисе сугышка киткәч туган бала.

– Безнең авыл гомер бакый данлыклы, бай саналган, – диде Әдеһәм абый. – Советлар заманына кадәр бик мәгърифәтле дә булган әле. Түбән Бәрәскәдә тирә-якка атаклы мәдрәсә эшләгән, анда Шаһабетдин Мәрҗанинең этисе Баһаветдин хәзрәт тә белем алган. Кызганыч, безнең чорда инде мәдрәсә дә, мәчет тә булмады. Тик барыбер сөенәм: мәчет бинасын амбар-фәлән итмәделәр, ә клуб ясадылар. Димәк, ул барыбер ягылды, ташландык хәлгә килмәде. Инде Аллаһ йортыбыз яңадан ачылгач, ничек сөенгәнне белсәгез! Күзгә яшьләр килде...

Әдеһәм абый меңләгән яшьтәшләре кебек авырлык күреп үскән бала. Колхозның күтәремгә калган сыерларын әле дә яхшы хәтерли. Сугыштан соң да авылда тормышлар бик авыр булды, ди. Ипине ул туйганчы бары армиягә баргач кына ашаган.

– Сугыш чорында да, аннан соң да бик авыр булды, – дип дәвам итте аксакал. – Сугыштан соң да колхоз эшчеләргә ярты капчык икмәк тә бирә алмый, таякка эшләтә. Юк, бу җитәкчеләрне гаепләү түгел, аның бит заманасы шул: хөкүмәткә итләтә, сөтләтә, йонлата салымын түләргә тиешсең. Шөкер, нинди авыр заманнарда да бирешмәдек, уникe яшьтән колхозда көтү көтеп башлаган идем, соңгы егерме сигез елда ревизия комиссия рәисе булдым. Шуңа сөенәм: авылда ферма бинаалары ташландык хәлгә килмәде, киресенчә, бүген колхоз икенче яшьлеген кичерә.

Әдеһәм абый ике тапкыр хаҗда булган, өч дистә елдан артык намазда икән. Җәмәгате Нәзирә апа белән бик матур тормыш корганнар. Ике ул тәрбияләп үстергәннәр. Балалары гаиләләре белән шәһәрдә яши икән.

– Әдеһәм белән күршеләр идек без, – диде Нәзирә апа. – Армиядән кайткач, миңа сүз катты ул. Үрнәк гаилә кордык, матур итеп йортлар да салып чыктык. Бүген инде балаларыбыз өчен сөенеп яшибез, бик акыллы ике ул үстердек. Гел ярдәм итәләр, кайтып торалар. Киленнәр, оныклар да якын итә, рәхмәттән башка сүз юк.

...Түбән Бәрәскәдән күтәренке кәеф белән кайттык: нинди татар авыллары бар бит! Тарихны, динне онытмыйлар, шуның белән бергә тормышлары да җитеш. Колхоз системасының сакланып калуы да үз ролен уйнагандыр. Нигезе төпле, догалы бу авылның, шулай булгач, заманның кырыс җилләре дә кагылмас аңа.

– Безнең авыл гомер бакый данлыклы, бай саналган, – диде Әдеһәм Гайнуллин.

ТАРИХ БИТЛӘРЕННӘН

– Авылның беренче исеме «Верески» булган дип карала. Шуннан ул, татарчалаштырып, Бәрәскәгә әйләнгән.

Оешу вакыты XV гасырларга карый. Каен урманнары уратып алган әлеге җирдә элек-электән марилар гомер кичергән. 1516 елда авылда инде мәчет барлыкка килә. Шуннан ул гел зурайган, үскән, кеше саны да арта барган.

Башкалабыз Казанда сакланып калган, тарихлары милли мәдәниятебезнең асыл затлары белән бәйле агач йортлар белән таныштыруны дәвам итәбез. «Казанның агач йортлары» проектын «Татарстан» журналы «Татар ядкәрләре» шәхси оешмасы белән берлектә эшли.

Эммануил Пёльцам.

Алексей Прокопчик.

РОМАНСЛАР ҺӘМ КЫРГЫЙ ҖАНВАРЛАР ЯШӘГӘН ЙОРТ

Луиза Янсуар, Фәнзилә Җәүһәрова

Казан үзәгеннән җәяүләп 15 минут аралыгында барып җитеп була торган бер урын бар – ул да булса, адресы буенча Волков урамы, 14 нче йортта урнашкан атаклы галим Эммануил Пёльцам биләмәләре. Аны бүген нәкъ менә шушы шәхес исеме белән атап йөртәләр дә. Йортка инде 134 яшь тулып килә: дәһшәтле инкыйлаблар, Бөек Ватан сугышын, шаулы 90 нчы елларны, инде югары технологияләр белән шаккатырган нуленчеләрне дә исән кичкән ул.

Фото: Александр Ефремов, ИНДЕ интернет-порталы, Пёльцам йорты архивыннан

БОРЫНГЫ – ЯҢА

1891 елда Керем йорты буларак төзелә, ә менә 1896 елдан алып 1912 елга кадәр биредә Казан Император университеты галиме, күренекле зоолог Эммануил Пёльцам яши. Чыгышы буенча – эстон кешесе, зоологияне ул үзлегеннән өйрәнә һәм үз чоры өчен бик яхшы карьера төзи.

Некрологы буенча без аның башта – Казан, ә аннан Томск университетларындагы Зоология кабинеты консерваторы булганын беләбез. Идел буйлап сәяхәтләр оештырган, Казан университетындагы башка галимнәр белән берлектә, табигатьне актив өйрәнгән. Пёльцамның елгалар ихтиологиясе буенча бай материаллар туплавы мәгълүм.

1923 елдан башлап, Совет хөкүмәте кулына күчкән йорттагы бүлмәләр коммуналь фатирларга бүленә һәм аларда Сельхозбанк хезмәткәрләре яши башлый. 1934 елда монда банк хезмәткәре Пётр Селивестерович Антипов килеп урнаша, хәзергәчә йортта аның оныкчыгы Алексей хатыны Ольга белән яши.

2018 елда йорт «Том Сойер» фестивале хәрәкәте волонтёрлары игътибарына эләгә. Нәкъ менә шул вакытта җирле төбәкне өйрәнүчеләр аның тарихи үткәнен ача, «Пёльцам йорты» булуын тәгаенли. Фамилияне 1910 елга караган йорт хуҗалары исемлекләреннән табып алалар. Йортның борынгы-яңа атамасы, шулай итеп, казанлылар теленә әйләнеп кайта.

РОМАНСЛАР ҺӘМ ИКЕ ГАСЫР АРАСЫНДА КҮПЕР

«Том Сойер» волонтёрлары йортның алгы өлешен реставрацияли. Кунаклар белән туристлар өчен йорт ишекләрен пандемия вакытында, 2020 елда ача. Бу да – искиткеч тарих. Фатирларының элеккеге интерьерын саклап калган һәм аңа, антиквар җиһазлар да өстәп, кабат җан өргән Алексей Прокопчик – элеге дә баягы Антиповның оныкчыгы – ике гасыр арасында күпер суза. Инстаграмда махсус сәхифә булдырып, йорт белән таныштырырга керешә. Кызыксынучылар да, экскурсиягә килергә омтылучылар да шактый җыела.

2020 елның сентябрь аенда Пёльцам йортында беренче экскурсия уза. 1953 елда Антиповлар сатып алган фортепианоны төзекләндереп, музыкаль кичәләр дә уздыра башлыйлар. Алексей әйтүенчә, аның карт әбисе белән бабасы әле тагын мандолинада, гитарада да уйнаган, бу өйдә романслар гел яңгырап торган. Хәзер дә бу традицияне онытмыйлар, чөнки Алексей үзе дә, хатыны да – меломаннар. Ольга кайчандыр чиркәү хорында җырлаган, Алексей джаз ярата...

ДАУЛЫ МИТИНГЛАР ҺӘМ КЫРГЫЙ ҖАНВАРЛАР

Ерак түгел генә урнашкан Арбузовлар музей-йорты традицияләрен дәвам итеп, Прокопчиклар да йортны алга таба җиһазлавын дәвам итәргә ниятли. Иганәчеләр, ярдәм кулы сузучылар булса, алар бигрәк тә шат. Әлегә йортка экскурсиягә 12-15 кеше, ә музыкаль кичәләргә 20 гә кадәр кунак язылa ала икән. Хуҗалар йортның үткәне белән таныштыра, тарихи фактларга туктала, музыка тыңлаганнан соң, чәй эчеп, фотога төшү хуплана.

Тузган торак программасы буенча кешеләр бу йорттан чыгарылган вакытта митинглар да оештырган. Ахыр чиктә, берничә гаилә яшәп калу хокукына ия булган. «Том Сойер» фестивале вакытында йортның тышкы кыяфәтен генә рәтләп калмыйча, югалган агач элементларын да кайтарганнар: йөзлекләрдәге бизәкләрне, детальләрне. Йортның үткәнен хәтерләүчеләр дә катнашкан.

Тагын бер кызыклы фактка тукталмый булмас. Баксаң, бу өйдә Алексейның әбисе белән этисе Казан зоопаркыннан тәрбиягә кыргый җанварлар алып торып та асраган икән. Имеш, арыслан, леопардлар, йомшак тәпиләре белән басып, йөгереп йөргән кайчандыр биредә...

Димәк, Пёльцам әфәнде рухы үзеннән соң да яхшы сакланган, дияргә генә кала.



«ТҮГӘРӘК УЕН» – АВЫЛ КЕШЕСЕН ЗУРЛАУ

Редакциябезгә Теләче районы газетасының баш мөхәррире Ленар Хуҗин килеп керде. «Сез «Татарстанның иң яхшы ансамбле» конкурсы башлагансыз икән. Безнең Теләче районында да бик шәп фольклор ансамбльләр бар, менә видеоларын да күрсәтәм», – диде.

Чынлап та, Теләчедә җыр-моңга гашыйк асыл затлар күп икән, алар җырлап кына калмый, милли йолаларны, шөгыльләрне дә барлый, сәхнәләштерә. Дүрт ел рәттән биредә республика күләмендә «Түгәрәк уен» уздыралар. Блогерлар, артистлар, район халкы – барысы бергә күңелле итеп ял итә.

– Теләчедә «Түгәрәк уен» оештыру кемнең уе булды? – дибез Ленар Хуҗинга.

– Әлеге проектны редакциянең смм-белгече Зөлфия Ибраһимова белән башлап җибәрдек. Ел саен җәен һәм кышын укучыларыбыз белән очрашабыз, фикер алышабыз, рәхмәт сүзләрен җиткерәбез. Җәйге очрашуны менә шундый «Түгәрәк уен» форматында эшләргә булдык. Теләче район хакимияте,«Татмедиа» акционерлык җәмгыяте җитәкчелеге дә бу фикерне хуплады, күтәреп алды. Район башлыгы Айрат Фатхуллин, «Татмедиа» АҖ генераль директоры Шамил Садыйков, Баландыш авыл җирлеге башлыгы Рөстәм Мөхәммәтшин үз өлешләрен кертте. Иганәчеләр таптык, нәтиҗәдә, бик күңелле бәйрәм оештырдык. «Түгәрәк уен» Теләченең Баландыш авылында уза, чөнки әлеге җирлек районда гына түгел, республикада да билгеле. Бу күңелле бәйрәм – Баландыш авыл җирлеге белән уртак эш.

Ул Сабан туеннан аерыла: монда хатын-кызлар да ярышып печән чаба, себерке бәйли. Гадәттә, авыл халкы Сабан туенда рәхәтләнеп ял итә алмый кала, чөнки кайткан кунакларны каршы аласы, озатасы бар. Ә монда без нәкъ менә авыл кешесе өчен бәйрәм ясыйбыз. Шулай булгач, авыл кешесен зурлау, олылау да бу.

Чынлап та, «Түгәрәк уен» күңелле узган. Кышкы озын кичләрдә авыл апалары киләсе бәйрәмгә әзерләнә – җырлар ятлыйлар, яңа сәхнә костюмнары сайлыйлар. Санаулы вакыт бик тиз уза – әле генә күзгә кергән идек, инде кыш җитте. Шагыйрь әйтмешли, күп калмады инде җәйгә дә. Ә алда – яңа Сабан туйлары, яңа «Түгәрәк уен»нар...

Фото: Зөлфия Ибраһимова, tatar-inform.ru

ЭМИЗ – ТЕЛӘСӘ КАЙСЫ БӘЙРӘМГӘ ШӘП БҮЛӘК

ЭМИЗ

БҮЛӘК ТУПЛАНМА

3 = 6

ЭМИЗ ТАВРИЧЕСКИЙ 0.75

Тәкъдим РФның барлык регионнарында 2025 елның 1 декабреннән 31енә кадәр гамәлдә. Башка акция тәкъдимнәре белән кушылмый

ЭМИЗ – ЙӨЗЕМ ТЫШЧАСЫ
ҺӘМ ТӨШЕНЕҢ КӨЧЕ ҺӘМ ФАЙДАСЫ

2025 ЛУЧШИЕ ТОВАРЫ И УСЛУГИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

100 ЛУЧШИХ ТОВАРОВ РОССИИ

100% NATURAL

ECO

HALAL

EMIZ.RU

8 800 444 09 37

Реклама. «ЭМИЗ» ҖЧҖ, Казан, Фучик ур., 52а, 3 нче офис. ОГРН 1660369389